2 ◦ 2016

# ФӘННИ ТАТАРСТАН



ISSN 2499-9741

КАЗАН

*Журнал «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә*

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

▶ **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

▶ **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән,
мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары —
мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

▶ **БАШ РЕДАКТОР**

КИМ МӨГАЛЛИМ улы МИҢНУЛЛИН

▶ **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

▶ **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты)

▶ **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

М.Г. МОРТАЗИН, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Г.Р. ХӘКИМОВА

## БУ САНДА


Баш редактор сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Мирхәев Р.Ф.* Г. Тукай әсәрләренең теле хакында . . . . . . . . . . 9
*Таһирова Ф.И.* Шүрәле образының эволюция һәм трансформациясенә лингвокультур күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . 14
*Вәлиева М.З.* Габдулла Тукай әсәрләрендә документаль антропонимнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
*Хисамов О.Р., Хамматуллина И.И.* Г. Тукай шигырьләренең поэтик ономастиконын өйрәнү тәҗрибәсеннән . . . . . . . . . . 23
*Денмөхәммәтова Э.Н.* Г. Тукайның мәгънәдәш сүзләрне куллану осталыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Хисамов Н.Ш.* Тукайның шигъри фикерләвендә шәркый сурәтләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
*Рәмиев З.З.* Тукай энциклопедиясе хакында . . . . . . . . . . . . 38
*Йосыпова Н.М.* Габдулла Тукай шигъриятендә символик образлылык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
*Харрасова Р.Ф.* Тукайчылар династиясеннән ике шагыйрь . . . . 51
*Шәйхелисламов З.Р.* Истанбул һәм Тукай . . . . . . . . . . . 60
*Мөбарәкшина А.Р.* Тукай шигырьләре беренче мәртәбә рус телендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
*Тимерова Л.М.* И. Нуруллин драматургиясендә Г. Тукай темасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
*Әхмәдуллин А.Г.* Бөек шагыйрьне зурлап һәм яклап . . . . . . . . 73
*Бәдигый Хәнәфи.* Габдулла Тукай – туган як җырчысы . . . . . . 77

### ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР

*Кыясова Г.Х.* Төрекмән-татар рухи мәдәнияте үсешенә Габдулла Тукай әдәби мирасының тәэсире . . . . . . . . . . . . . 82
*Барган Х.* Татар шагыйре Габдулла Тукай һәм төрек әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Закирова И.Г.* Фольклорда су ияләре һәм су культы белән бәйле мифологик мотивлар . . . . . . . . . . . . . . . . 99

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Яхин Ф.З.* Г. Тукай «Бердәмлек һәм тәрәккыят» комитетында . . 111
*Галләм Р.Г., Фидаева Л.И.* Тукай туган авыл (*Кушлавыч авылы тарихыннан сәхифәләр*) . . . . . . . . . . . . . 115

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Галимҗанова Э.М., Фәйзуллина Ф.Г.* Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» төрле басмаларда . . . . . . . . . . . . 120

## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР

*Ярми Х.* Тукай һәм халык иҗаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
*Сәгъди Габдрахман.* Татар шагыйрьләре арасында Тукай (*үлүенә ун ел тулу мөнәсәбәте белән*) . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

## ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Әхмәтҗанов М.И.* Тукай поэзиясе ташъязмаларда . . . . . . . 147

## СӘНГАТЬ

*Әхмәтова Д.И.* Әстерхан фотографы И.М. Бочкарев . . . . . . 151
*Ваһапова Ф.Г.* «Яшен» һәм «Ялт-йолт» сатирик журналларының рәссам-бизәүчеләре . . . . . . . . . . . . . . . . 161
*Алмазова А.Г.* «Шүрәле» балеты . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

От главного редактора . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Мирхаев Р.Ф.* О языке произведений Г. Тукая . . . . . . . . . . 9
*Тагирова Ф.И.* Лингвокультурный анализ эволюции и трансформации образа Шурале . . . . . . . . . . . . . . . 14
*Валиева М.З.* Документальные антропонимы в произведениях Габдуллы Тукая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
*Хисамов О.Р., Хамматуллина И.И.* Из опыта изучения поэтического ономастикона стихотворений Г. Тукая . . . . . . . . . . .23
*Денмухаметова Э.Н.* Мастерство Г. Тукая в использовании синонимов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Хисамов Н.Ш.* Восточные образы в поэтике Тукая . . . . . . . . . . . 33
*Рамеев З.З.* Об энциклопедии Тукая . . . . . . . . . . . 38
*Юсупова Н.М.* Символическая образность в поэзии Габдуллы Тукая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
*Харрасова Р.Ф.* Два поэта из династии Тукая . . . . 51
*Шайхисламов З.Р.* Стамбул и Тукай . . . . . . . . . . . 60
*Мубаракшина А.Р.* Стихотворения Тукая впервые на русском языке . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
*Тимерова Л.М.* Тема Тукая в драматургии И. Нуруллина . . . . . 67
*Ахмадуллин А.Г.* Возвеличивая поэта . . . . . . . . . . . . . . . 73
*Бадиги Ханафи.* Габдулла Тукай – певец родного края . . . . . . . 77

## ЛИТЕРАТУРНЫЕ СВЯЗИ

*Киясова Г.Х.* Влияние литературного наследия Г. Тукая на развитие туркмено-татарской духовной культуры . . . . . . . . 82
*Барган Х.* Татарский поэт Габдулла Тукай и турецкая литература . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Закирова И.Г.* Мифологические мотивы в фольклоре, связанные с культом воды. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Яхин Ф.З.* Г. Тукай в комитете «Единство и Прогресс» . . 111
*Галлям Р.Г., Фидаева Л.И.* Малая родина Тукая (из истории деревни Кошлауч) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .115

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Галимзянова Э.М., Файзуллина Ф.Г.* Разные издания книги Г. Тукая «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» . . . . . . . . . . 120

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Ярми Х.* Тукай и народное творчество. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
*Сагъди Габдрахман.* Тукай – яркий представитель плеяды татарских поэтов (*к 10-летию смерти*) . . . . . . . . . . . . . . . 139

## ПО СЛЕДАМ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Ахметзянов М.И.* Поэзия Тукая в эпитафиях . . . . . . . . . 147

## ИСКУССТВО

*Ахметова Д.И.* Астраханский фотограф И.М. Бочкарев . . . . . 151
*Вагапова Ф.Г.* Художники-оформители сатирических журналов «Яшен» и «Ялт-юлт» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
*Алмазова А.Г.* Балет «Шурале» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164

## ХРОНИКА НАУЧНОЙ ЖИЗНИ

## БАШ РЕДАКТОР СҮЗЕ

Габдулла Тукайның 1913 елның 14 мартында язган «Уянгач беренче эшем» мәкаләсендә: «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле», – дигән юллар бар. Клячкин шифаханәсендә гомеренең соңгы көннәрен уздырган даһи Тукай әлеге сүзләрне кәгазьгә төшергән чакта, әйтерсең лә, киләчәкне алдан күреп эш иткән. Һәрхәлдә, инде гасырдан артык аның иҗатын өйрәнәбез, шәхесенә кагылышлы мөһим вакыйгаларны, мисалларны барлыйбыз, еллар узган саен шул юлда яңа ачышларга тап булабыз. Бу юнәлешнең төп нигезен, үсешен инде менә ничә дистә еллар дәвамында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре билгеләп килә. Алар, мәшһүр шагыйребез үзе язганча, һәммәсен дә инәсеннән җебенәчә тикшереп, соңгы елларда байтак фәнни уңышларга иреште. Иң сөендергәне шул – олы буын тукайчылар белән беррәттән, әлеге сафта яшь галимнәребез дә янәшә атлый, әнә шул рәвешле әдәбият белеме фәнендә буыннар алмашы эзлекле дәвам итә.

Шагыйребезнең 130 еллык юбилеен каршылаган көннәрдә институтыбыз галимнәре икеләтә дулкынлану һәм җаваплылык хисе тоеп яши. Чөнки бу көннәр безнең өчен, бәйрәм вакыты булу белән бергә, Габдулла Тукай иҗатын барлауда узган елларга, башкарылган эшләргә нәтиҗә ясау, киләчәк максат-бурычларны билгеләү ноктасы да. Чыннан да, соңгы елларда Габдулла Тукайның тормышын һәм иҗат мирасын фәнни өйрәнү өлкәсендә шактый зур эшләр башкарылды. Шуларның иң мөһимнәреннән берсе – шагыйребез әсәрләренең алты томлык академик басмасын эшләү. Әлеге академик хезмәт алдагы биштомлык басмадан идеологик сәбәпләр аркасында кыскартылган яки бөтенләй төшереп калдырылган текстларның торгызылуы, гарәп-фарсы алынмаларының, контекстан чыгып, төгәл тәрҗемәләрдә җиткерелүе, совет чоры идеологиясенә туры китереп язылган искәрмә һәм аңлатмаларның субъектив бәя-хөкемнәрдән арындырылуы, әсәрнең иҗат ителү тарихына мөмкин кадәр игътибар юнәлтелүе, бу җәһәттән XX гасыр башында дөнья күргән күпсанлы басмаларның, вакытлы матбугатның кабаттан тәфсилләп өйрәнелеп чыгуы, аңлатмаларның шулай ук Тукайның замандашлары, наширләр тарафыннан бирелгән бәяләмәләр белән баетылуы ягыннан аерылып тора.

Тукай иҗатын заман ихтыяҗларына җавап бирерлек итеп өйрәнүдә институт галимнәре белән бергә республиканың югары уку йортлары, башка фәнни оешмалары хезмәткәрләре башкарган киңкырлы эшчәнлекнең тагын бер тармагы – Габдулла Тукай персональ энциклопедиясенең басмага әзер булуы. Татар әдәбияты тарихында яңа сүз булырлык әлеге хезмәт, соңгы ноктасы куелып, нәшрияткә тапшырылды. Аерым шәхескә багышланган күләмле энциклопедия, гомумән, әдәбият белеме үсешендә үзгә бер этапны тәшкил итә һәм аның Тукайдан башлануы табигый иде. Безнең әле Г. Исхакый, Г. Ибраһимовлар кебек дөньякүләм абруйга ия шәхесләребез бар.

Димәк, киләчәктә дә тел-әдәбият галимнәренә, текстологларга бу юнәлештәге эзлекле эшчәнлекләрен бергәләп дәвам итәсе, үстерәсе дә үстерәсе әле.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар әдәби мирасын өйрәнү юлында алып барылган эзләнүләрне чагылдырган, текстология һәм археография мәсьәләләрен яктырткан «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» исемле яңа сериягә нигез салынды. Бу фәнни җыентыкның беренче чыгарылышы Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат биографиясенә багышлана. Биредәге материалларның күпчелеген шагыйрь хакында сирәк басылган яки моңа кадәр кулъязма хәлендә генә яшәп килгән текстлар, истәлекләр, фотографияләр тәшкил итә.

Габдулла Тукайның юбилеен каршылаган көннәрдә вакытлы матбугат битләрендә шагыйрьнең тормыш юлын, иҗатын яктырткан мәкаләләр дөнья күрә, газета-журналларның апрель саннары Тукайга багышлана. Шул җөмләдән Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең Тукай мирасын өйрәнү юлындагы эшчәнлеге аерым игътибарга лаек: Рифә Харрасованың вакытлы матбугатта дөнья күргән мәкаләләрен, әңгәмәләрен туплаган «Уйлар Тукайга илтә», Динә Әхмәтованың шагыйрьнең бүген фәнгә билгеле фотосурәтләрен сәнгати яктан анализлаган «Тукай фотографияләрдә» исемле китаплары. Болар шагыйрь иҗатына төрле яклап игътибар зур булу турында сөйли.

«Фәнни Татарстан» журналының әлеге махсус саны да Габдулла Тукайга багышланды. Биредә шагыйрьнең шәхесе һәм иҗаты хакында галимнәребезнең соңгы еллардагы табышлары үзәккә алынды. Журнал алдарак саналган хезмәтләрнең эзлекле дәвамы булып, бүген Тукай фәне ирешкән казанышларны көчәйтеп, тулыландырып торыр, дип уйлыйбыз.

Шунысын да искәртү урынлы булыр, эшләнгән һәм эшләнәсе гамәлләр болар белән генә чикләнми. Тукайның 130 еллык юбилее уңаеннан ел дәвамында күпсанлы фәнни-популяр чаралар, түгәрәк өстәлләр, халыкара конференцияләр уза. Республиканың төрле фәнни оешмалары, югары уку йортлары галимнәре белән берлектә, бу чараларда институт галимнәре дә катнаша, күпчелегендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты әлеге эшләрне оештыручы, координацияләүче үзәк вазифасын да башкара. Мөбарәк юбилей уңаеннан Халыкара Төрки академия (Астана, Казакъстан) белән берлектә оештырылган, Казанда 25 апрельдә узачак «Габдулла Тукай һәм төрки дөнья» халыкара фәнни-гамәли конференциясе дә шул чараларның берсе.

«Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә!» – дип чакыра Габдулла Тукай үз шигырендә. Шагыйребезнең эшчәнлеге бүген дә әнә шулай галимнәребезгә иҗат чыганагы биреп, яңа үрләргә рухландырып тора.

УДК 811.512.145

***Р.Ф. Мирхәев***

# Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТЕЛЕ ХАКЫНДА

Язык первых стихотворений Г. Тукая вот уже много лет является объектом научных споров. До этого считалось, что они написаны на староосманско-турецком языке, который имел сильное влияние на старотатарский письменно-литературный язык в конце XIX – начале XX века. Однако результаты последних научных исследований языка произведений поэта, проведенных в контексте истории татарского литературного языка, показали, что основу их лексического фонда составляют слова общетюркского происхождения, которые характерны для многих тюркских языков, в том числе и для татарского языка, и которые употреблялись в старотатарском письменно-литературном языке в течение многих веков, а также арабо-персидские заимствования. Слова же чисто османско-турецкого происхождения встречаются в них очень редко.

**Ключевые слова:** язык произведений Г. Тукая, старотатарский письменно-литературный язык, османско-турецкий язык, разговорный язык, письменно-литературные традиции, языковая ситуация, общетюркская лексика, арабо-персидские заимствования.

Г. Тукай – татар әдәбияты белән бергә, татар әдәби теле үсешенә дә зур йогынты ясаган, аерым алганда, телнең эчке мөмкинлекләреннән оста һәм нәтиҗәле файдаланып, әдәби телне башка юнәлештә үстереп җибәргән шәхесләрнең берсе. Бу турыда үз вакытында күренекле тел белгече Җ. Вәлиди түбәндәге юлларны язып калдырган: «Тукайның иң сөйдергән ягы – шөбһәсез, аның теле вә өслүбедер. Тукай кадәр җиңел вә тәкәллефсез, шуның белән бергә аһәңле һәм сәлис язучы шагыйрь әле һәнүз татарда килгәне юк» [Вәлиди, 1923, б. 13]. Ш. Рамазанов әйткәнчә, шагыйрьнең әсәрләре, аларның теле бер яктан, татар халкының әдәби үсеш процессын һәм әдәби теле оешу тарихының үткәннәрен чагылдырса, икенче яктан, татар әдәбияты һәм татар әдәби теленең җитлеккән гүзәл үрнәкләре булып тора [Рамазанов, 1954, б. 62].

Г. Тукайның башлангыч чор иҗаты татар әдәби теле тарихының катлаулы һәм яңалыкларга бай дәверенә туры килә. Мәгълүм булганча, гасырлар дәвамында борынгы төрки, гарәп, фарсы, чыгытай һәм госманлы-төрек телләренең йогынтысы астында үсеш-хәрәкәттә булган иске татар язма әдәби теле XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында структур һәм функциональ яктан зур үзгәрешләр кичерә. Аерым алганда, аның кулланылыш сферасы киңәя –ул сәнгатьле проза, драма әсәрләре һәм газета теле буларак файдаланыла башлый. Шуның белән бергә борынгыдан килгән традицияләр һәм нормалар яңалары белән үрелеп үстерелә. Әлеге үзгәрешләр

язма әдәби телдә үзенә күрә бер «чуарлык» барлыкка килүгә дә сәбәпче була һәм бу «чуарлыкны» шул чорда яшәп иҗат иткән мәгърифәтче әдипләр әсәрләренең телендә күрергә мөмкин.

Г. Тукай шигырьләренең теленә дә гомуми күзәтү ясалган очракта, биредә, шулай ук, борынгы язма-әдәби традицияләр белән бергә, үз чорының саф татар сөйләм теле берәмлекләренең дә урын алганлыгы күренә. Әлеге үзенчәлеккә шагыйрьнең беренче тәнкыйтьчеләре дә игътибар итә. Мәсәлән, Ф. Әмирхан үзенең «Габдулла Тукаев шигырьләре. Өченче дәфтәр» җыентыгы басылып чыгу уңае белән язылган мәкаләсендә шагыйрьнең саф татар сөйләмә телендә язылган шигырьләренә югары, ә «иске төрек», ягъни госманлы-төрек телендә язылган дип уйланылган әсәрләренә тискәре бәя бирә: «Бу мәҗмугада Габдулла әфәнденең халис татарча – һәр татар рәхәтләнеп укырлык язылган бик гүзәл шигырьләре вә халис татар мәгыйшәтеннән алынган тасвирлары янында, иске төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, азәрбайҗанча, тагы әллә нәрсәчә телләреннән корылган шигырьләре дә күптер... Габдулла әфәнде кеби табигате шигъриятле кешеләрнең иске вә яңа төрек әдәбияты тәхте тәэсиренә төшеп тә, татар шагыйре урынына – үзләреннән мөтәкәллиф төрекләшкән шагыйрьләр ясап чыгарулары татар теле вә әдәбияты ноктаи нәзарыннан гөнаһтыр, ...гарәп сүзләреннән татарча төзелеп ясалган бәетләрнең татар шигырь мәҗмугасында торулары – бөтенләй урынсыздыр». Шуның белән бергә бу төрдәге шигырьләрнең дә «гүзәл чыгуы» искәртелә. Әлеге фикерләрен Ф. Әмирхан икенче мәкаләсендә дә дәвам итә, ягъни Г. Тукай шигырьләре саф татар һәм иске төрек телләрендә язылган дип белдерә. Алга таба алар Җ. Вәлиди һәм Г. Ибраһимов хезмәтләрендә дә чагылыш табалар [Татар әдәби..., 2015, б. 92–94].

Әдипнең башлангыч чор иҗатын госманлы-төрек теле һәм әдәбиятына бәйләп карау тенденциясе аннан соңгы дәвердә дә дәвам итеп, үзен бүгенге көннәрдә дә сиздерә. Ләкин Г. Тукай шигырьләрен башка төрки халыкларның (шул исәптән төрекләрнең) рухи-мәдәни мирасы белән уртак тамырларга ия булган татар әдәбияты һәм әдәби теле тарихы яссылыгыннан чыгып өйрәнү аның чынбарлыкка бик үк туры килеп бетмәгәнлеген күрсәтә. Шагыйрь әсәрләренең телен тикшергән галимнәр фикеренчә, аларның лексик фондын, нигездә, гомумтөрки, гарәп-фарсы һәм татар сүзләре тәшкил итә, ә төрек сүзләре чагыштырмача сирәк очрый [Татар әдәби..., 2015, б. 96–98].

Шулай булуга карамастан, Г. Тукайның беренче шигырьләрендә күзәтелгән «тел чуарлыгын» ничек аңлатырга соң? Моның өчен шагыйрь яшәгән чорга хас булган иҗтимагый-мәдәни вәзгыятькә һәм тел торышына мөрәҗәгать итү сорала. Алда әйтеп үткәнчә, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар халкы, аның мәдәнияте, теле тарихында катлаулы чорлардан санала

һәм ул түбәндәге сәбәпләр белән аңлатыла.

Беренчедән, язма-әдәби тел өлкәсендәге традицияләрнең кинәт кенә юкка чыкмавын истән чыгарырга ярамый. Гасырлар дәвамында кулланылып килгән һәм катлаулы бер иҗтимагый күренеш саналган борынгы язма әдәби телне халык өчен аңлаешлы тел дәрәҗәсенә җиткерү өчен билгеле бер вакыт аралыгының үтүе кирәк. Саф татар телендә язылган әсәрләре булу өстенә, Г. Тукай һәм бу чорда иҗат иткән башка әдипләрнең әсәрләрендә борынгы традиция җирлегендә, иске татар язма-әдәби теле үзенчәлекләреннән саналган гомумтөрки, чыгытай, госманлы-төрек, гарәп-фарсы берәмлекләренең дә шактый урын алуы, иң беренче чиратта, нәкъ шуның белән аңлатыла [Хаков, 1972, б. 59].

Икенчедән, XIX гасыр ахырында татар җәмгыятендә башланып киткән әдәби телнең нинди булырга тиешлеге турындагы бәхәсләр, XX гасыр башында Петербург, Казан, Оренбург, Әстерхан, Уральск кебек Россиянең төрле шәһәрләрендә татар телендә беренче вакытлы матбугат барлыкка килгәч, тагын да көчәеп китә. Татар укымышлыларының бер өлеше борынгыдан килгән иске язма-әдәби тел алга таба да кулланылырга тиеш дип санасалар, икенче төркем вәкилләре әдәби телне саф татар сөйләмә теленә нигезләүне яклап чыгалар. Шул ук вакытта әдәби тел буларак госманлы-төрек телен куллану фикерен алга сөрүчеләр дә була. Әлеге мәсьәләдә газета наширләре арасында да бердәмлек булмый. Аларның бер ишесендә халык телендә язуга өстенлек бирелсә, икенчеләрендә исә китап теле нигез итеп алына. Г. Тукайның башлангыч чор иҗатына әдәби тел өлкәсендәге бәхәсләр дә тәэсир итми калмагандыр әлбәттә. Үзенең беренче әсәрләрен шагыйрь вакытлы матбугат битләрендә бастыра һәм шул сәбәпле баштарак газета-журналларның тел өлкәсендә тоткан юнәлешен искә алып эш иткән булырга да мөмкин.

Өченчедән, XIX гасырның икенче яртысында татар язма әдәби теленә башка телләр белән бергә госманлы-төрек теленең дә йогынтысы көчәя. Бу турыда Н.Ф. Катанов түбәндәге юлларны язып калдыра: «На татарском языке многие из богословских и юридических сочинений переведены с языков арабского и персидского или переложены с языков турецкого и джагатайского. Язык сочинений, переведенных или переложенных, не обладает определенностью: тут можно видеть самую беспорядочную смесь и слов, и грамматических форм, и цельных фраз. В Казани лишь в последнее время стал вырабатываться особый стиль: одни (А.К. Насыйри, А.А. Фейзханов) стали употреблять слова своего и других языков с коренными казанско-татарскими грамматическими формами, а другие (А.Г. Максудов) стали употреблять современный турецкий язык. Оба направления обращаются за словами к языкам арабского и персидского, даже тогда, когдат есть свои татарские

слова» [Катанов, 1898, с. 4]. Бу чорда татар язма әдәби телендә төрле тел берәмлекләренең кулланылуына Н.И. Ашмарин да игътибар итә: «Подобно другим тюркам, татары не пишут на чистом родном языке. В их книжной речи встречается масса арабских и персидских выражений, часто только мешающих изяществу и толковости языка. Литературный язык казанских татар представляется нам кроме того странным смешением нескольких тюркских наречий; в нем мы видим наряду с собственно татарскими формами особенности, свойственные джагатайскому и турецкому (т.е. османскому) языку, которые усвоены путем заимствования и подражания» [Ашмарин, 1901, с. 4].

Иске татар язма әдәби теленә госманлы-төрек теле йогынтысының сәбәпләрен Җ. Вәлиди түбәндәгечә билгели: «Төркиядән бик күп төрекчә вәгазь китаплары һәм тәфсирләр кайтып, татар муллалары арасында тарала. «Алты бармак», «Мөхәммәдия»-не һәрбер язу таныган кеше укый иде. Болар соңга таба Казанның үзендә үк басыла башладылар» [Хаков, 1972, б. 60].

В.Х. Хаков фикеренчә, XIX гасырның икенче яртысында һәм XX гасыр башында иске татар язма әдәби телендә госманлы-төрек берәмлекләренең шактый киң күләмдә таралуын мәгърифәтчелек карашларының үтеп керүе (Төркиядә уку, төрек телендә чыккан китаплар алып кайту, аларны тарату һәм Казанда бастыру) нәтиҗәсе дип каралса да, бу гына мәсьәләнең асылына төшенергә җитәрлек дәлил була алмый, чөнки аның сәбәпләре тирәндәрәк ята [Хаков, 1972, б. 60–61].

Мәгълүм булганча, 1883 елда Кырымда «Тәрҗеман» газетасы чыгарыла башлый. Аның нашире күренекле мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе И. Гаспринский газета, аның теле ярдәмендә төрки халыкларны бер арага тупларга омтыла, ә газета теле исә, иң беренче чиратта, билгеле бер дәрәҗәдә гарәп-фарсы алынмаларыннан арындырылган госманлы-төрек теленә нигезләнгән була. И. Гаспринскийның фикерләре баштарак татар укымышлы даирәләре арасында яклау тапса да, соңыннан алар кире кагылалар. Аерым алганда Ш. Мөхәммәдев, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Әхмәров кебек күренекле татар җәмәгать эшлекләре һәм язучылары, шул исәптән Г. Тукай да әдәби телне төрекләштерүгә каршы чыгалар.

Югарыда әйтелгәннәргә йомгак ясап, биредә шагыйрь тарафыннан бу мәсьәләгә карата әйтелгән фикерләрен китерү урынлы булыр: «...аның теле безнең телебезгә бөтенләй кире бер кырым теледер»; «Бу персиян үзенең «сәнә, мәнә, сән үләсән, мән үләм, нә данишәрсән?»ләренә, ягъни үз милли телләренә бер кадак кишмиш кадәр генә ригаясе булса, төрекләрнең шушы чирканыч сонгый телләре белән «шигырь» язмас һәм әүзане шигырьдән кишмиш үлчәве кадәр генә хәбәре булса, «якыйн, вә ашәфтә хун» сүзләренең вәзендәш түгеллекләрен сизәр иде»; «...үз араларында төрекчә сөйлә-

шеп маймылланучы шәкертләр, башларына фәс киеп, «госманлыез, әфәндем» дип йөрүче хифәтләребез дә аз булмады. Ләкин мондый комедияләр вакытына булды да узды да китте. Газеталарда «бундан», «бөйлә» кебек сүзләрне генә калдырып, татарча языша башладылар, китап вә рисаләләр дә татарча чыга; без татарлар, һаман да татарлар булып калдык. Төрекләр Истамбулда, без монда. Хәерле юлга!» [Хаков, 1972, б. 62–63].

## Әдәбият

*Ашмарин Н.И.* Очерк литературной деятельности казанских татар-мухаммедан за 1880–1895 годы. М.: Типография Варвары Гатцук, 1901. 58 с.

*Вәлиди Җ.* Тукайның шагыйрьлеге // Мәгариф. 1923. № 3–4. Б. 13–14.

*Катанов Н.Ф.* Материалы к изучению казанско-татарского наречия. Часть первая. Образцы книжной и устной литературы казанских татар. Казань: Типолитография Императорского университета, 1898. – 298 с.

*Рамазанов Ш.* Татар теле буенча очерклар. Казан: Татар. кн. изд-во, 1954. 422 б.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘҺСИ, 2015. 696 б.

*Хаков В.Х.* Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан: Тат. кит. нәшр., 1972. 221 б.

***Мирхәев Рифат Фирдинат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Ф.И. Таһирова***

# ШҮРӘЛЕ ОБРАЗЫНЫҢ ЭВОЛЮЦИЯ ҺӘМ ТРАНСФОРМАЦИЯСЕНӘ ЛИНГВОКУЛЬТУР КҮЗӘТҮ

Статья посвящена разноаспектному анализу образа Шурале, зафиксированного в фольклорных текстах, отражённого в лексико-фразеологическом фонде татарского языка и воплощённого в разных произведениях искусства. Проведённый анализ показывает, что мифологический персонаж претерпел существенную эволюцию и транформацию, в результате чего значительно расширил ареал бытования, получил переосмысление как литературный герой, идиоматизировавшись, зафиксировался во фразеологии татарского языка в качестве маркированной единицы, характерной только для татарской лингвокультуры и в целом стал неотъемлемой частью общей культуры.

**Ключевые слова:** мифология, лингвокультура, татарский язык, культурный код.

Шүрәле образының һәм тикшерүчеләр өчен, һәм халык өчен иң мөһим үзенчәлеге аның бүгенге көнгә кадәр «җанлы» булып калуында. Ягъни, ул кайчандыр легенда персонажы булараk теркәлеп, шул текстта гына калмыйча, татар халкының иҗат, сәнгать, культура тормышының һәр өлкәсенә үтеп кереп, төрлечә гәүдәләнеп, бүгенге көнгә кадәр яшәп килә. Алай гына да түгел, ул татар культурасында иң киң таралганы, халык арасында иң популяры дип әйтергә тулы нигез бар. Моны типик күренеш дип әйтү дөрес булмас иде, чөнки татар халкының башка әкият-легендаларда телгә алынган яки дөнья фольклорында очраган бер генә персонажның да таралыш ареалы һәм үсеш-үзгәреш тарихы Шүрәле белән чагыштырырлык дәрәҗәгә дә җитми. Моның сәбәбе, әлбәттә, Габдулла Тукайның әлеге мифологик легенда сюжетына язылган поэмасында. Г. Тукайга кадәр Шүрәле татар халык иҗатын өйрәнүче берничә галим тарафыннан кыска-кыска хикәя-легенда рәвешендә теркәлгән берничә әсәрдә генә очрый [Татар халык иҗаты. Риваятьләр..., б. 271; Татар халык иҗаты. Әкиятләр..., б. 111–115]. Ул хикәяләрнең халык арасында таралышы да Казан арты белән чикләнгән булуы турында фикерләр бар. Ә Г. Тукай иҗат иткән «Шүрәле» поэмасының таралышы исә бу образны глобаль дәрәҗәдә таныта. Моннан тыш, образның эчке семантикасы да аның халык тарафыннан бик уңай кабул ителүендә зур роль уйнаган булырга тиеш. Әйтик, К. Насыйри, Гобәйди, Коблов һ.б. әсәрләрендә тасвир ителгән мифик зат архаик кара көчләрнең типик вәкиле булса, Г. Тукай иҗат иткән образ аннан ерак тора. Шүрәле образы анда бер яктан конкрет персонаж булараk гади, халыкчан итеп, нечкә

юмор белән тасвирланса, тулаем алганда ул табигать, туган як, ваемсыз балачак символы булып формалаша. Гомумән, безнең фикеребезчә, Шүрәленең мондый киң популярлыгы турыдан-туры Габдулла Тукайның поэмасында тудырылган образның популярлыгы ул.

Фәнни өйрәнелелеш ягыннан да Шүрәле образы башка фольклор персонажларыннан нык аерыла. Татар халык иҗатын өйрәнүгә нигез салучылардан башлап бүгенге галимнәргә кадәр күпсанлы белгечләрнең тикшерену объекты булып тора. Мәсьәләнең XIX–XX йөзләрдәге историографиясе җентекле рәвештә Л.Ш. Җамалетдинов хезмәтендә чагылыш тапкан [Замалетдинов, с. 115–124]. Соңгы елларда аны төрле аспектлардан тикшерүгә багышланган хезмәтләр арасында шулай ук игътибарга лаеклары бар [Җамалетдинов, б. 6, 167; Тагирова, с. 393–395; Tagirova, s. 197–200 h.б.].

Лингвокультур эзләнүләр күзлегеннән дә бу образ тикшерүчеләр өчен кызыклы предмет булып тора. Теләсә кайсы халыкның мәдәнияте үзенең тамырлары белән халык тарихының бик борынгы чорларына барып тоташа. Аның нигезен кешелек җәмгыятенең формалаша башлаган иң борынгы дәверләрендә барлыкка килгән һәм халыкның дөньяны күзаллавы, танып белү рәвеше, йола-традицияләре, ышанулары һәм мифологиясе кебек күптөрле элементлардан торган синкретик берлеге тәшкил итә. Җәмгыятьнең тарихи үсеше процессында әлеге элементларның һәрберсе үсә, үзгәрә, тулылана, үзара кушылып, берегеп китә яки киресенчә аерымлана, камилләшә. Шушы үсеш һәм үзгәрешләр нәтиҗәсендә һәр халыкның культур-тарихи үзенчәлекләрен чагылдырган, шул җәмгыятьнең үзенә генә хас кыймммәтләр системасы барлыкка килә.

Халыкның теле әлеге системада төп элементларның берсе булу белән беррәттән, уникаль милли, этник билгеләрне, үзенчәлекне үзендә чагылдырган, туплаган һәм йөрткән объект та булып тора. Бу мәсьәләдә без тулысынча О.А. Корнилов фикеренә кушылабыз: «...любой национальный язык является не только одной из кодовых систем общения и хранения информации, но и неповторимым результатом мыслительно-эмоционального и духовного творчества конкретного этноса, его коллективным органом самопознания собственной культуры на фоне пространственно-временного континуума [Корнилов, с. 137].

Этносның рухи иҗат нәтиҗәсе булган һәм, югарыда әйтелгәнчә, аның телендә чагылган шундый берәмлекләр күпчелек очракта универсаль характер алган иң архаик фольклор кодлар, иң киң таралган клише, образ, эпитетлар һ.б.ш.дан гыйбарәт була. Күп вакыт үтүгә карамастан, алар үзләренең беренчел мифологик һәм фольклор тамырына нисбәтлелеген саклыйлар, шуңа күрә дә милли маркерлы булудан туктамыйлар, телдә лингвокультур кодлар ролен үтиләр. Аларны лингвокультур яссылыктан тикшерү нәкъ менә

шул үзенчәлекле кодларны ачып бирергә ярдәм итә. Мифологик Шүрәле образы да татар телендә, аның төрле катламнарында чагылыш тапмый калмаган. Татар фразеологиясендә Шүрәле исеме кереп калган берничә тотрыклы гыйбарә яшәп килә. Аларның семантикасы да турыдан-туры әлеге мифик персонаж турындагы хикәяләрнең эчтәлеге белән бәйле. Мәсәлән, *шүрәлегә су башы күрсәтү* идиомасы да фольклор сюжетка нигезләнгән. Хикәяләрнең берсендә соңга калган бер юлчының каршысына Шүрәле чыгу турында сөйләнә. Аннан качу өчен юлчы чишмә аркылы сикереп чыга. Шүрәле чыга алмый. Татар халкында, башка күп кенә халыклардагы кебек, су мифик көчләр өчен кичә алмаслык чик булып күзалланган. Шүрәле, суны әйләнеп үтәргә уйлап, берәүдән суның башы кайсы якта дип сораган. Тегесе, әлбәттә, аңа кире якка күрсәткән. Шулай итеп, бу гыйбарә «алдау, төп башына утырту» мәгънәсендә кулланыла [Татар халык иҗаты. Риваятьләр..., б. 269].

*Шүрәле каргаган авыл* гыйбарәсенең мифологик тамырлары да ачык күренә. Бер әкияттә Шыгали исемле авылның кешеләре хәйлә белән бер шүрәлене тотып үтерүе тасвирлана [Насыйри, б. 271]. Үлгәндә Шүрәле авылны каргый: *«Авылыгыз алты йорттан артмасын, җиде йортка җитмәсен!»* Шул көннән соң гөрләп торган зур авыл таркалып, берничә йортка кала. Моны шүрәленең каргышы белән аңлаталар. Шул ук сюжет тагын берничә текстта теркәлгән [Тагирова, с. 111–115]. Шулай итеп, 6–7 йорттан гына торган, каралмаган авыл турында сүз барганда *Шүрәле каргаган авыл* гыйбарәсе куллануның сәбәбе аңлашыла.

*Шүрәле бармак* (озын кәкре бармаклар турында), *Шүрәле мөгезе күрсәтәләрме әллә?* (сәбәпсез көлүчегә карата) кебек гыйбарәләрнең эчтәлеге дә, күренгәнчә, әлеге персонажның кыяфәтендәге үзенчәлекләргә нигезләнгән – озын бармаклар һәм мөгез.

Тулаем алганда, бу гыйбарәләр татар теленең культур маркерлары булган лексик-фразеологик чаралары катламына карый. Башкача әйтсәк, башка телдә сөйләшүче чит культура вәкиле өчен ят булган, татар телендә сөйләшүче, татар культурасы белән таныш булган кеше генә аңлый алган берәмлекләр булып тора. Мифологик образ лингвокультур код ролен үти башлавы, һәм культур кодларның беренче чиратта телнең лексик-фразеологик составында саклануы аңлашыла. Әлеге лингвокультур тикшеренү шундый чараларның семантикасын, этимологиясен чит культура вәкилләре өчен ачып бирергә ярдәм итә.

Шүрәле образы үзенең үсеше-үзгәреше дәверендә һәм эчтәлеге, һәм функцияләре, һәм таралышы ягыннан зур трансформация кичерүе белән кызыклы. Аның татар культурасының барлык өлкәләренә үтеп керүенә күп кенә факторларның туры килүе кирәк булгандыр. Һәм мондый эволюциянең төп сәбәпчесе, әлбәттә, Габдулла Тукай. Аның «Шүрәле» поэмасы бик популяр

булганга күрә, китаплар еш басыла. Узган гасырның 20 нче елларында ук Бакый Урманче беренче иллюстрацияләрен иҗат итә. 40 нчы елларда Фәрит Яруллин балеты дөнья күрә. Әдәбиятта Шүрәле Т. Миңнуллин, И. Юзиев, Л. Лерон, Р. Миңнуллин, Р. Батулла, Р. Харис, Р. Зәйдулла, Р. Маннанов һ.б. язучыларның әсәрләрендә персонаж буларак катнаша яки телгә алынып үтә. Күпсанлы рәсем-портретлары (рәссамнар Б. Урманче, Б. Альменов, Ф. Аминов һ.б.), һәм сыннары (скульпторлар Г. Зяблицев, Б. Урманче, М. Гасимов һ.б.) иҗат ителә. Махсус Шүрәле портреты конкурслары һәм күргәзмәләре оештырыла. Күптән түгел Шүрәле экияте сюжетына татарча мультипликацион фильм да төшерелде. Аның исемен төрле күңел ачу урыннары, парклар, балалар мәйданчыклары, иҗат түгәрәкләре, кафе кебек төрле объектларны атау өчен файдаланыла. Гомумән, бүгенге көндә Шүрәле образы чынлыкта нык тиражланган, рекламаланган масскультура элементы булып тора һәм гомумкультур процесслар контекстыннан аерылгысыз.

Нәтиҗә буларак шуны әйтергә мөмкин: чагыштырмача кыска вакыт аралыгы – соңгы йөз ел – эчендә берничә легенда һәм мифологик хикәя персонажы гына булган Шүрәле үзенең үсешендә күп кенә стадияләр үткән. Фольклор персонажы буларак таралыш ареалы киңәюдән башлап, лексик-фразеологик фондка урнашып, телдә урнашкан когнитив модельләре үзгәрү, әдәби герой буларак яңадан иҗат ителүе, соңрак күп мәртәбәләр татар поэзиясендә, драматургия, музыка, опера һәм балет сәнгатендә, скульптура һәм рәсемдә гәүдәләнеш тапкан. Образга салынган менталь эчтәлек тә төрле чорларда һәм гәүдәләнешенең төрле очракларында үзгәрми калмаган. Башкача итеп әйткәндә, хәзерге вакытта Шүрәле татар этнокультурасына мөнәсәбәте булган кеше өчен элеккеге мифологик персонаж булудан узып, күптән инде бик күп төрле элементлардан оешкан бербөтен булып тора. Шулай итеп, фикеребезчә, аерым мифологик образның гомумкультур код дәрәҗәсенә җитеп трансформацияләнүе турында фикер йөртергә тулы нигез бар.

**Әдәбият**

*Исәнбәт Н.С.* Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. I том. 495 б.

*Исәнбәт Н.С.* Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. II том. 365 б.

*Җамалетдинов Л.Ш.* Татар экиятләрен барлау юлында / төз. И.И. Ямалтдинов. Казан: ТӘһСИ, 2015. 264 б.

*Замалетдинов* Л.Ш. О мифологической основе сказки Шурале // Габдулла Тукай. Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвящённых 90-летию со дня рождения поэта. Казань, 1979. С. 115–124.

*Корнилов О.А.* Языковые картины мира как производные национальных менталитетов. 2-е изд. М.: ЧеРо, 2003, 349 с.

*Минһаҗева Л.И.* Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе… // Татар фольклоры мәсъьәләләре. Хәмит Ярминең 100 еллыгына багышлана (Проблемы татарского фольклора. Посвящается 100-летию Х. Ярми). Казан: Фикер, 2004. 167 б.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр. 4 томда. III том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

*Тагирова Ф.И.* Трансформация фольклорных кодов в общекультурные. На примере татарского мифологического образа шурале // Традыцыі і сучасны стан культуры і мастацтваў. Матэрыялы V Міжнароднай навукова-практычнай канферэнцыі (20–21 лістапада 2014 года, г. Мінск). Мінск: «Права і эканоміка», 2014. С. 393–395.

*Tagirova F.* 'Tatar Mitolojisinde Şürele Tipi' // III Uluslararası Halk Kültürü Sempozyumu. Bildiriler. 2. Cilt. 757 s. // Cilt I. Ankara: T.C. Kazan Belediyesi Kültür ve Sosyal İşleri Müdürlüğü Kültür yayınları, 2015. S. 197–200.

Татар фольклоры мәсьәләләре. Хәмит Ярминең 100 еллыгына багышлана. Казан: Фикер, 2004. 358 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 592 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 367 с.

Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр / томны төзүче, искәрмәләрне хәзерләүче Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми, кереш мәкалә язучы Л.Ш. Җамалетдинов, Х.Х. Ярми Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 406 с.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр / томны төзүче, искәрмәләрне хәзерләүче Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми, кереш мәкаләне язучы Л.Ш. Җамалетдинов, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 445 с.

***Таһирова Фәридә Инсан кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*
*feride2412@mail.ru*

УДК 811.512.145

***М.З. Вәлиева***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ДОКУМЕНТАЛЬ АНТРОПОНИМНАР

Как и другие языковые единицы, антропонимы, в частности имена исторических личностей, в поэтических произведениях приобретают дополнительные функции и смысловые оттенки художественно-стилистического характера. Они играют большую роль в построении сюжетной композиции и помогают раскрыть основную идею. Кроме этого, поэты обращаются к ним для передачи культурно-исторической обстановки своего времени и усиления эмоционального фона. Имена исторических личностей находят отражение и в творчестве Г. Тукая. В статье на примере отдельных стихотворений поэта в общих чертах раскрывается его мастерство в области использования документальных антропонимов.

**Ключевые слова:** язык произведений Г. Тукая, лингвостилистика, ономастика, документальные антропонимы, языковой код, поэтическая антропонимия.

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тел байлыгы фәндә шактый тикшерелгән, аның милли әдәби телгә нигез салуы һәм аны үстерүе, баетуы турында аерым хезмәтләр язылган. Шагыйрьнең тел байлыгын тикшерү, өйрәнү бүген дә дәвам итә. Нәкъ Тукай үзе язганча: *«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен, вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле» («Уянгач беренче эшем»).*

Чыннан да, бөек шагыйрьнең иҗаты, шигъриятенең тел-стиль үзенчәлекләре тикшерелә, телне баетудагы роле билгеләнә һ.б. Бу мәкаләдә Г. Тукай иҗатында урын алган документаль антропонимнарның, ягъни тарихи шәхесләр исемнәренең кулланылу үзенчәлекләренә тукталып үтмәкче булабыз.

Кеше исемнәренең аерым бер катламын тәшкил иткән документаль антропонимнар матур әдәбиятта әсәрнең сюжет-композициясен төзү-коруда, аның идея-эчтәлеген ачуда зур әһәмияткә ия булып торалар. Ономаст галим И.А. Воробьева фикеренчә, күренекле сәясәтче, галим, әдәбият әһелләре һәм башкаларның исем-фамилияләре үзләренең яшәү дәверендә субъект хакындагы белем-мәгълүматны сеңдерә киләләр [Воробьева, с. 5]. Шуңа күрә дә алар җәмгыять тормышының билгеле бер дәверен чагылдыра торган шартлы тел, үзенчәлекле код булып торалар һәм матур әдәбият текстында сүз барган тулы чорны реалистик планда чагылдыру сәләтенә ия булган төп чара-детальләрнең бер төре булып саналалар [Щетинин, с. 215]. Нәтиҗәдә, документаль антропонимнар, ягъни поэтик антропонимиягә кертеп карала. Дөрес, автор аларны тудырмый, ләкин элеге антропонимнарның

теге яки бу төрен сайлап, билгеле бер контекстка кертеп җибәрә. Шулай итеп, мондый исемнәрнең коннотациясе тагын да тулылана [Мурадян, с. 128].

Әдәби әсәрне иҗат иткәндә, һәрбер язучы яисә шагыйрьнең үзенә генә хас иҗат психологиясе, стиле булган кебек, Габдулла Тукайның да үзе генә яратып кулланган поэтик законнары, тел-сурәтләү чаралары бар. Бу үзенчәлекләр, үз чиратында, шагыйрьнең кеше исемнәрен куллануына да тәэсир итми калмаган. Габдулла Тукай документаль антропонимнарны ике максаттан чыгып куллана.

1. Тарихи вакыйга, чорга бәйле рәвештә тарихи шәхесне индивидуальләштереп атау өчен. Бу очракта документаль антропонимнар үзләренең төп номинатив функцияләрен башкаралар. Мондый төр исемнәр Габдулла Тукайның барыннан да бигрәк әдип яисә шагыйрьләргә багышлап, нечкә лиризм белән язылган әсәрләрендә урын ала. Мәсәлән:

*Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,*
*Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам.*
(«Бер татар шагыйренең сүзләре»).

2. Тарихи шәхес исемнәре текстта турыдан-туры стилистик бизәк, конструкцияләр хасил итү, эмоциональ фонны көчәйтү өчен, ягъни поэтик максат белән дә кулланылырга мөмкин. Мәсәлән:

*Мин: «Мәхәббәтсез», – дидем, ләкин мәхәббәт төрлечә:*
*Йолдыз ул күктән атылган җиргә, Генрих Гейнечә.*
(«Мәхәббәт шәрхе»).

Мәгълүм булганча, турыдан-туры поэтик чара ролен башкара торган кеше исемнәрендә коннотатив планда бара торган үзгәрешләр күзәтелә, чөнки документаль исемнәр, объектлар халыкка яхшы таныш булу сәбәпле, энциклопедик характерга ия булалар. Шул сәбәпле, документаль исемнәр, номинатив функция башкару белән бергә, тасвирлана торган чор мохитен мәдәни, иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи планда сурәтләүгә дә ярдәм итәләр.

Габдулла Тукай иҗатында кулланылган документаль антропонимнарның, нинди вазифа башкаруларыннан чыгып, түбәндәге төрләрен күрсәтергә мөмкин:

1. Үзләренең төп номинатив функцияләрен башкарган антропонимнар. Бу төр исемнәр Г. Тукай иҗатында күпчелекне алып тора, ул аеруча рус һәм татар шагыйрьләренең исемнәрен еш куллана, иҗатында аларга соклана, алар белән горурлана яисә тыныч кына булган фактны тасвирлый:

*Шигъре Лермонтов вә Пушкин – олуг саф диңгез ул,*
*Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай – өч йолдыз ул.*
(«Җавап»)

*Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек.*
(«Мәкаләи махсуса»).

*Бу җөмләдән А.С. Пушкиннең «Алтын балык» вә «Алтын әтәч» кеби хикәяләрен атап китәргә мөмкин.*
(«Халык әдәбияты»).

2. Тарихи шәхесләргә мөрәҗәгать итеп язылган шигырьләрдә кулланылган антропонимнар.

Мондый шигырьләрдә антропонимнар, гадәттә, үтенү, сорау, соклану хисләре белән үрелеп бара:

*Нәзарыйсыз шагыйрь улдың*
*(афәрин), Пушкин Александр!*
*Бәнем дә дәрде шәүкым һәм сәнең*
*дәрдеңлә якъсандыр.*

(«Пушкинә»).

*Диде Камил ки, я Сәйдәш,*
*оныттым,*
*Яңылдым юлый, яңлыш юлга*
*киттем.*

(«Мөхәммәдия»дән»).

Әлеге шигырендә автор «Бәянелхак» исемле газетаның нашире, атаклы сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшевкә мөрәҗәгать итеп, аның ялгышларын искәртеп яза.

*«Алла, Алла! Саклый күр утдыйн!» –*
*диләр,*
*«Кыл шәфәгать, я Баһаветдин!» –*
*диләр.*

(«Печән базары,
яхут Яңа Кисекбаш»).

Биредә сүз Вәисевләр сәяси төркеменә нигез салучы шәех Баһаветдин Вәисев турында бара.

3. Компаратив конструкцияләрдә кулланылган документаль исемнәр, алар бу очракта «предмет-логик эчтәлек белән байый» [Скворецкая, с. 125]. Мәсәлән:

*Кашың кара «хи» кебек, әлептәге*
*«би» кебек;*
*Сотрудниклар булса булсын*
*Хөҗҗәт, Наурузи кебек.*

(«Авыл җырлары»
дүртенче көлтә).

Бу шигырьдә Хоҗәтел-Хәким Мәхмүдов һәм Вәгыйз Наурузов кебек тарихи шәхесләр күз алдында тотыла.

*Хәтфә калак киштәдә, эшләнүе*
*бистәдә;*
*Морат кебек теләнчене күрәлмассың*
*төштә дә.*

(«Авыл җырлары»
беренче көлтә).

Әлеге шигырьдә сүз Мораделмәкки дигән кеше турында бара. Мәгълүм булганча, татар байлары Мәккә шәһәренә хаҗ кылырга үзләре бара алмасалар, акча биреп, үзләре өчен башка берәүне җибәрә торган булганнар. Шул хаҗга йөрүчеләр арасында Мораделмәкки иң «шомарганнардан» саналган.

4. Фикерне раслау, логик дәлилләү, яки, киресенчә, кире кагу максатында кулланылган кеше исемнәрен дә очратырга мөмкин. Мәсәлән:

*Ул, шуңар ышанып, Тукаев лекция укыячак икән, дип, могтәбәр гәзитәләремезнең берсенә язып та өлгергән.*

(«Игътизар»).

*Алар алдарлар, алдансаң, җәсүр*
*мөфти юк, диярләр;*
*Мәһабәтле, озын буйлы*
*Мөхәммәдъярыбыз бардыр!*

(«Безне урынсыз яманлыйлар»)

*Яза күрмә, җитәр, артык, Тукаев,*
*вастрок бар бит;*
*Куярлар астырып дарга, ятып тор*
*бер дә кузгалмай.*

(«Сорыкортларга»).

5. Кайбер документаль антропонимнар җәмгыятьнең билгеле бер сәяси, мәдәни тирәлеген чагылдыру максатыннан кулланылган. Мәсәлән:

*Җыйла халкы шул канатың астына,*
*Тулды өч йөз ел Романов нәсленә.*

(«Олуг юбилей мөнәсәбәте
белән халык өмидләре»).

Әлеге мисалда автор Романов антропонимын куллану аша шул нәсел идарә иткән чорны, илдәге сәясәтне күз алдына китереп бастыруга ирешә.

6. Сөйләм процессында телгә алынган күренеш, объектның иясен атау максатыннан кулланылган антропонимнар. Мәсәлән:

*Безнең урам аркылы ага суның*
*салкыны;*
*Тарта Казанның яшьләрен*
*Рәмиевләр алтыны.*

(«Авыл җырлары».
Беренче көлтә).

*Мисал өчен мин монда Миргазиз әл-Укмаси җәнабләренең бер «соңгый шигырен» вә башкаларның да берәр шигырен укып күрсәтәм.*

(«Халык әдәбияты»).

7. Аерым бер тарихи шәхесне, затны белдергән антропонимнар, күплек формасын алган очракта, уртак уй-фикер, идея, эшчәнлек нигезендә берләшкән кешеләр төркемен җыеп атау өчен дә кулланыла:

*Безнең милләт тә Пушкиннәргә, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ.*

(«Хиссияте миллия»).

Мондый антропонимнар, бердәнбер, кабатланмас, индивидуаль булулары белән бергә, аерым төркем кешеләргә хас гомуми сыйфатларны да берләштереп, билге буларак кына түгел, ә бәлки характерологик планда да чыгыш ясый торган чор символына әйләнәләр. Шул рәвешчә, документаль исемнәр әдәби текстта гомумилек һәм бердәнберлекне берләштерү сыйфатына ия булалар.

Шулай итеп, галим Л.М. Буштян фикеренә нигезләнеп, шуны әйтергә мөмкин: «...күренекле кешеләрнең фамилиясен генә дә телгә алу җитә, әдәби текст шунда ук поэтик яңгыраш ала» [Буштян, с. 156]. Документаль исемнәрнең әнә шундый мөмкинлекләргә ия булуын яхшы аңлаган Г. Тукай да үзенең антропонимнарны иҗади якын килеп, әсәр тукымасына гармоник үреп куллану осталыгына ия булуын тагын бер кат раслый.

**Әдәбият**

*Буштян Л.М.* Ономастическая коннотация. Одесса, 1973. 230 с.

*Воробьева И.А.* К вопросу о лексическом значении имен собственных // Актуальные проблемы лексикологии: Доклады лингвистической конференции. Томск, 1971. С. 1–9.

*Мурадян И.В.* Антропонимия повести А.С. Пушкина «Капитанская дочь» // Русская ономастика. Рязань, 1977. С. 125–130.

*Скворецкая Е.А.* Компоративное использование собственной имени в русском языке II половины XVIII в // Вопросы русского языка. Рязань, 1971. С. 123–134.

*Щетинин Л.М.* Имена и названия. Ростов, 1968. 215 с.

***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***О.Р. Хисамов, И.И. Хамматуллина***

# Г. ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕНЕҢ ПОЭТИК ОНОМАСТИКОНЫН ӨЙРӘНҮ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

В последние годы в татарской топонимике стало развиваться новое направление, основной целью которого является исследование роли и места омонимов в языке художественных произведений. Как и другие языковые единицы, омонимы здесь приобретают новые функции и смысловые оттенки. В статье рассматриваются особенности поэтического ономастикона поэзии Г. Тукая. В частности уделяется внимание выявлению специфики художественного использования географических названий в произведениях поэта.

**Ключевые слова:** язык произведений Г. Тукая, ономастика, поэтический ономастикон, топонимы, художественно-стилистические средства, символические образы.

Башка тел берәмлекләре кебек үк, топонимнар да әдәби әсәрләр тукымасына килеп кергәч, өстәмә мәгънә төсмерләре белән баеп, яңа функцияләр үти башлыйлар. Моңа кадәр татар тел белемендә топонимнар үз эченә лексик-семантик, структур һәм генетик анализ элементларын берләштергән традицион методология нигезендә өйрәнелеп килде. Соңгы елларда татар топонимикасында ялгызлык исемнәренең әдәби әсәр структурасындагы урынын тикшерүне максат итеп куйган поэтик ономастика дигән яңа юнәлеш үсә башлады. Моңа үрнәк итеп В.М. Гарипова-Хәсәншина (2004), Л.М. Хәмитова (2007) һ.б. хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин.

Теге яисә бу әдип әсәрләренең поэтик ономастикасын өйрәнү фәнни яктан зур әһәмияткә ия. Ул бер яктан язучының индивидуаль тел үзенчәлекләрен ачыкларга, икенче яктан әдәби әсәрләрдә кулланылган сәнгатьчә стиль чараларын билгеләргә һәм әдәбият белән ономастика арасындагы мөнәсәбәт-бәйләнешләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

Топонимнарның сәнгатьчә кулланылыш үрнәкләрен Г. Тукай әсәрләрендә дә күзәтергә мөмкин. Аерым алганда, автор үзенең шигырьләрендә *Казан, Мәскәү, Россия, Бохара, Идел* һ.б. топонимнарга мөрәҗәгать итә. Мәкаләдә әлеге топонимнарның шагыйрь әсәрләрендә сәнгатьчә кулланылыш үзенчәлекләрен ачыклау максат итеп куелды.

Г. Тукайның поэтик ономастиконында төп урынны *Казан* топонимы алып тора. Бу аңлашыла да, чөнки Казан шәһәре элек-электән татар дөньясында сәяси, икътисадый, мәдәни, фәнни яктан зур урын алып торган, аның үзәге саналган.

«Пар ат» шигырендә дә шагыйрь Казанны татарларның рухи мәркәзе, кәгъбәсе буларак сурәтли:

*Әйтә иртәнге намазга бик матур,*
*моңлы азан;*
*И Казан! дәртле Казан! моңлы*
*Казан! нурлы Казан!*
*Мондадыр безнең бабайлар*
*түрләре, почмаклары;*
*Мондадыр дәртле күңелнең хурлары,*
*оҗмахлары.*
*Монда хикмәт, мәгърифәт һәм*
*монда гыйрфан, монда нур*
*Монда минем нечкә билем,*
*җәннәтем һәм монда хур.*

(«Пар ат»).

Шәһәрнең борынгы яшәеш хасияте, аның әһәмияте бер татар дөньясы белән генә чикләнми, бәлки бөтенроссия, Евразия киңлекләре белән билгеләнә. Бу турыда «Казан вә Казан арты» шигырендә телгә алына:

*И Казан шәһре, торасың тауда зур*
*шәмдәл кеби,*
*Мәсҗедең, чиркәүләрең, һәр*
*часларың шәмнәр кеби.*
*Син, үзеңне чорнаган һәрбер өязгә*
*нур чәчеп,*
*Бик мәһабәтле торасың, барчага*
*юл күрсәтеп.*

(«Казан вә Казан арты»).

Шуның белән бергә, *Казан* атамасын шагыйрь үзенең туган ягын сурәтләгән вакытта да куллана:

*Нәкъ Казан артында бардыр бер*
*авыл – Кырлай диләр;*
*Җырлаганда көй өчен «тавыклары*
*җырлай» диләр.*

(«Шүрәле»).

Мисалдан күренгәнчә, *Казан арты* атамасы биредә туган ил, туган як, туган җир символы буларак ачыла.

Г. Тукай шигырьләрендә туган ил, аны сагыну темасы халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш очрый торган *Идел* һәм *Агыйдел* топонимнары ярдәмендә дә ачыла, чөнки тарихи яктан карაганда, алар татарлар өчен әлеге төшенчәнең аерылгысыз өлешләрен тәшкил итәләр [Гарипова, 2011, б. 214–215]:

*... Идел суы агын су – эчәр җире*
*бар микән;*
*Без фәкыйрьне исенә төшереп дога*
*кыйлган бар микән?*
*Идел суы ашлыдыр, ашлы түгел –*
*ташлыдыр;*
*Ташлы булмый кая китсен, безнең*
*күзләр яшьледер.*

(«Солдат бәете»).

*... Унике чана утыным Агыйделгә*
*сал булсын;*
*Елама, әткәй, бәнем өчен,*
*калганнары сау булсын.*
*Безнең илгә барсагыз, сәлам, диегез*
*муллага;*
*Безнең өчен дога кыйлсын кул*
*күтәреп Аллага.*

(«Солдат бәете»).

*Ямьле Агыйдел буенда ат эчердем*
*төшереп;*
*Җаныкаем елый микән бәне исенә*
*төшереп?*

(«Озын эрбет көе»).

*Агыйделләрне кичкәндә, ут күренә*
*аргы якларда;*
*Кайгырмас та иде бу башкаем,*
*әҗәл килсә бала чакларда.*
*Агыйделләрнең буенда атып алдым*
*кытай казларын;*
*Кайгырмасана, газиз башым, бер*
*күрербез Ходай язганын.*

(«Аксак Йосып көе»).

Мәгълүм булганча, үз вакытында татар халкының рухи тормышында Бохара шәһәре мөһим урын тоткан. Гасырлар дәвамында ул татар халкында югары бәяләнгән гыйлем һәм мәгърифәт

учагы саналган. Бу билгеле бер дәрәҗәдә шагыйрь иҗатында да чагылыш таба. «Авыл хатынының бала тибрәткәндәге өмидләре» шигырендә шәһәрнең атамасы үзендә югарыда телгә алынган мәгънә төсмерен ташый:

*Әлли-бәлли итәр бу,*
*Бохарага китәр бу,*
*Бохарадан кайткачтан,*
*Мулла булып җитәр бу.*

Ләкин, шуңа карамастан, Г. Тукай *Бохара* топонимына күп очракта үз чорының тискәре күренешләрен ачып бирү өчен мөрәҗәгать итә:

*Садакать бездә юкмыш, булмаса, ялганыбыз бардыр;*
*Нифак выставкасында күп медаль алганыбыз бардыр.*
*Нәзафәткә ригать юк имеш бездә, нә бөхтандыр!*
*Аның чөн йорт саен безнең берәр комганыбыз бардыр.*
*Тагын бездә гыйлем әһле – зыялылар юк диләр;*
*Утыз еллап Бохар, Каргалыда торганымыз бардыр.*

(«Безне урынсыз яманлыйлар»).

*Сарт китабыннан алынган үрнәге,*
*Назмы шуннан бик мөкәммәл булмады.*
*Монтазам булсынмени соң гаскәрең,*
*Алгач үрнәккә Бохара гаскәрен.*

(«Кисекбаш»ка гыйләвә»).

Шуны ук *Мәккә, Мәдинә* топонимнарына карата әйтергә мөмкин:

*Художниклар вә рәссамнар да бардыр, юк диялмаслар;*
*Мәдинә, Мәккә дип, төрле буяу сатканымыз бардыр.*

(«Печән базары, ...»).

Әлеге очракка үрнәк итеп *Мәскәү* топонимын китерергә мөмкин. Шагыйрь аны чагыштыру чарасы буларак куллана, нәтиҗәдә, җәмгыятьтә күзәтелгән рухи артталыкның ни кадәр тирәнгә киткәнлеге ачып бирелә:

*Үсә, пешә, тәмле була алмагачның алмасы;*
*Сузсаң Мәскәүгә җитәрлек ишаннарның чалмасы...*

(«Авыл җырлары»).

Моннан тыш, Г. Тукайның әсәрләрендә тискәре мәгънә төсмерләрен үзләрендә *Мәкәрҗә* һәм *Печән базары* атамалары да ташый:

*Көнчелек, үчлек белән тулган татарлык,*
*Төяп илтеп Мәкәрҗәдә сатарлык.*

(«Хәзерге хәлебезгә карата»).

*Бер заман бардым Печән базарына,*
*Шунда мин таптым азык язарыма.*
*Иртә белән кайнатмакта бу базар,*
*Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.*
*Йөгерешәләр сөртенә дә абына, –*
*Барча мөэминнәр «Көфер почмагы»на.*

(«Печән базары, ...»).

Топонимнарны шагыйрь сәнгатьчә сурәтләү алымнары буларак кына түгел, ә бәлки җәмәгатьчелеккә үзенең гражданлык позициясен җиткерү, илдә барган сәяси вакыйгаларга мөнәсәбәтен белдерү максатыннан да куллана:

*Иң бөек максат безем: – хөр мәмләкәт, хөр Русия!*
*Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ!*

(«Китмибез!»).

Шул ук максатта, Г. Тукай шигырьләрендә татар мифологиясендә һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә символик мәгънәгә ия булган *Кавказ (Каф тавы)* топонимына да мөрәҗәгать итә. Күпчелек очракта ул әлеге атаманы башка мифологик образлар белән бергә куллана һәм әлеге алым әйтеләсе фикерне тагын да үтемлерәк итә:

*Көн буе яткан иде, үлгән җылан*
*күк, юл тыныч;*
*Чыкты соң кайдан адаштыргыч*
*буран – бу куркыныч?*
*Әллә ычкынганмы баудан Каф тау*
*арты җеннәре?*
*Йә тишелгәнме ходайның бихисап*
*зур мендәре?*
*Кар булып җирдә очамы ошбу*
*мендәр җоннары?*
*Йөгерешеп җан аулый мәллә Каф*
*тау арты җеннәре?*

(«Буран»).

*Каф тавы артында үсә самарау*
*кош баласы;*
*Һинди Минһаҗ шул җирләрдә*
*дарелфөнүн саласы.*
*Ак та була, күк тә була буяучының*
*буявы;*
*«Хөкүмәт яптырды», – дидер*
*наширләрнең уявы.*

(«Авыл җырлары»).

Үзен генә кулланган очракта Г. Тукай әлеге топонимнан чагыштыру алымы буларак файдалана:

*Боларның һәрберсе Каф, яки Кавказ*
*таулары микъдар;*
*Болар ни йотмаган инде, беләмсең,*
*Миңлебай бабай!*
*Матур булыр бу корсакларга каршы*
*чаралар корсак;*
*Тотып ярсак боларны без заман*
*үткәрми, картаймай.*
*Ярыйк дустлар, ярыйк дим, чөнки*
*безнең бәхтебез шунда;*
*Шулар йоткан безнең икъбалебезне,*
*бер дә кызганмай.*

(«Сорыкортларга»).

Әлбәттә, бер мәкалә кысаларында гына чын мәгънәсендә халык шагыйре саналган Г. Тукай шигырьләренең поэтик ономастиконын тасвирлап бетерү мөмкин түгел. Моның өчен аерым фәнни тикшеренү үткәрү сорала. Шуңа да карамастан, югарыда китерелгән мисаллар гына да шагыйрь әсәрләре теленең ни дәрәҗәдә бай, сәнгатьчә камил икәнлеген, аның татар теленең эчке мөмкинлекләреннән никадәр оста һәм нәтиҗәле файдаланганлыгын күрсәтеп торалар.

**Әдәбият**

*Тукай Г.* Әсәрләр. Биш томда. I том. Шигырьләр, поэмалар (1901–1908). Казан: Татар. кит. нәшр.., 1985. 405 б.

*Тукай Г.* Әсәрләр. Биш томда. II том. Шигырьләр, поэмалар (1909–1913). Казан: Татар. кит. нәшр.., 1985. 399 б.

*Гарипова Ф.Г.* Габдулла Тукай иҗатында географик атамалар кулланылышы // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бaгланышлар: Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (25 апрель, 2011 ел). Казан, 2011. 315 б.

*Гарипова-Хәсәншина В.М.* Поэтическая ономастика прозы Гумара Баширова: дис. ...канд. филол. наук. Казан, 2004. 241 с.

*Хамитова Л.М.* Поэтический ономастикон в татарских детских стихотворениях: на материале художественных текстов Шауката Галиева и Роберта Миннуллина: дис. ...канд. филол. наук. Казан, 2004. 208 с.

***Хисамов Олег Ришат улы**,*
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары*

***Хамматуллина Инзилә Илнур кызы**,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге аспиранты*

УДК 811.512.145

*Э.Н. Денмөхәммәтова*

# Г. ТУКАЙНЫҢ МӘГЪНӘДӘШ СҮЗЛӘРНЕ КУЛЛАНУ ОСТАЛЫГЫ

В сокровищнице поэтического наследия великого татарского поэта Габдуллы Тукая хранятся уникальные творения его бессмертного таланта, олицетворяющие собой свод культурных ценностей и сложных лингвокультурологических проблем эпохи. В их основе лежат разнообразные экстралингвистические и интралингвистические факторы. Каждый из этих факторов по-своему обусловливает конкретную специфическую особенность употребления в произведениях Г. Тукая лингвокультурологических концептов. К числу таких ценностных конструкций его поэзии относятся синонимы. В них посредством компактных словесных единиц в малых лингвохудожественных формах происходит синтез многих языковых особенностей своей эпохи.

**Ключевые слова:** язык произведений Г. Тукая, художественно-образная реализация системы языка, лексическая система, синонимы, художественно-образные конструкции, слова тюрко-татарского происхождения, арабо-персидские заимствования.

Күренекле татар шагыйре Габдулла Тукайның шигъри хәзинәләрендә әлегә кадәр тикшерелмәгән меңләгән тел җәүһәрләре саклана. Алар, шагыйрьнең үлемсез талантын кабат дәлилләп, ул яшәгән чорның мәдәни кыйммәтләрен һәм катлаулы лингвокультурологик проблемаларын бүгенге тормышыбыз өчен актуаль мәсьәләләр җирлегендә безгә җиткерә. Г. Тукай иҗаты белән танышу күп төрле сорауларга җавап табарга ярдәм итә, ә теге яки бу концептның барлыкка килү, формалашу һәм Тукай иҗатында ни рәвешле чагылышын өйрәнү исә бөек шагыйрьнең сүз уйнату һәм тирән мәгънә белдерү осталыгын кабат раслый. Татар халкына хас әдәби фикер тирәнлеге, туры сүз, үткен теллелек, XX йөз башы татар шигъриятендә киң таралган сүз уйнатудагы сыгылмалылык һәм шул ук вакытта кискенлек – болар барысы да бөек шагыйрь иҗатында да урын ала, һәм XX гасыр башы татар лингвомәдәниятен тасвирлый торган тел җәүһәрләрен тәшкил итә. Шундый берәмлекләр исәбенә мәгънәдәш сүзләрне дә кертеп карыйлар.

Элек-электән теге яки бу телне камил белү күрсәткечләренең берсе булып, мәгънәдәш сүзләрдән дөрес файдалану саналган. Шунлыктан синонимнарга күп тел белгечләре, язучылар һәм әдәби тәнкыйтьчеләр зур әһәмият биргәннәр, синонимнарның телне баету, фикерне төгәл һәм анык бирүдәге рольләрен күрсәтеп килгәннәр, сүзләрне үз мәгънәсендә, әйтәсе фикерне гади, җыйнак итеп бирерлек формада кулланырга чакырганнар. Г. Тукай шигырьләрендә урын алган мондый

берәмлекләрне өйрәнү исә авторның, шигъри аһәңлелеккә ирешү өчен, тон һәм семантик төсмерләрдән бик оста файдалануын, синонимнардан уңышлы комбинацияләр төзүен, сүзләр гармониясенә ирешүен күрсәтә. Шул рәвешле ул укучының күзаллавын киңәйтүгә, күбрәк ассоциацияләр тудыру мөмкинлегенә ирешә.

Шагыйрь кулланган мәгънәдәш берәмлекләрне бары контекст эчендә генә тикшерергә мөмкин, чөнки алар тулы бер образның эстетик ягын чагылдырган кисәкчекләр булып торалар. Шунлыктан текстның лексик һәм семантик системасында синонимнар максатчан хәрәкәттә күзалланалар.

Шуны да искәртеп үтү зарур: Тукай иҗатында синоним берәмлекләр уртак, охшаш мәгънә белдереп кенә калмыйлар, ә билгеле бер аермалыкларга ия булган берәмлекләр буларак та уңышлы кулланылалар. Тел белеме фәнендә мәгънәдәш сүзләрне абсолют, парлы, семантик һәм якын мәгънәле берәмлекләргә бүлү бар. Нәкъ шул берәмлекләр ярдәмендә фикернең концептуаль вазифасы башкарыла.

Абсолют синонимнар (икенче төрле аларны тулы синонимнар яки дублетлар дип тә йөртәләр) тел берәмлекләре арасында артык күп булмый, ә шигъриятнең катгый кануннарын исәпкә алганда, аларның саны тагын да кими. Нигездә, мондый берәмлекләр телнең үз сүзләре һәм алынма берәмлекләр исәбенә тулылана. Мәсәлән, *яз (весна) – бәһар; кояш (солнце) – шамс; йөз (лицо) – бит, чәһрә, чырай.*

Абсолют синонимнар Тукай шигырьләрендә күп очракта субъект һәм объектларны белдерү-атау чарасы буларак файдаланыла. Шулай ук билгенең сыйфатын, санын-күләмен, предметның билгесен белдерү өчен һ.б. максатлардан да кулланылалар. Бу аларның поэтик характеристикалары булып тора. Мәсәлән, югары яки әдәби стильдә *кояш* сүзе *шәмс* берәмлеге белән, яки *йөз* сүзе *бит, чәһрә* синонимнары белән алыштырылса, текстның эчтәлегенә һич тә хилафлык килми; автор поэтик текстның ритм һәм рифма мөмкинлекләреннән чыгып, шул берәмлекләрне сайлый:

*Язлар җитте, карлар эри*
*башладылар,*
*Толыплылар толыпларын*
*ташладылар...*
(«Яз галәмәтләре»)

*Шулай йоклап, бәһар җиткәндә*
*торсам,*
*Торып тагы яшел җирдә утырсам...*
(«Күз»)

Мисаллардан күренгәнчә, *яз* һәм аның *бәһар* синонимында стилистик аерма күзәтелә, семантик төсмер дә чагылыш таба. Шулай булуга да карамастан, аларда тулы мәгънәдәшлек бар.

Парлы синонимнар үзләренең ясалышлары белән аерылып торалар. Бу очракта мондый берәмлекләр *вә, һәм, илә* тезүче теркәгечләре ярдәмендә барлыкка килә һәм һәр берәмлек, билгеле бер урында, үз семантик вазифасы белән кулланыла. Синоним берәмлекләр урыннары белән алышына алмыйлар, чөнки бу парлы синоним элементларының

аһәңен һәм экспрессив яктан үзара ярашуын югалтырга мөмкин.

*Кайвакыт Мәҗнүн кеби көлмәс вә шатланмас идем, –*
*Син агач ат өстенә атландыручы булмаса!*
(«Син булмасаң!»)

*Син бүлеш, сөйсәң мине, гыйльмең вә гыйрфаның белән;*
*Нәрсә белсәң дә, икәү уртаклашыйк аның белән.*
(«Шиллердән»)

*И карендәш! Син, кирәксә, суга бат йә сөткә бат!*
*Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сөббат!*
(«Сөткә төшкән тычкан»)

Парлы синонимнар барлыкка китерүдә, аеруча, *вә* яки *һәм* тезүче теркәгечләре еш кулланыла. Алар, беренче лексема белдергән мәгънәне аныклап, икенче лексик берәмлекне теркиләр. Шул рәвешле фикерне шигъри формада җиткерү өчен, персонажның халәтен, хәл яки вакыйганың ничек булуын тасвирлаганда бик актив кулланылалар. Тукай шигъриятендә парлы синонимнар түбәндәге берәмлекләр исәбенә барлыкка килә:

а) укучыга фикерне төгәлрәк җиткерү максатыннан, татар әдәби теле берәмлекләре бер-берсен аныклап киләләр:

*«Йөземнәр чи, әле өлгермәгәннәр, пешмәгәннәр, – ди.*
*Бозарсың ашказаныңны, килешми эчкә анлар!» – ди.*

(«Төлке һәм йөзем җимеше»)

Кайчакта автор мондый синонимнарны парлы сүз составында куллана һәм лексемаларның мәгънәви вазифасын арттыра.

*Безгә ят-чит телдәге изге фикерне тәрҗемә*
*Биш вакытта биш намаз күк керде инде фарзыма.*
(«Буш вакыт»)

*Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син,*
*Чын сөбатлә алга бардың, бакмый уңга-сулга син.*
(«Даһигә»)

ә) Парлы синонимнарның күпчелегендә беренче компонент – төрки-татар сүзе, икенчесе – гарәп яки фарсы берәмлегенә булган калыплар урын ала. Мәсәлән, татар телендәге *тел* берәмлеге гарәпчә – *лөгать* буларак кулланыла. Автор аларны түбәндәгечә файдалана:

*Рус белән тормыш кичердек сайрашып,*
*Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.*
(«Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре»)

б) Ике яки күбрәк гәрәп-фарсы берәмлегеннән торган парлы синонимнар да Г. Тукай иҗатында урын ала.

*Гыйззәтем бу, кадрем бу.*
*Минем йөрәк бәгърем бу;*
*Куанычым, шатлыгым –*
*Бу, бу минем бу, бу, бу.*
(«Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре»)

*Шунда белдем Рәсүлемез Мөхәммәтне,*
*Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.*
(«Туган авыл»)

Семантик (идеографик) синонимнарга тукталганда, шуны әйтергә мөмкин: мондый берәмлекләр Г. Тукай шигырьләрендә мәгънә төсмерләре белән ае-

рылып торалар. Автор, сүзнең эчке мәгънәсенә басым ясау, лексеманы тагын да тирәнрәк аңлату, синонимның яңа төсмерен белдерү һәм поэтик системада контекстуаль урынын билгеләү максатыннан, семантик мәгънәдәш сүзләрне күпләп куллануга өстенлек бирә.

*Мөкаддәс ул, бөек ул, гали зат ул,*
*Тәмам хөр ул, вә бик киң ул, азат ул.*
(«Театр»)

Мисалдан күренгәнчә, *мөкаддәс, бөек, гали* барысы бер уртак мәгънә белдерә, ә *хөр, азат* лексемалары ирекле дигәнне аңлата. Әмма алар мәгънәви һәм стилистик төсмерләре белән аерылалар. *Мөкаддәс* сүзе дини семантикага ия һәм *изге* дип тәрҗемә ителә ала; *гали* киңрәк мәгънәдә *бөек, билгеле*, танылган дип аңлатыла, ә *бөек* сүзе бу синонимик рәттә доминанта ролен үти. *Хөр* лексемасында нәрсәдән, кемнән дә булса тулы бәйсезлек мәгънәсе өстенлек итә, ә *азат* сүзе ирекле семантикасы белән кулланыла.

Г. Тукай иҗатында якын мәгънәле, бер үк төшенчәне белдерә торган синонимнарны да очратырга мөмкин. Мәсәлән,

*Кайда китте цензурлык,*
*Коллык, тарлык, ким-хурлык?*
(«Хөррият хакында»)

Шул рәвешле, *коллык (рабство), тарлык (стеснение прав) и ким-хурлык (унижение)* берәмлекләре семантик яктан бер-берсенә якын торалар, әмма мәгънә төсмерләре белән шактый аерылалар: *коллык* – тулысынча буйсыну, ирексезлекне белдерә; *тарлык* берәмлегендә ирекнең чикле булуына басым ясала; *ким-хурлык* исә кемдер тарафыннан кимсетелүне белдерә.

Г. Тукай шигырьләрендә берберсенә якын мәгънәле сүзләр билгеле бер дәрәҗә (статус) белдерү рәвешендә дә урын алалар:

*Шәкерт, студент – бары,*
*Дарга асылганнары, –*
*Сез бу арысланнарны*
*Онытмагыз тик дия.*
(«Хөррият хакында»)

Бу мисалда *шәкерт* (мәдрәсәдә укучы) һәм *студент* (гимназиядә яки югары уку йортында укучы) берәмлекләре уртак синонимик мәгънә белдерә, ләкин контекст эчендә һәрберсе өстәмә семантик һәм стилистик төсмер ала. Шигъри юлларда алар бер-берсен тулыландырып киләләр һәм үз шигъри кулланылу үзенчәлеген саклыйлар, шунлыктан Г. Тукай иҗатында синонимнарны мәгънә уртаклыгы гына түгел, ә контекстта кулланылу үзлеге дә берләштерә дип әйтергә мөмкин.

Гомумиләштереп әйткәндә, синонимнарның ясалу, кулланылу төрлелеге һәм күплеге Г. Тукай иҗатының үзенчәлеген тәшкил итә. Синонимнар шагыйрь каләме ярдәмендә төрле составта, күләмдә һәм күптөрле комбинацияләрдә кулланылалар һәм үзләренең стилистик вазифаларын бик уңышлы үтәүгә ирешәләр. Бу, һичшиксез, авторның зур казанышы булып тора.

**Әдәбият**

*Брагина А.А.* Синонимы в литературном языке. М.: Русский язык, 1954. 127 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. Казан: Хәтер, 1999. Б. 36–51.

*Сәгыйтов Р.* Татар теле синонимиясендә гарәп-фарсы алынмалары // Мәгариф. 1992. № 10. Б. 22–23.

*Ханбикова Ш.С.* Синонимнар сүзлеге. Казан: Хәтер, 1999. 256 б.

*Ханбикова Ш.* Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 280 б.

***Денмөхәммәтова Эльвира Николай кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының гомуми һәм төрки тел белеме кафедрасы доценты*

УДК 821.512.145

***Н.Ш. Хисамов***

# ТУКАЙНЫҢ ШИГЪРИ ФИКЕРЛӘВЕНДӘ ШӘРКЫЙ СУРӘТЛӘР

В статье рассматриваются образы в поэтике Тукая, основанные на традициях мусульманского Востока. По мнению автора статьи, в произведениях Тукая традиционные восточные образы используются не только в простом контексте, но и в преломлении различных смысловых связей, образных выражений. В поэтической системе подобные образы занимают незначительное место, однако Тукай мастерски интерпретирует их в своих произведениях.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, поэтика, традиции, образы.

XX йөз башындагы татар барышының тизләтелгән үсешендә аның бер чагылышы һәм шарты итеп Көнчыгыш-Көнбатыш синтезын саныйлар. Бу күренеш шул чор шигъриятенең барлык күренекле вәкилләрендә дә, иң беренче нәүбәттә Тукайда, Дәрдемәндтә һәм Сәгыйть Рәмиевтә күзәтелә.

Әмма синтез ике нигезнең дә бер тигез булуы дигән сүз түгел. Бу процесста Шәрекътән килә торган традиция төп нигезне, үзәк чишмәне тәшкил итә. Күпгасырлык татар классик шигърияте дә шул ук мәдәни төргә, шул ук культура даирәсенә керә.

Тукайның тулысынча диярлек гарузга нигезләү шигърияте һәм ритмик сурәт, һәм шигъри фикерлегенең идея-фәлсәфи конструкциясе, һәм сурәтле-бизәкле гәүдәләнеше җәһәтеннән, асылда, Шәрекъ шигъри күренеше булып тора. Шәрекъ шигъриятенең исә әйдәүче үзәк сыйфаты – традиционлык. XX йөз башы татар шигъриятенең шушы бөек вәкиле әлеге традицион җирлектә һәм система эчендә даһиларга хас новаторлык чалымнары ясый. Ул традицион шәркый сурәтләрне үзләренең сыналган һәм гадәти контекстында куллану белән бергә бөтенләй көтелмәгән, кайвакыт хәтта сәер тоелырлык мәгънәви бәйләнышларга алып керә, үтә тәвәккәл сурәт хәрәкәте һәм борылышларын бирә.

Гасырлар дәвамында тотрыклы традицияләр өстенлек иткән шигъри системада сурәтләр саны бик күп булмый. Әмма таланты көчле булган бөек шагыйрьләр шул сурәтләрне виртуоз оста дәрәҗәсендә уйнаталар. Тукай шигъриятендә дә Шәрекътән килгән сурәтләр хисапсыз түгел. Аларның иң күбесе Мөселман Көнчыгышының дөньяга карашын, яшәүгә, әхлакка мөнәсәбәтен билгеләгән ислам дине төшенчәләреннән тора. Иң беренче урында, әлбәттә, илаһиятне гәүдәләндергән төшенчәләр: Алла, Коръән төшенчәләре кулланыла. Аннары фәрештәләр, пәйгамбәрләр килә. Тормышның кызу казанында кайнаган,

иҗтимагый һәм фикер көрәшенең үзәгендә хәрәкәт иткән шагыйрь өчен XX йөз башының трагик коллизияләрен йөрәге аша уздырганда, дини әдәбиятның негатив символлары – Иблис, шайтан сурәте калкып чыга. Алар үзләренең табигый контекстында кулланылу белән бергә, бөтенләй көтелмәгән, парадоксаль контекст та хасил итә. Менә Тукай лирикасының җитлегеп кристаллашкан дәвереннән бер үрнәк.

*Туйса Иблис тормышыннан, яд итә*
*оҗмахларын, –*
*Яд итәм, бизсәм үземнән, мин*
*сабыйлык чакларын.*
*И күңелнең шаулап аккан чишмәдән*
*сафрак чагы!*
*И гомернең нурланып үскән яшел*
*яфрак чагы!..*
*Чәчмәгән җир күк – күңелнең һәр*
*гүзәлгә бушлыгы,*
*Тик кояшны һәм табигатьне*
*сөюдән хушлыгы!*

Монда нәрсә нәрсәгә каршы куела? Тормыш авырлыклары, борчулар һәм гөнаһ баскан лирик каһарман шәхесе – аның ваемсыз, саф балачагына. Һәм шуңа параллель итеп шагыйрь гөнаһ вә вәсвәсә гәүдәләнеше Иблисне ала. Дөресрәге, шагыйрьнең, лирик каһарманның халәте шушы модель, шушы сурәт нигезендә ачыла. Моны XX йөз башы шагыйре генә эшли ала. Урта гасыр булса, дин һәм гавам аңында каһәрләнеп килгән бу зат белән үзен тиңләштергән өчен шагыйрьне кичермәсләр иде. Бу төшенчәләрне янәшә алуның җирлеген Тукай гуманизмыннан эзләргә кирәк. Ул әлеге затта, үзенең шул чордагы халәтенә хас фаҗигалелек, трагизм күрә. Үз-үзеннән тую, бизү мизгелләре аны саф балачагыннан, үткәннәреннән якты хатирә эзләп юануга этәрә. Баланың дөньяга мөнәсәбәтендәге сафлык, яктылыкка, шуны гәүдәләндергән сурәтләрнең нәфислегенә карагыз! Һәм шул халәтне фәлсәфи төшенү, шуның фәлсәфи сурәте нинди тирән!

Тукайның бала сурәтен күзаллавы, аның лирикасында бала һәм балачакның яктыртылуы – үзе бер зур тикшеренү темасы. Сез шигырьләрнең исемнәренә генә карагыз: «Бала оҗмахта», «Сагыныр вакытлар» һ. б.

Сабый төшенчәсен фикердән кичергәндә, Тукай кешелекнең иң бөек гуманистлары, нәфислектә иң камил сәнгатькәрләре югарылыгында эш итә.

Сабыйга эндәшеп язган «Таян аллага» шигырендәге шушы юллардан да өстен камиллек булырга мөмкинме икән?!

*Пакь җаның һәм пакь тәнең –*
*барлык вөҗүдең пакь синең;*
*Син фәрештә валчыгысың,*
*йөзләрең ап-ак синең!*

Әдәбиятка ислам аша кергән төшенчәләр шагыйрьнең мәхәббәт лирикасында киң урын ала. Мәсәлән, гашыйк кешенең сөеклесе каршындагы халәтен ул намазга оеган гыйбадәтче рәвешендә сынландыра. Әйтик, әле генә уен-көлке сөйләп утырган гашыйк каршына җанашы керә, һәм егет шундук җитдиләнә, үзгәрә:

*Нишләсен, җанаш хозурында аңар*
*лазем намаз;*
*Бер азан әйткәч, колак каккач,*
*мөселман уйнамас.*

Тукайның мәхәббәт шигырьләрендә сөеклесенең сурәте иң изге биеклеккә күтәрелә. Чагыштырулар да дини тәкъвалык күзлегеннән гафу ителгесез күренерлек тәвәккәлләр. Шагыйрьнең бу өлкәдә кыюлыгы шул дәрәҗәгә барып җитә ки, ул Коръәндәге «ля шәркыя, ля гарбия» (Шәрекътә дә, Гаребтә дә юк) гыйбарәсен сөеклесенә мәдхия, дип шәрехли:

*Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияңи? –*
*Ул синең васфеңдә: «ля шәркыя, ля гарбия», – ди!*

Мәхәббәт – гомумән, Тукай өчен илаһи хис. Ул аның чыганакларын, урынын гел күктән эзли. «Йолдыз ул күктән атылган җиргә, Генрих Гейнечә», – ди «Мәхәббәт шәрхе» шигырендә. Әйе, Һенрих Һәйне шигъриятенең рухын, аңардагы «мәхәббәт шәрхен» Тукай дөрес төшенгән. Шагыйрьнең лирик сурәтләре, чагыштыру һәм метафораларының илаһи төшенчәләр даирәсеннән алынуы әлеге хискә әнә шушындый карашыннан килеп чыга. Аның яшьлек шигырьләре арасында «Дәрдемәнд дәгелмием?» дигән камил бер әсәре бар. Анда мондый юлларны укыйбыз:

*Тәңре гыйшкында шәһадәт итсәләр дәр Гәрбзла,*
*Бән шәһидем дәр мәхәббәт, дәр бәлаем, нәйләем.*

(Аллага гыйшык юлында Гәрбәладә шәһит булсалар,
Мин мәхәббәт, бәла юлында шәһитмен, – ди.)

Гәрбәла – Гыйрактагы бер шәһәр. Анда өмәвиләр кулыннан хәзрәте Галинең уллары – Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныклары Хәсән-Хөсәен һәлак булалар. Шигыйләр анда хаҗга йөри. Тукай мәхәббәт юлында корбанга әзерлеген менә шушы шәһитләр язмышына һәм ихтыярына тиңли. Шул рәвешчә, ислам тарихы фактлары аның шигъри фикерләвендә югары әхлакый-эстетик кыйммәткә ия чагыштыруга, мәгълүм дәрәҗәдә шигъри оппозиция, антитеза элементына әверелә.

Тукайның шигъри фикерләү тирәнлеге даими ачыклауга, шәрехләүгә мохтаҗ. Без шулар аша гына аның даһилык колачын тулырак иңли алачакбыз. «Көзге җилләр»дәге гади искәрмә белән чикләнеп узыла торган шушы юлларга күз салыйк әле:

*Тилмереп торса бу ачлар, безгә бәйрәмнән ни ямь?!*
*Мәркадендә чөнки Ибраһим вә Исмәгыйль җылый.*

Тәүрат һәм Коръән аша Ибраһим вә Исмәгыйльнең пәйгамбәрләр булуын беләбез. Ләкин алар ни өчен «елый»? Чөнки сүз илдәге ачлык чорына туры килгән корбан гаете хакында бара. Бу бәйрәм – Ибраһим белән Исмәгыйльнең шатлык бәйрәме. Беренчесе үзенең Аллага тугрылыгын улын корбан итеп раслау мәҗбүриятеннән, зарурлыгыннан котылган, икенчесе исән калган. Һәм шушы вакыйга легенда күләмендә илаһияткә тугрылыкны ятимнәр һәм фәкыйрьләр хакында кайгыртып раслау дәверен башлап җибәрә. Корбан гаете – асылда шатлык бәйрәме,

шәфкать, мәрхәмәт бәйрәме. 1911 елны Идел буендагы ачлык бәйрәмнең әнә шул мәгънәсен юкка чыгара. Бәйрәмгә нигез салган пәйгамбәрләр шунлыктан елый. Даһи каләменнән чыккан гади генә ике юл ил һәм кешелек күләмендәге шушы тирән фаҗигане чагылдыра.

Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасына караган кайбер әсәрләрендә Көнчыгышның легендар каһарманнары белән чагыштыру градация рәвешендә дини әдәбият персонажлары белән янәшәлектә алына, ул янәшәлекләр исә классик фарсы шигърияте стилендә сурәтле хәрәкәткә китерелә. «Бер рәсемгә» шигырендә, мәсәлән, ул болай:

*И кояш! ямьсезлегеңнән син*
*оялырсың, беләм,*
*Гәр чагыштырсаң йөзеңне син бу*
*бит алмасына.*
*Күрсә яңлыш бу матур кызның*
*фәкать рәсмен генә,*
*Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә*
*үз Ләйләсенә.*
*Булсайде оҗмах түрендә әүвәл үк*
*рәсме моның,*
*Илтифат итмәс иде Адәм дә үз*
*Хаувасына...*
*Күрсәйде Иблис ләгыйнь дә, кайда*
*баш тартып йөрү!*
*Баш иярди сәҗдәгә, кайтып тагын*
*алласына.*

Шушы сурәт-төшенчәләр шагыйрьнең хис-кичереш дөньясы киңлеген, аның күз күреме җитмәслек чикләрен сыза, абсолют дәрәҗәгә ирештерә. «Кулың» шигырендә ул кызның кулына карата: «Бер фәрештә күңледәй пакьтер кулың», – ди. Аның сафлыгын, гүзәллеген, камиллеген ул шушындый сәмави, изге төшенчәләр аша күрә. Мондый чагыштыру һәм парадокслар шагыйрьнең үз күңелен, аның чиксез киңлеген, сафлыгын, бөтенлеген төсмерләтә.

Тукай үтә нечкә хисләргә сугарылган мәхәббәт шигырьләрендә дә традицион гыйшык каһарманнары сурәтен үз чорының иҗтимагый-мәдәни төшенчәләренә үреп бирә. «Мәхәббәт» шигырендә аның шундый юллары бар:

*Барча әхраре мәхәббәт миннән*
*уңда, зан итәм, –*
*Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! –*
*мин аларның таңчысы!*

Игътибар итегез: XX йөз башы татар җәмгыятендәге уңнар, суллар, ягъни радикаллар һәм соңгыларының Гаяз Исхакый катнашындагы «Таң» гәзите шушы нәфис мәхәббәт шигыре каһарманының нинди ашкындык белән януын төсмерләтә. Әдәбиятның камил сурәтләре янына шагыйрь үз чорының кискен иҗтимагый агымнары һәм шуның иң күренекле гәүдәләнешләре булган затларны янәшә куя, шул үрелеш аша үз сурәтенең зурлыгын, хис кайнарлыгын шәйләтә.

Көнчыгыш шигъриятендә гасырлар дәвамында төрләнderелгән шаһлык-коллык нисбәтен шагыйрь сөеклесен олылау һәм гүзәл хатын-кыз дәрәҗәсен данлау өчен файдалана.

*Һич хуҗалыкны кабул итмәм*
*бөтен дөньяга мин,*
*Булмага мөмкин икән гыйшык,*
*мәхәббәт ялчысы.*

Шагыйрьнең кол булуын ул бары гүзәл кыз каршында гына аклый:

*Һич килештермим синең төсле*
*гүзәллек шаһына,*
*Ичмасам, бер хисле шагыйрь дә*
*килеп кол булмаса.*

Ләкин, гомумән, шагыйрьнең мохиткә, түбән дөньяга баш июен ул кискен кире кага.

**Әдәбият**

*Тукай Г.* Әсәрләр: биш томда.

*Хисамов Н.* Тукайны төшенү юлында: «Габдулла Тукай» энциклопедик белешмәсенә материаллар. Казан: ТаРИХ, 2003. 80 б.

***Хисамов Нурмөхәммәт Шаһвәли улы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге*
*баш фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***З.З. Рәмиев***

# ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ХАКЫНДА

В статье речь идет о первой татарской персональной литературной энциклопедии, посвященной великому татарскому поэту, сатирику и публицисту-журналисту Габдулле Тукаю (1886–1913), включающей 2358 статей, кратко анализирующих его поэзию, прозу и публицистику, литературное и бытовое окружение, творческую связь с предшественниками и последователями, а также отражение сюжетов и образов его произведений в различных отраслях искусства Татарстана.

**Ключевые слова:** энциклопедияя, Г. Тукай, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, тукаеведение

Менә ни гомер инде татар халкы Тукай тудырган шигъри дөнья белән аерылгысыз бәйләнештә яши! Бактың исә, икенче гасырга чыкканбыз. Торган саен бөек шагыйрь иҗатының хиссификери тирәнлеге тулырак ачыла, милли йөзебезне саклаудагы, рухи дөньябызны баетудагы бәяләп бетергесез әһәмияте артканнан-арта бара. Бу җәһәттән шагыйрь дөньясы серлелеген фәнни-нәзари күзлектән чыгып анализлауның роле дә гаять зур. Әлеге олы мирасны шәрехләү тарихы да йөз елдан артты инде. Заманалар барышында илебез тормышында булып торган кискен иҗтимагый үзгәрешләр аңа ничек кенә йогынты ясамасын, Тукай шәхесен һәм иҗатын гыйльми өйрәнү һаман саен тирәнәя барды. Бөек шагыйребез мирасын һәрьяклап игътибар үзәгенә алу бүгенге татар әдәбият белеменең иң мөһим тармакларының берсен тәшкил итә.

Фән дөньясында тупланган зур тәҗрибә аерым бер әдип иҗатын өйрәнүнең максатка ярашлы юлы итеп персональ энциклопедияләр төзүне саный. Татар җәмәгатьчелегендә дә сөекле шагыйребез Габдулла Тукайга мөнәсәбәтле шундый әдәби энциклопедия төзү мәсьәләсе туган иде. Моны беренчеләрдән булып 1980 еллар ахырында ук Н. Юзиев, Ә. Кәримуллин, Ф. Мусин кебек галимнәр күтәреп чыктылар. Ниһаять, Татарстан бәйсезлеге игълан ителү, хокукый мөмкинлекләр арту, шул исәптән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе төзелү дә халкыбызның бөек улына багышланган энциклопедияне гамәлгә кую юнәлешенә беренче адымнар ясауга юл ачты. Билгеле, татар гуманитар фәне дөньясында моңа кадәр мисле күрелмәгән мондый зур эшне башкарып чыгу җиңел булмаячагы да ачык беленеп тора иде. Чөнки мондый хезмәт – персональ әдәби энциклопедия бездә беренче мәртәбә башкарыла. Татар галимнәренең бу юнәлештәге тәҗрибәләре дә әллә ни зурдан түгел, үзләрен Тукай иҗаты буенча белгеч итеп таныткannar

да аз, фикерләүдә совет чорыннан килгән идеологик аспект та әле тулысынча алып ташланмаган. Энциклопедияне төзү эшен җитәкләгән Н. Юзиев, рус һәм башка телләрдә чыккан мондый хезмәтләрне өйрәнеп, мәсьәләгә аеруча җитди килеп, хәзергәчә камил саналган Лермонтов энциклопедиясен өлге сыйфатында алырга тәкъдим итте.

Шулай ук Н. Юзиев инициативасы Татарстан Фәннәр академиясе җитәкчелегендә хуплау тапты һәм энциклопедиянең бернечә галим катнашында төзелгән лөгатьлеге – «Мәкаләләр исемлеге» анның әдәбият буенча фәнни советында тикшерелеп куллануга кабул ителде. Эш барышында энциклопедиянең сигез тематик юнәлешкә караган материалны эченә алачагы ачыкланды. Аларның һәрберсе Тукай феноменын, Тукай дөньясы серләрен ачуга хезмәт итәргә тиешле булды. Бүген инде әлеге планнар чынга ашты дип әйтергә дә мөмкин, энциклопедия төзелеп басмага тәкъдим ителде.

Хезмәтнең структур корылышы түбәндәгечә: беренче тематик юнәлеш – әдипнең шигъри, сатирик, публицистик, гомумән, анның каләменнән чыккан, басылган яисә кульязма хәлендә генә калган һәр әсәрен аерып алып анализлаган, фәнни-нәзари ноктадан шәрехләгән, темасы, проблематикасы, сюжет бирелеше, сәнгати үзенчәлеге һ.б. хосусыятьләре тикшерелгән мәкаләләрдән тора. Барлыгы 780 мәкалә. Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр дә, соңгы елларда табылган, я, булмаса, совет идеологиясе басымы астында шагыйрь әсәрләренең күптомлы басмаларыннан читләштерелгән сатирик, публицистик чыгышлар да өйрәнелде. Һәр мәкаләдә кыскача әсәрнең жанры, шагыйрь исән чакларда кайда һәм кайчан басылуы, кайсы томлыкка беренче мәртәбә кертелүе, кемнәр тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителүе, аңа ияргән назыйрә, пародияләрнең булу-булмавы, әсәрнең музыкада, рәсем, театр сәнгатендә чагылышы хәбәр ителә. Ахырда чыганак һәм әдәбият исемлеге күрсәтелә.

Икенче тематик юнәлештә Тукай иҗаты татар әдәбият белеме мәсьәләләре белән бәйләнештә, гомуми, проблематик планда карала. Ягъни, Тукайның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләре, анның лирикасы, жанрлары, иҗат методы, ысулы, стилистик алымнары, шулай ук дини-әхлакый карашлары игътибар үзәгендә тора, халыкчанлык, миллилек һ.б. мәсьәләләр тикшерелә.

Өченче тематик юнәлештә сүз шагыйрьнең бабалары, ата-анасы, кан-кардәшләре, иптәшләре, дуслары, танышлары, замандашлары (әдипләр, журналистлар, баширләр һ.б.), укытучылары, шәриктәшләре турында бара, әмма барлык төр мәгълүматларның Тукайга мөнәсәбәтлеләре генә бирелә. Әлеге юнәлештәге мәкаләләр һәм белешмәләр өчен төп чыганаклар булып «Исемдә калганнар» автобиографик повесте, замандашлары язып калдырган шагыйрь турындагы хатирәләр, истәлекләре, китапханә, архив, музей фондларында саклана торган доку-

ментлар хезмәт итте. Билгеле ки, һәр очракта да фактик төгәллеккә ирешү мөмкин түгел. Шулай да авторлар алдында торган иң мөһим бурыч теге яки бу затның Тукай шәхесе белән бәйләнешен бары тик кәгазьдә теркәлгән фактларга нигезләнеп кенә яктыртудан гыйбарәт иде.

Дүртенче тематик юнәлештә Тукай иҗатын татар әдәбияты белән бәйләнешләре яссылыгында шәрехләү ачык күренеп торырга тиеш иде. Мәкаләләрдә Тукайның урта гасырлар төрки-татар әдипләре иҗатына мөнәсәбәте, замандаш язучылары белән реаль тормышта һәм иҗат мәйданында «очрашуы»на нисбәтле яклар, Тукай шәхесенә, иҗади мирасына, традицияләренә үзенчәлекле фикер-карашларын гәүдәләндергән әсәрләр турында сүз бара. Соңгы елларда бөек шагыйрь иҗаты белән бәйләнеше тикшерерлек әдипләр даирәсе киңәя төште. Әлеге бүлектә Тукайның татар, рус һәм чит телләрдәге вакытлы матбугат органнары, матбага-нәшриятлар белән бәйләнешын тикшергән мәкаләләр дә урын алды («Фикер», «Уклар», «Әлгасрелҗәдид», «Ялт-йолт» һ.б.). Бу мәкаләләр фактик мәгълүматларны бирү, укучыда гомуми күзаллау тудыру максаты белән язылды.

Бишенче тематик юнәлешкә караган мәкаләләрдә Тукайның татардан тыш дөнья белән бәйләнеше турында сүз бара. Татар шагыйренең иҗатын күп кенә төрки халыклар оригиналда укысалар да, аның әсәрләре төрки телләргә дә, шулай ук рус, Европа, Шәрык телләренә дә тәрҗемәдә тәкъдим ителә. Бүген Тукайны берничә дистә телдә укыйлар. Дөнья әдәбиятының гүзәл үрнәкләре белән таныш булган һәм әсәрләре чит әдәбиятларның бәрәкәтле тәэсирен татыган Тукай иҗатын милли мәдәни-әдәби багланышлар яссылыгында өйрәнү – аеруча катлаулы һәм әһәмиятле бурыч булып торды. Элекке союздаш республикалар мөстәкыйль дәүләтләр булып яши башлагач, алардагы әдәби-фәнни җәмәгатьчелек белән бәйләнешләрнең өзелүе Тукай һәм төрки әдәбиятлар темасын энциклопедия кысаларында тиешле дәрәҗәдә чагылдыруда билгеле бер дәрәҗәдә авырлыклар тудырды.

Төрле илләрдә яшәүче әдәбиятчы галимнәрнең фәнни-тәнкыйди мәкаләләре Тукай турындагы фәнне библиографик яктан гына баетып калмыйча, татар шагыйренең иҗатына читтән бәя бирү мөмкинлеген ача. Әлеге тематик юнәлештә татар булып та, язмышлары читтә яшәргә мәҗбүр иткән чит телле галим, язучы, драматург, шагыйрьләр турында да сүз алып барыла. Кыскасы, кайбер мәкаләләрне язар өчен Татарстаннан читтәге төбәк, республика, илләрдәге галимнәргә, фәнни оешмаларга да мөрәҗәгать ителде, аерым алганда, Башкортстан, Чувашия, Мари иле, Азәрбайҗан, Казахстан галимнәре белән элемтәдә эш алып барылды.

Алтынчы тематик юнәлеш буенча язылган мәкаләләрдә Тукай шәхесе һәм иҗатының татар сәнгатенең төрле юнәлешләрендә – театр, телевидение, кино, рәсем, сынлы, декоратив һәм музыка сәнгатендә яктыртылуы

тикшерелә. Шартлы рәвештә бу юнәлеш үз эчендә өч бүлектән гыйбарәт: Тукай музыкада, театрда, рәсем сәнгатендә.

Җиденче тематик юнәлештәге мәкалә һәм белешмәләрдә Тукайның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты белән бәйле урыннар турында сөйләнә. Иҗатында чагылган әдәби топографик материалга шагыйрьнең үзенчәлекле мөнәсәбәте тикшерелә, әсәрләрендә очраган Төркия, Уральск, Мәскәү, Болгар, Алабуга, Кушлавыч, Кырлай кебек шәһәрләр, авыллар, илләр, үзе яшәгән, я булмаса, тукталып киткән кунакханәләр, үзе һәм танышлары укыган мәдрәсәләр, шулай ук музейлары турында сүз бара.

Сигезенче тематик юнәлешкә йөзьеллык тарихы булган Тукай фәненә үз өлешен керткән татар галимнәренең эшчәнлеген яктырткан мәкаләләр керә. Тукай тормышы һәм иҗаты турында үз сүзен әйтмәгән бер генә татар әдәбиятчысы да юктыр. Әмма биредә Тукай тормышы һәм иҗатына кагылышлы китап-монографияләр, диссертацияләр язган, иҗатын барлауга өлеш керткән, мәкаләләрендә Тукай турында аеруча мөһим һәм кызыклы фикерләр белән чыгыш ясаган әдәбият галимнәренә, текстологларга, иҗтимагый фәннәр эшлеклеләренә урын бирелде. Энциклопедиягә шулай ук Тукай псевдонимнары турындагы мәкаләләр дә кертелде. Шагыйрь 7–8 еллык иҗат дәверендә 70 ләп ачык һәм яшерен имза кулланып укучыга тәкъдим иткән.

Югарыда атап үтелгән һәр тематик юнәлеш буенча да мәкаләләр язылдылар. Шуны искәртәсе килә, эш барышында лөгатьлектә күрсәтелгән темаларның барысына да материал табылмады. Хәер, егерме ел эчендә Тукайны өйрәнү фәне бер урында гына тормады бит, тормышына, иҗатына нисбәтле яңадан-яңа фактлар ачылды, теге яки бу әсәрне, Тукайга бәйле фактларны, вакыйгаларны башкачарак шәрехләү дә мөһим булды. Авторлардан мөмкин кадәр объектив фикерләү таләп ителде, энциклопедик мәкаләләрдә субъективлыкка урын калдырылмады.

Энциклопедия татар алфавитына туры китерелеп урнаштырылган 2358 мәкаләне эченә ала. 135 авторның һәрберсе алдында теге яки бу текстны шәрехләгәндә, элеккеге бәя-карашларны исәпкә алу, әмма аларга иярмәү, яңача фикер йөртү бурычы торды. Бу таләпне үтәү җиңел түгел иде, хәтта кайбер очракларда мәкаләләрне тамырдан үзгәртеп язарга да туры килде. Мәкаләләрне энциклопедиягә кертерлек рәвешкә китерү өчен фәнни редакторлар Т. Галиуллин, Д. Заһидуллина, А. Әхмәдуллин, Х. Миңнегулов, Г. Арсланов, Т. Гыйлаҗев, В. Гарифуллин, Р. Исламов, Р. Солтанова, Р. Харрасова, Н. Йосыпова, Д. Абдуллина, З. Шәйхелисламов, Ф. Арсланова, Л. Бәдретдинова тарафыннан шактый зур көч куелды.

Хезмәт библиографик тасвирламаларга да бай. Һәр мәкалә азагында китерелгән кыскача фәнни әдәбият Тукай темасына киләчәктә уздырылачак тикшеренүләргә ачкыч вазифасын үтәр дип өмет итәбез.

Энциклопедиягә 650 дән артык иллюстрация урнаштырылды. Алар төрле характерда: шагыйрь әле исән чагында чыккан китаплардагы, журналлардагы рәсемнәр, карикатуралар, фотолар, истәлекле урыннар, һәйкәлләр, җырларның ноталары, спектакльләрдән күренешләр, сынлы сәнгать әсәрләре. Аларны туплауга А. Мөбарәкшина, Г. Ханнанова, Энциклопедия һәм төбәкара институты хезмәткәре Р. Сәлахиев, Г. Зиннәтуллина һ.б. тарафыннан күп көч куелды.

Сөекле шагыйребез Тукайга багышланган персональ әдәби энциклопедиянең эчтәлеге исеменә туры килә. Анда алфавит тәртибендә урнаштырылган, күләме ягыннан җыйнак, әмма фикергә, фактларга бай мәкаләләрдә Тукай дөньясының зурлыгы һәм тирәнлеге төрле яктан, сыйнфый һәм идеологик бәяләргә буйсындырылмыйча ачыла. Тукай феномены белән, ягъни язма мирасы, даирәсе, әсәрләренең төрле телләргә тәрҗемәләре, иҗади традицияләре, Шәрекъ һәм Гареб әдәбияты белән багланышлары, татар әдәбиятында, театрда, сынлы сәнгатьтә, музыкада чагылышы белән кызыксынган һәр кеше, гади укучымы, галим-тикшерүчеме, аны кулына алган сурәттә, энциклопедиябезнең бөек шагыйрьгә олы ихтирамыбызның югары дәрәҗәдәге матур гәүдәләнеше икәнен ачык күренер.

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Н.М. Йосыпова***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ СИМВОЛИК ОБРАЗЛЫЛЫК

Статья посвящена особенностям образности в творчестве Г. Тукая. Традиционная для татарской литературы система символов позволяет поэту в романтической форме выразить отношение лирического героя к жизни в ее экзистенциальном осмыслении, что в свою очередь дает возможность многие образы-метафоры в поэтической структуре стихотворения воспринимать образами-символами. На фоне данной системы происходит символизация метафорической образности.

**Ключевые слова**: татарская поэзия, символ, трансформация, экзистенциальное осмысление.

Татар әдәбиятында символлардан файдалануның бай тарихы, үзенчәлекле тәҗрибәсе бар. Теләсә кайсы милли әдәбияттагы кебек үк, татар поэзиясендә дә символларның тамырлары фольклор, халык авыз иҗаты әсәрләренә тоташа һәм буыннар, әдәби чорлар аша үтеп, мәгънәви яктан байый, төрләләнә. Икенче яктан, милли җирлектә символларның активлашуына шәркый әдәбиятларның, әдәби-эстетик фикеренең йогынтысы көчле була. Үз чорында ук Шеллинг һәм бертуган Шлегельләр сәнгатьнең табигате гомумән символик дип белдерәләр. Массиньон да мөселман халыклары сәнгате структурасын символик берлек тәшкил итүен билгели [Массиньон, с. 58]. Татар әдәби җирлегендә дә символлар системасыннан файдалану тәҗрибәсе борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятында ук мәгълүм була. XX йөз башы шигъриятендә дә бу яктан бай һәм төрле, әлеге дәвер сүз сәнгате символларны сыйфат һәм сан ягыннан тагын да тулыландыра, мәгънәви яссылыкта баета, киңәйтә.

«Символлар үзләрендә берберсенә бәйләнгән һәм капма-каршы ике иҗади башлангычны берләштерә: бер яктан алар сүз сәнгатенең үткән гасырлар сынавын кичкән классик традицияләргә нигезләнүен чагылдырса, икенче яктан шул традицияләрне «үтеп китеп», аларны яңарту, трансформацияләү омтылышын раслый. Шуңа да символлар әдәбиятның тирән үзгәрешләр кичергән борылышлар вакытында, бер үсеш баскычыннан башка этапка күчү чорында, чиктәш ситуациягә аяк баскан вакытларда аеруча активлаша» [Колобаева, с. 207]. Л.А. Колобаеваның рус әдәбиятына мөнәсәбәтле әйтелгән әлеге фикере милли җирлектә дә актуаль яңгырый. XX йөз башы милли сүз сәнгатендәге үзгәреш-яңарыш гасырлар дәвамында кулланылып килгән символларны сәнгати үзләштереп кенә калмый, аларны традицион булмаган мәгънәләргә дә баета.

Ислам дине белән бәйле символик элементлар, халык авыз иҗатыннан үстерелә килгән традицион символик образлар, суфичылык белән үтеп кереп, милли байлыкка әверелгән символлар XX йөз башында фәлсәфи, иҗтимагый фикерләрне үткәрү мәйданына әйләнә. Көнчыгыш әдәбияты традицияләренә нигезләнеп үскән һәм XX йөз башында рус, аның аша көнбатыш әдәбиятлары йогынтысын тирән тойган милли сүз сәнгате XX гасыр башы әдәбиятында символларга яңача караш булдыра һәм бу үзенчәлек шушы чорда яңа гасыр татар шигъриятенең нигез сукмакларын салган Габдулла Тукай иҗатын да читләтеп үтми.

«Шартлы формаларның» – символларның Тукайның реалистик, романтик шигырьләрендә дә активлашуы, тотрыклы төс алуы күзәтелә һәм ул еш кына милләт язмышын яки лирик герой халәтен, автор позициясен гәүдәләндерүдә файдаланыла башлый. Моңа, әлбәттә, бер яктан, ике гасыр чигендә милли идеянең көчәюе, икенче яктан рус әдәбияты аша гареб дөньясыннан символизм агымының килеп керүе, шагыйрьләр тарафыннан яратып кабул ителүе тәэсир ясый. Шагыйрь иҗатындагы символик образлар, аларның әсәрдәге урыны – роле бу чор татар әдәбиятында шәрык традицияләренең көчле булуы, символизмның да әдәби агым кысаларында шәркый казанышларны исәпкә алып үсүе хакында сөйли. Шәркый әдәбиятлардагыча, аллегорик фикерләүгә тартылу, шартлылыкны лирик-эмоциональ киеренкелек моментлары белән үрү, мәгълүм символларны яңача куллану аша иҗади осталыкны күрсәтү әһәмиятле санала.

Символлардан файдалану тәҗрибәсе ягыннан Тукай поэзиясе бай иҗатларның берсе булып тора. Бу яктан аның аеруча Казан чоры иҗаты кызыклы, өйрәнү үзәгенә куелган шигырьләр дә, нигездә, шушы дәвергә карый. Билгеле булганча, Тукай поэзиясендә халык авыз иҗаты традицияләре, мөселман шәрык әдәбияты һәм гареб поэтик башлангычлары бергә үрелә, бу сыйфат шигырьләрдәге символик, аллегорик образлар системасы, аларга салынган мәгънәви-фәлсәфи йөкләмәдә дә үзен нык сиздерә.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, Тукай лирикасында еш кулланылган символик образларның бер төркемен космогоник символлар тәшкил итә; мондый әсәрләрдәге дөнья сурәтендә җир – күк бинар оппозициясе алга чыга һәм лирик герой күңеленә, гомумиләшеп, җир тормышына, милләт язмышына бәя бирүгә юнәлтелә. Хәтта шагыйрь иҗатының буеннан-буена үстерелә, кабатлана килүче тотрыклы символик образлар барлыкка килә. Нәкъ менә кабатлаулар аша аерым шигырьләрдә аллегорик аспектта кулланылган образлар символик югарылыкка күтәрелә.

1908–1913 еллар татар поэзиясендә таң, кояш, йолдыз, ай кебек күк, галәм символикасына еш мөрәҗәгать итү тенденциясе күзәтелә. Тукай да шушы чорда язылган шигырьләрендә кояш, йолдыз, ай кебек космогоник образларга мөрәҗәгать итә һәм

аларның төрле вариация, мәгънәви төрләрен тудырып, фәлсәфи идея үткәрә.

Шагыйрь әсәрләрендә иң еш кулланылган һәм мәгънә төсмерләренең төрлелеге белән аерылып торган космогоник образларның берсе – йолдыз. Тукай иҗатында йолдыз – бөеклек – ялгызлык – мәхәббәт – өмет концепциясе урын ала. Йолдыз образы традицион кулланылышта өмет, юл һәм мал яклаучысы, якты киләчәк хәбәрчесе мәгънәсендә йөри. Тукайның «Күңел йолдызы» әсәрендә исә ул башка төрле мәгънә төсмерләрен дә үзенә беркетеп, кабатлау, интонация үзгәреше ярдәмендә шигырьне милли һәм иҗади эчтәлектә шәрехләргә, аңлатырга мөмкинлек бирә. Лирик герой бу дөньяның караңгылыгы өчен борчыла; әлеге хис гомернең төнгә тиң булуы белән көчәйтелеп, күңелдә сакланган изге йолдыз борчылу, әрнү хисен шатлык төсмере белән баета, киләчәккә өмет белән алыштыра:

Озаттылар миңа күп төрле мәлгунь
көч, кара көчләр,
Теләп сүндермәгә күңлемдә янган
изге йолдызны.
Вәләкин сүнмәде ул: йолдызым
якты, һаман нурлы;
Гаҗәпме юлга салса, ичмасам, бер
данә юлсызны?
Җиһанда калдырып китсәм икән,
йа раб, гүзәл эзне!

[Тукай, б. 164]

Тукай иҗатының милли юнәлешкә йөз тотуын исәпкә алганда, йолдыз милләт яшәеше югарылыгында аңланып, авторның милләткә мәхәббәте, якты киләчәккә юл күрсәтү омтылышы булып тәгәлләшә. Икенчедән, йолдыз символик образы шагыйрь күңелендәге иҗат уты, шигърияткә мәхәббәте кебек тә кабул ителә һәм лирик герой күңелендәге рухи бөеклек, шәхси азатлык эчтәлеген берләштерүгә ирешә.

«Үкенеч» шигырендә дә җир йөзенең караңгылыгына, кешеләрнең әхлаксызлыгы, икейөзлелегенә әрнегән, ачынган лирик герой үзенең эчке халәтен ирештерү өчен йолдыз символик образын куллана. Шигырь аның үз тормыш хәле, яшәеше белән бәйле хәсрәт хисенең үсә баруы рәвешендә язылган. Тукай экзистенциаль рухта милләт өчен янып яшәп тә, кешеләр арасында, үлем каршында үзенең ялгызлыгы, көчсезлеге, чарасызлыгы өчен сызлана. Һәр якның нурсыз, караңгы булуы, кәгъбә-идеалның югалуы кебек әдәби детальләр сызлануны көчәйтү чарасына әйләнә. Алга таба шигырьдә шәхси күңел төшенкелеге, Яшәешнең мәгънәсен күрмәү мотивлары милләтнең киләчәгенә бәйле өмет белән сугарыла. Йолдыз символы исә авторга бер яктан өмет эчтәлеген салырга, икенчедән, ялгызлык фәлсәфәсен үткәрергә мөмкинлек бирә.

Шагыйрьнең «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре»ндә йолдыз символик образы халкы һәм туган Ватанына хезмәт итеп, шул юлда җанын фида кылган Х.Ямашев образын ачуга юнәлтелә. Тукай символик образ аркылы суфичылык фәлсәфәсеннән килгән социаль һәм матди хәленнән бәйсез рәвештә, бөтен кешеләрнең тигезлеге турындагы гуманистик, дини идеяне чорга аваздаш дәвам

итә, хаклык, рухи матурлык, намус, гаделлек кебек әхлакый кыйммәтләрне алга сөрә. Моннан тыш, әсәрдә матди байлык, шәхси милекне кире кагып, рухи камиллекне алга куйган толстойчылык мотивлары да үзен сиздерә. Йолдызның яктылыгы, биеклеге, юл күрсәтүче маяк кебек мәгънә төсмерләре үз милләтенә бирелеп хезмәт иткән изге күңелле Ямашевның бөеклеге фәлсәфәсенә тоташа. «Җавап», «Китап» кебек шигырьләрдә дә ул шул эчтәлектә кулланыла. Әнә шулай йолдыз образы Тукай иҗатын өч – бөеклек, мәхәббәт һәм ялгызлык турындагы фәлсәфи фикерләр белән баета.

Тукай шигырьләрендә Кояш символик образының бирелеше дә үзенчәлекле. Борынгы мифологиядә кояш мәңгелек, иминлек, яшьлек һәм бәхет символы булып, милли әдәбият тарихы аны бөеклек һәм зурлык кебек мәгънәви вариантлар белән баета. Шагыйрьнең «Үкенеч», «Күңел йолдызы» кебек шигырьләрдә ул шул мәгънә төсмерендә кулланыла да. Башлангыч чорда язылган «Пушкинә», «Мөбарәк тәсбих өзелде» кебек әсәрләрендә дә Кояш кешеләргә яхшылык, шатлык, бәхет вәгъдә иткән идеалны гәүдәләндерә.

Тукайның күпчелек шигырьләрендә исә Кояш образы бөеклек, камиллек турындагы фәлсәфи фикерләрне үткәрергә ярдәм итә. Мәсәлән, «Ай һәм Кояш» шигырендә укучы Җир дөньясы – Күк дөньясының кисешүе белән очраша. Шушы кисешү ноктасы үзе үк символик образга әверелә. Тыныч интонация, моң агышы аша күктәге кояш белән Айның дуслыгы, яшәеш гүзәллеге турында хәбәр итүче шагыйрь әсәрнең соңгы юлларында җир һәм күк арасында бәйләнеш тудыра, шуның ярдәмендә мондый яшәешне, матурлыкны милләткә идеал итеп күтәрә, татар халкына идеаль яшәешне романтик детальләр аша тасвирлап бирә.

Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый», «Эш» кебек балалар өчен язылган әсәрләрендә кояш образы юл күрсәтүче маяк, камиллек билгесе буларак кулланыла. Мәсәлән, «Эш» әсәрендә кояш образы ике строфада кабатланып, һәрберсендә төрле мәгънә төсмерләре белән баетыла. Беренче кулланылышта ул камиллек, изгелек, яктылыкка, азатлыкка илтүче Хакыйкать буларак аңлашыла. Икенче кабатланышта Шәрык әдәбиятының нигезен тәшкил иткән нур фәлсәфәсенең чагылышы сизелә: синең һәр изгелегең, эшләгән эшең гомер буена нур кебек җыелып, үз кояшыңны булдырыр, ди шагыйрь. Бу нурлар – белем, гыйлем, тырышлык, хезмәт сөючәнлек. Әнә шулай шагыйрь халыкны яктылыкка чыгару өчен яшь буындагы аң-акыл куәтен көчәйтергә, хакыйкатькә омтылыш, тырышлык булдырырга кирәк кебек мәгърифәтчелек фикерен дә ассызыклый.

Тукай иҗатында ай символик образына да еш мөрәҗәгать ителә. Матурлык, яңару, үлемсезлек, мәңгелек, Илаһи көч символы [Тресиддер, с. 203] булган ай образы шагыйрьнең романтик шигырьләрендә дөньяви эчтәлекне җиткерүгә йөз тота, илаһи ма-

турлыкны яки мәхәббәт тойгысын ачуга юнәлтелә: мәхәббәт темасына язылган шигырьләрендә суфичыл образ үзенә кызның гүзәллеген ачучы әдәби деталь, Аллага яки сөйгән ярга мәхәббәтнең матурлыгын белдерү вазифаларын беркетә. Әнә шулай ай образының күпмәгънәлелеге Тукай иҗатында матурлык, мәхәббәт, сызлану фәлсәфәләрен үткәрергә мөмкинлек бирә.

Мәсәлән, «Ана догасы» (1909) шигырендә *«авыл өстенә чыккан нурлы, бөтен дөньяны балкытучы көмеш»* ай образы метафора чикләрендә кала һәм шигырьнең беренче өлешендә табигатьнең матурлыгын, гармониясен, тынычлыгын гәүдәләндерә. Икенче өлештә табигать белән дога укучы ананың халәте ялгап куела: айның матурлыгы, илаһилыгы ана күңелендәге матурлыкка, изгелеккә, чисталыкка күчерелә, Аллага булган мәхәббәт дәрәҗәсен ачуга юнәлтелә, ягъни икенче өлештә ай символик образы ярдәмендә кеше күңелендәге илаһи матурлык турында сүз алып барыла.

«Җәйге таң хатирәсе» (1910) шигырендә ай сурәте, йолдыз образы белән янәшәлектә, илаһи матурлыкны ачуга юнәлтелә. Табигать гүзәллеге Тукай иҗатында илһам чыганагы булып килә. Ләкин субъектив эчтәлектә аның башка мәгънә төсмере дә күзәтелә. Суфичылык фәлсәфәсе кешеләрнең идеалга омтылып яшәве Җирдә камиллек, гармония урнашуга китерә дип белдерә. Шушы яссылыктан караганда җәйге табигатьнең, таң ату күренешенең гүзәллеге, табигый гармония Тукайның матурлык идеалы белән тәңгәлләшә. Шигырьнең соңгы строфасында «шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң» юлларын кертеп, автор, бер яктан шигъриятькә йөз тотса, икенче яктан, милләтнең киләчәк тормышы турындагы өметен игътибар үзәгенә куя һәм милләткә яңача яшәү юлын күрсәтергә омтыла.

Тулысынча әрнү хисенең көчәюенә нигезләнгән «Өзелгән өмид» (1910) шигырендә ай образы бөтенләй үзгә – контраст мәгънәдә кулланыла:

Күз тегеп баксам әгәр дә
тормышымның күгенә,
Яшь, туган ай урнында тулган
айның яктысы.

[Тукай, б. 196]

Бер яктан яңа туган ай символик образы якты өмет мәгънәсен үзенә беркетә. Бөтен гомерен халкына багышлаган шагыйрьнең яктылык, яхшылык турындагы идеаллары, өметләре тормышка ашмау лирик герой күңелендә сагыш хисен уята. Икенчедән, ул бертөрле мәхәббәтнең дә булмавын аңлаудан туган ачынуга ишарә ясый, гомернең үтүе, кешенең үлем алдында аның котылгысызлыгына төшенүе, яшәүнең мәгънәсезлеге, үз-үзеңнән канәгатьсезлек кебек төсмерләр аша сызлану фәлсәфәсен үткәрергә мөмкинлек бирә. Өченчедән, ай образы шәркый мөселман әдәбиятларында шагыйрьлек таланты мәгънәсендә йөри. Милли җирлеккә күчерелеп, ул лирик герой күңелендә яңа иҗади чаткыларның инде тумавын да шәрехли.

Шул рәвешле Тукайның космогоник образларны төрле мәгънә төсмерләре белән баетуы һәм фәлсәфи фикер үткәрүдә терәк итеп куллануы ачыклана. Тукай иҗатында космогоник образларның үз сыйфатлары калкытып куелып, лирик геройның эчке халәтен, милләт яшәешен, аңа мөнәсәбәтне, фәлсәфи фикерне ачуга юнәлтелә.

Икенчедән, Тукай шигъриятендә суфичылык традицияләре көчле саклана, суфичыл символика актив. Галимнәр тарафыннан символның иң әһәмиятле сыйфаты буларак нәкъ менә аның күпмәгънәлелеге, чиксез күләмдә аңлатылыш вариантларын табу мөмкинлеге күрсәтелә [Әдәбият белеме, б. 175]. XX йөз башында да күпкатламлы, киң эчтәлекле символлар борынгы мәҗүси, фольклор традицияләренең, Шәрык мәдәниятенең, рус һәм Европа әдәбиятларында билгеле әдәби күренешләрнең, «системаларның» тоташу ноктасына әверелә. Галимнәр синтезлык сыйфатының, кушма характердагы билгеләрнең әдәбиятның бер этаптан башкасына күчү чорында еш очравын билгели. Бу чорда да шагыйрьләр тарафыннан кулланылган символлар төрле мәдәни катламнарның синтезы булып укыла, әсәрләрнең көнчыгыш һәм көнбатыш әдәби-эстетик фикере чикләрендә шәрехләнү мөмкинлеген бирә.

Илаһи гыйшык фәлсәфәсен өйрәнгән галимнәр фикеренчә, суфичылык шигърияте көнчыгыш кына түгел, хәтта көнбатыш сүз сәнгатьләрендә дә Яңарыш чорының дөньяви әдәбияты формалашуга көчле йогынты ясый [Шах, с. 5]. Әлеге фикерне Тукай шигъриятенә карата да кабатларга мөмкин булыр иде.

Шагыйрьнең «Гыйшык бу, йа?..» (1906), «Алла гыйшкына» (1906), «Ифтирак соңында» (1906), «Мәхү идәрмисән?» (1906), «Сөеклемнең кабер ташында» (1906) һ.б. шигырьләре суфичыл символикага корылып иҗат ителә. Мәсәлән, «Гыйшык бу, йа» (1906) шигыренә күз салсак, гүзәл кыз, матур йөз, күбәләк, ут, шәраб кебек суфичыл символларның күпмәгънәлелеге шигырь тукымасында дини-суфичыл һәм шәркый мәдәни катламнарны тергезеп, аларны дини-суфичыл һәм дөньяви контекстларда «уку» мөмкинлеген калдыра. Р. Ганиева сүзләре белән әйтсәк, шигырьне өч юнәлештә – саф суфичылык, дөньяви мәхәббәт һәм әдәби иҗат фәлсәфәсе рухында аңлатырга мөмкин [Ганиева, б. 9]. Әлеге шигырьгә карата А. Саяпова эзләнүләрендә кызыклы шәрехләү бирелә [Саяпова, с. 98–104].

Шигырь тукымасында күбәләк – ут парлы символларына, исерү һәм әйләнү мотивларына мөрәҗәгать ителә. Шәм образы турыдан-туры чагылыш тапмаса да, әсәрдә әлеге образ ут символикасы аша шәрехләнә:

Җанын фида иткән фәкыйрьмен,
гыйшкың күбәләгемен;
Кил, гүзәл, күрсәт матурлыгың:
янаем, кил, янаем...

И гүзәл, кил каршыма, кил,
елмайчы рәхим итеп,
Мин дә синең әйләнәндә әйләнием,
әйләнием...

Синнән исергәнемнән үлгәнче
котыла алмам;
Күз һәм кашыңнан синең айланыем,
айланыем.
[Ил корабын җил сөрә, б. 55]

Суфиларда янып торучы шәм һәм шуның тирәсендә әйләнеп, утта эреп югалучы күбәләк сурәте актив кулланыла; әйләнү мотивының көчле булуы да билгеле, әйләнә-әйләнә транс халәтенә керү, Аллаһ белән кушылырга омтылу мәүләви тарикатендә көчле. Шигырьдәге әлеге сурәтләр суфичыл контекстта Аллаһ белән кушылырга омтылу мизгелен тасвирлый, лирик герой Илаһи гыйшык баскычында торучы кебек кабул ителә. Шушы яссылыкта шигырьдә Аллага мәхәббәт гармониягә китерә, дигән идея аерылып чыга.

Символларның икепланлылыгы әсәрне дөньяви эстетика кысаларында шәрехләү мөмкинлеген дә бирә. Бу вариантта күбәләк гашыйк җанны белдереп, ут символикасы мәхәббәтне аңлатуга күчә, әйләнү, исерү мотивлары да дөньяви мәхәббәтне ачуга юнәлтелә. Лирик герой җир кызына мәхәббәт тотучыга әверелә. Шуларга нисбәтән шигырьнең идеясе дә үзгәрә: мәхәббәт кеше күңеленә «үлгәнче тирбәнерлек» рәхәт бирә, бәхет китерә.

«Хур кызына» (1906), «Син булмасаң!» (1907) шигырьләрендә инде суфичыл эстетика чикләрендә уку мөмкинлеге калдырылмый, ай, зикер, сандугач кебек образ-детальләр бер яклы сурәтләнеш ала һәм символ түгел, ә бәлки метафора чикләрендә кала. Алар романтик материалда дөньяви мәхәббәтнең матурлыгын җиткерүгә хезмәт итә.

Тукай поэзиясендә суфичылык поэзиясендә киң кулланылышта булган пәйгамбәр образына да еш мөрәҗәгать ителә. Шагыйрьлекне пәйгамбәр миссиясе белән тиңләп карау тенденциясе пантеистик юнәлештәге суфичылык әдәбиятыннан килә. Ю. Лотман XVIII гасыр рус әдәбиятында да поэзия, шигъри сүзнең илаһи текстларга алмашка килүен һәм аларның функцияләрен үзләштерүен, илаһи сүзне халыкка җиткерүче пәйгамбәрнең шагыйрь шәхесе белән «урын алышуын» күрсәтә [Лотман, с. 122]. Татар җирлегендә дә әдәби-эстетик фикер секуляризация, сыйфат үзгәреше кичерә. Бу күренешне дәлилләп, Г. Ибраһимов «Альбом мөнәсәбәте илә» (1915) мәкаләсендә: «Сәнгать – яңа заманның дине, бөек сәнгатькярләр ул диннең пәйгамбәрләредер» [Ибраһимов, б. 200], – дип яза.

1910 нчы еллар татар поэзиясендә, гомумән, пәйгамбәр-шагыйрь образы шагыйрь һәм шагыйрьлек темаларының характерлы гәүдәләнеше төсен ала. Аның төп мәгънәсе – шагыйрьлекне җир өстенә кешеләр арасында якты мөнәсәбәтләр урнаштыру, изге теләкләр тарату өчен җибәрелгән гуманистик максат итеп раслаудан [Татар әдәбияты тарихы, б. 130] һәм шәхеснең әхлакый кыйммәтен ачудан гыйбарәт. XX йөз башы лирикасында бу фикер Толстой, Пушкин образлары мисалында ачык чагыла. Пәйгамбәр образы Тукайның үз иҗатында да билгеле урын тота,

әмма суфичыл эчтәлек кысаларында түгел, ә бәлки, бер яклы – дөньяви эстетика чикләрендә «укыла», шуңа мөнәсәбәттә ул символ булудан читләшеп, метафорага якыная. Мәсәлән, иҗатының башлангыч чорында ук язылган «Пушкинә» (1906), «И, каләм» (1906), «Бер татар шагыйренең сүзләре» (1907) шигырьләрендә пәйгамбәр образы аша белдерелгән шагыйрь туры сүзе, таланты, иҗаты белән халкына хезмәт итәргә, яктылык, матурлыкка ышаныч уятырга, милләт идеаллары өчен көрәшергә тиеш дигән идея-фикер ездырыла.

Өйрәнелә торган чор шигърияттә пәйгамбәр-шагыйрь образы Тукайга багышланган әсәрләрдә дә дәвам иттерелә: унынчы еллардан Тукайны пәйгамбәр белән бәйләнештә сурәтләү тенденциясе урнаша.

Нәтиҗә ясасак, Тукай шигъриятендә суфичыл символлар, әдәби структуралар һәм космогоник символика актив. Алар, бер катламлы эчтәлек белән чикләнмичә, төрле аспектта уку мөмкинлегенә ия. Мондый символик образлар Тукайның милләт тормышына мөнәсәбәтле уйлануларын, эчке халәтен, экзистенциаль мотивларны, яшәеш канунннарына бәяне, мәхәббәт тойгысын яшәешнең асылы кебек ассызыклап, бер әсәр чикләрендә төрле мәдәни катламнарның, мәгълүматларның тоташу, кисешү үзәгенә әверелә.

**Әдәбият**

Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы. Казан, 2002. 112 б.

Ибраһимов Г. Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз // Әсәрләр: 8 томда. 5 т. Казан, 1978. Б. 178–200.

Ил корабын җил сөрә: XX йөз башы татар поэзиясе. Казан: Мәгариф, 2001. 208 б.

Колобаева Л.А. Символ как хранитель и возмутитель классических традиций // Классика и современность. М.: Изд-во МГУ, 1991. С. 207–216.

Лотман Ю. Литература в контексте русской литературы XVIII века // О русской литературе. СПб., 1997. С. 118–137.

Массиньон Л. Методы художественного выражения у мусульманских народов // Арабская средневековая культура и литература. М., 1978. С. 54–60.

Саяпова А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. Казань: Алма-Лит, 2006. 246 с.

Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 600 б.

Тресиддер Дж. Словарь символов. М.: ФАИР-ПРЕСС, 1999. 448 с.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда: 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 271 б.

Шах И. Суфизм. М.: Клышников, Комаров и К, 1994. 446 с.

***Йосыпова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*
*faikovich@mail.ru*

УДК 821.512.145

***Р.Ф. Харрасова***

# ТУКАЙЧЫЛАР ДИНАСТИЯСЕННӘН ИКЕ ШАГЫЙРЬ

Поэтическое наследие Габдуллы Тукая является образцом высокого и совершенного искусства. Влияние художественной системы, формированной Тукаем, на творчества Харраса Аюпова и Роберта Миннуллина бесспорно. Тукай для них, как и для всех остальных современных поэтов, является и литературным наставником, и жизненным советчиком, и национальным лидером. Х. Аюпов и Р. Миннуллин используют и развивают художественные традиции, заложенные татарским поэтом еще в начале прошлого века.

**Ключевые слова:** татарская литература, современная поэзия, Тукай, художественные традиции, Харрас Аюпов, Роберт Миннуллин.

## *Харрас Әюп*

Бөтен татар әдәбиятын, бигрәк тә шигъриятен бер ноктага туплаган Тукай иҗаты – борынгыда тамырланган шигъри кәүсәнең иң ныклы бер өлеше. Мәшһүр Кол Галиләрдән, хәтта аңа кадәргеләрдән алып үзенәчә булган һәр уңышны бөртекләп җыйган талантлы каләм иясенең үз мирасы да әлеге кәүсәдән үсеп чыккан бик күп ботак һәм ботакчыкларны шифаландырган, кәүсәне өскә таба үрләткән – яңа талантларны ачарга булышлык иткән.

Әлбәттә, шигъри агач турында уйлаганда, мин Тукай премияләре алып, үзен аңа лаек дип санаган һәр кешене дә кәүсәнең яңа буыннары сыйфатында күрмим, әмма алар арасында да, «тукай»лы булырга өлгермәгәннәр тирәлегендә дә, һичшиксез, зур шәхесләр, куәтле каләмгә ия булучылар җитәрлек, һәм Харрас Гыйлемгали улы Әюпов әнә шундыйларның берсе иде.

Харрас Әюповның татар шигърияте чылбырында төп алкалардан икәнлеген аны шул чылбырда чагылдырган язмалар бик ачык гәүдәләндерә. Мәсәлән, Суфиян Поварисов «Ташка язылган мәхәббәт» язмасында болай ди: «Тукайда җил егерменче йөз башындагы халыкның авыр тормышын чагылдыра, Г. Ибраһимовта, Такташта искелекне пыран-заран китерүче символик көч була. М. Җәлил дә Бөек Ватан сугышындагы яугирләр каһарманлыгын тасвирлый. Бу традицион образ Харрас Әюп шигъриятендә дә поэтик бизәк булып нәкышләнә. Әмма Кол Гали, Тукай, Такташ, Ибраһимов, Җәлилләрдәге җил Харрас Әюп поэзиясендә инде яңа моң, яңа көй, яңа мәгънә, яңа шигъри көч булып яңгырый, заман заңына, чор мизгеленә, вакыт сулышына яраклаштырыла» [Поварисов, 2006].

Укучыларга бигрәк тә шагыйрь буларак билгеле, каләмдәшләре таләпчән һәм үткер күзле редактор да дип таныган Харрас Әюпның гомере шактый иртә өзелде. Ул 1946 елның

21 августында Татарстанның Мөслим районы Түреш авылында туа, шунда башлангыч белем ала, 1964 елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлый.

1969 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып чыккан егет Мөслим район газетасы «Авыл утлары» редакциясенә өлкән әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша, аннан газетаның авыл хуҗалыгы бүлеген җитәкли.

Әлбәттә, район җире генә талантлы кеше өчен тар, 1972 елда Х. Әюп тә гаиләсе белән татарларның иҗтимагый һәм мәдәни үзәге булган Казанга күченә. Унике еллап «Татарстан яшьләре» газетасында эшләгән Харрас Әюповны 1983 елда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясенә мөхәррир итеп чакыралар. 1992 елның сентябреннән ул шул редакциянең мөдире булып эшли, ә инде 1994–2007 елларда нәшриятның баш мөхәррире вазифаларын башкара. 2007 елдан кабат матур әдәбият редакциясе мөдире хезмәтендә була.

Әле зур иҗат хыяллары белән янып йөргәндә, шигъри атны ныклап иярләгән бер чакта Харрас Әюп арабыздан китеп барды. Ул 2008 елның 7 октябрендә кинәт вафат булды һәм туган ягы – Мөслим районы Түреш авылы зиратына җирләнде.

Кызганыч ки, Тукай премиясенә тәкъдим ителгән шагыйрьгә, Дәүләт бүләге булмаган исемнәр дә, башка төр бүләкләр дә бик соңга калып бирелде. Шигърияттә милләтче каләм иясе буларак танылса да, язганнары Г. Исхакый исемендәге премияне дә вафатыннан соң гына ала алды.

Харрас Әюп, әдәбиятта милләт һәм аның теле язмышын, хаклык һәм гаделлекне кайгыртулары белән, Тукайлар башлаган эшне дәвам итүчеләр сафында иде, хәтта гаять лирик рухтагы әсәрләрендә дә шагыйрь телгә алынган проблемалардан читкә китмәде. Ф. Сафин «Шигъри балкыш» язмасында: «Аның шигъри накалы елдан-ел арта, иҗатының мәгънәви йөкләме әһәмиятлерәк төс ала. 2005 елда Харрас Әюповны Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим итү моның дәлиле», – дип билгеләде [Сафин, 2008].

Шагыйрьнең турыдан-туры Тукайга мөнәсәбәтле әсәрләре күп булмаса да, яшәвендә һәм иҗатында, уйларында ул остазын иманлылык үлчәме сыйфатында сайлады. Татар шагыйрьләре мирасханәсендә «Шигырь бәйрәме»ндә уку өчен махсус язылган шигырьләр һәм шул көн хакында әсәрләр шактый. Х. Әюповның «Иман яңарту» шигырендә шулай ук лирик миннең 26 апрель көнендә туган хисләре чагыла. Анда Тукай һәйкәле янында язгы шигырь уку-тыңлаулар иман яңартуга тиңләштерелә; «бу мәхшәрдә изге кыйблаларың кайтаралсаң гына – баш бетмәс!» дигән фикер уздырыла.

Текстта Тукай яраткан алым – асмәгънә белән әйтелгән юллар да бар. Ул хәтта шул рәвешчә башлана да:

Тукай чорында да, аннан соң да
Буш булмады Тукай тирәсе...
Безгә дә бит ел да менә шулай
Иман яңартырга киләсе.

Күрәбез ки, Харрас Әюпов Тукай исеме белән югары үрләргә омтылулар, шул исәптән фәндә һәм әдәбиятта да дан-дәрәҗә алулар, Тукайдан «өлешле» булулар хакында яза; укучыга мәкерлеләрнең, куштаннарның, гаделсезләрнең, милләтне сөймәүчеләрнең ялган белән, теге яки бу эшләргә катышып яхшатланулары, Тукайны битлек итеп киюләре турында җиткерергә тели.

Шигъри мәйданнарга кем нинди хыяллар белән килә бит, Харрас Әюп иҗат иткән лирик миннең хыялы – Шагыйрьне, Шигъри сүзне терелтү, яшәтү:

Дөньясында җылы калмаганда,
Бар өметләр бетте дигәндә,
Күбәләктәй терелер күк җаның,
Терелер күк... Шигырь белән дә!

Белеп җыелабыз: тик бер көнгә
Тукайларның монда күчәсен.
Иман яңарыр да, әгәр булса...
Имансызлар менә нишләсен?!

Гомумән алганда да, узганнан кыйбла эзләү, анда якты идеаллар күрү, танылган шәхесләр алдында баш ию кебек мотивлар Х. Әюпов иҗатында еш күзәтелә. Ул «Барып җитәр көне» һәм кайбер башка әсәрләрендә, мәсәлән, Тукай иҗаты, аның киләчәге хакында фәлсәфә кора, исеменең һәм язганнарының халык күңелендә мәңге яшәсенә ышаныч белдерә, шул ук вакытта «Туры сүзгә» шигырендә заманга ярашучыларның Тукайны йөрәкләрендә әле дә бикләп тотуларын әйтә.

Х. Әюпнең Тукайдан эпиграфлар еш алуы аның шагыйрь иҗаты белән яхшы танышлыгын да, аны даими укуын, өйрәнүен дә күрсәтеп тора. Бу эпиграфлар, нигездә, узган чорлар мотивлаштырган әсәрләрдә күзәтелә: «Бу тору, әйтергә мөмкин, кояшсыз-айсыз тору» («Сөембикә манарасындагы айны сәламләү») яисә «Очты дөнья читлегеннән» («Үз күгендә») һ.б.

Х. Әюп иҗат иткән «Печән базары» поэмасының «Базарлар» бүлегендә «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш»тан алынып, яңа материалга трансформацияләнгән Кисекбаш, Карәхмәт кебек образлар һ.б. төр күчемлелекләр аның Тукайны олылыклавын, иҗатыннан нәкъ менә программ характердагы әсәрләренә мотивлар эзләвен сөйли. Мәсәлән, ул «Бер иңдәге ике фәрештә күк» әсәренә аны язуга этәргән юллар урнаштыра: «Тукайның өстәл тартмасында Коръән белән револьвер сакланган» һәм укучының игътибарын Тукай аңлавындагы җан белән тәнне саклаучы ике көчкә юнәлтә:

Бер иңдәге ике фәрештә күк –
Бер тартмада Коръән, револьвер:
Бер үк җанны икәү сагалаган...
Мәрхәмәт бир берүк, иман бир!
/…/

Бер үк җанны икәү сагалаган:
Йә сынасы син, йә чыдасы;
Кара нокта куясыдыр берсе,
Икенчесе – ясин чыгасы.

Асылда шагыйрь утлы коралга кагылмаган, аның дошманы белән көрәш чарасы «төбәп аткан сүз» булган, ди автор. «Бер иңдәге ике фәрештә күк» озак еллар намаздагы Х. Әюп каләме өчен үтә көтелмәгәнчә, «чирканды» сүзе аркасында сискәндергән юллар белән тәмамлана:

Баш бирмәде шагыйрь берсенә дә,
Кагылырга хәтта чирканды:
Китеп барды бер тартмага ябып
Револьверы белән Коръәнне...».

Әлбәттә, моны, алдагы строфалардан чыгып, Тукай кеше гомерен вакытсыз өзгән револьверны һәм шул гомергә нокта куйган ясинны кабул итә алмады, физик һәм рухи үлемгә каршы иде, дип тә аңларга булыр иде.

Харрас Әюп милләтебезнең үткәне, бүгенгесе, иҗтимагыйммәдәни тормышы, гореф-гадәтләре, сәяси хәле, авылларыбызның һәм шәһәрләребезнең яшәеше, халыкның көн итү ритмы һәм башкалар турында уйлана. Бу төр уйланулар узган чорларда, бигрәк тә XX гасыр башында көчле була, әдәбиятны көнүзәк мәсьәләләргә җавап бирүче өлкәгә әйләндерә, аның һәр төр вазифаларын көчәйтеп җибәрә. Шушылардан чыгып та, без Харрас Әюповны Тукайлар, Җәлилләр кебек алтын буыннары булган шигърият чылбырының үз чоры өстәгән бер алкасы сыйфатында кабул итәбез дә.

Шул ук вакытта Тукай мирасы рухына, Х. Әюповның интим лирикасы, авыл яисә табигать турындагы шигырьләре түгел, Үзгәртеп кору елларына кергәч язган публицистик рухтагы иҗаты, иҗтимагый-фәлсәфи тематикага караган аерым әсәрләре якынрак тора дип уйларга кирәк.

### *Роберт Миңнуллин*

Әдәби-фәнни тирәлектә шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе булып танылган Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин зур әдәби мәйданга җитмешенче еллар башында аяк баса. Шулай дип яздым да уйга калдым… Кинәттән шушы җөмләм белән каләм иясенең аңарчы гомерен сызып аткан кебек булдым. Чыннан да, балалар шагыйре турында язуны бала чагыннан башларга кирәк иде шикелле. Ул йөргән басу-кырлардан, ул аунап уйнаган болын-чишмә буйларыннан, ул коенган мул сулы елгалардан..., чөнки кечкенәләргә атап иҗат итәр өчен, бала чагың хисләрен гомерең буе күңелеңдә йөртергә, аның вак-төяклеме, катлаулымы хәл-вакыйгаларын хәтереңдә җете сакларга, күпмедер бала булып калырга кирәк. Инде зур шагыйрь булгач, Ташаяк тәлинкәсенә барып сабыйланып аласы килгән, җае чыкканда, малай-шалайга кушылып китеп уйнарга яраткан, холкы белән дә инфантильрәк Тукай сыман дип әйтимме…

Төрле якларда тусалар да, төрле чишмәләрнең суын эчсәләр дә, танылган шәхесләрне әдәбиятка алып килгән тормыш биографиясе, шартлары элек күпчелек очракта, бик аз чыгармалар белән, бер төсле була иде. Аның схемалары артык күп түгел. Тормыш авырлыгы, хезмәттә үткән сабыйлык, ил кичергән фаҗигаләрне өлкәннәр белән бергә күтәрү һәм, иң-иң авыры – иртәрәкме яисә соңракмы тойган ятимлек ачысы. Кешене бу хәлләр ныгыта да, сындыра да… Сынмаганнар кайчан да бер башкаларга рухи терәк булып яши башлый, күңеле китекләргә, җылы һәм татлы сүзгә мохтаҗларга – шул сүзләрне әйтә, киңәш сораганнарга – киңәшен

бирә. Каләм ияләре әнә шундый зур миссияне алып бара. Аларга аерым бер кеше генә түгел, тулы бер милләт өмет күзе белән карый, үзләрен яшәтү сагына баскан таяныч дип саный.

Сугыш тәмамланганнан соң нибары өч ел узгач, 1948 елның 1 августында Башкортстанның Илеш районы Нәҗәде авылында туган Роберт абыйны да язмыш арбасы, шома юлларны сайламыйча, яшәешнең кытыршы, сикәлтәле, күптукталышлы юлларыннан алып китә. Шагыйрьнең тормыш биографиясе белән танышкан кеше, елмаеп, кечкенә Роберт бик илгизәр булган икән, дип әйтә алыр иде. Сабыйга бер яшь булганда, аларның гаиләсе Кыпчак авылына күченә, ә берничә елдан әтиләренең туган авылы Шәммәткә кайтып төпләнә. Сөн буеның гүзәл кочагында утырган, шагыйрьнең популярлыгы дистәләрчә елларга сузылган «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» җырына һәм башка бик күп әсәрләренә илһам биргән авыл була ул.

Татарстанда яшәгәч, инде Казан кешесенә дә әйләнеп беткәч, Роберт абый башкалабыз турында да, безнең як балалары исеменнән күп яза, билгеле. Әле бит, республикабызга күчеп килеп, гомер дәвамында иҗатына күптөрле тема-мотив бирерлек ул-кызлар, оныклар үстергән. Шулай булуга да карамастан, хәтта лирик герое Татарстан баласы булганда да, аның хакындагы шигырьне шагыйрьнең үз балачагы, үз туган ягы тудырган хисләрне, хатирәләрне кушып язганлыгына шигем юк.

«Кунакка килегез!»дә: «Җирнең иң матур җирендә – Татарстанда торам мин!» – дип горурланган авыл малае:

«Сезне үзебез үстергән
Ипи белән сыйларбыз.
Матур итеп, Тукай, Җәлил
Шигырьләрен сөйләрбез!» –

дип вәгъдә бирә. Милләтебезнең күз карасы Тукай, Казан артында туып үссә дә, Башкортстан балаларына да, башка өлкәләрнекенә дә бик якын. Җәлил исә – Оренбург якларыннан килеп, шагыйрьлек данын Казаныбызда яулаган. Әнә шулай итеп, татарлар яшәгән төрле төбәкләр арасында тыштан күзгә ташланып тормаган рухи-мәдәни җепләр тоташа.

Өзелеп калган сүземә – илгизәрлеккә кайтыйм. Бәләкәй Роберт башлангыч мәктәпне үз авылында укый, ә аннан Аккүз сигезьеллык мәктәбендә белем ала. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Уфа сәүдә-кулинария училищесына укырга керә. Бераздан авылына әйләнеп кайта һәм китапханәдә, колхозда эшләп ала. Икенче елны исә район үзәгендәге Югары Яркәй мәктәбенә укырга китә. Ул да белем алуның соңгы тукталышы булмый. Урта мәктәпне инде Роберт абый Карабаш авылында тәмамлый.

Зур әдәбиятка элекке язучыларның юллары бик әйләнгеч була, тормыш-тәҗрибә мәктәбен уза-уза салына торган иде. Роберт Миңнуллин хакындагы биографик материалларда: «Мәктәптән соң ике ел “Маяк” исемле район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Иҗат

белән ныклап шөгыльләнүе дә шул елларга туры килә. Әле мәктәптә укыганда ук “Башкортстан пионеры”, “Маяк” газеталарында беренче шигырьләрен бастырган Роберт әдәбият белән чынлап кызыксына башлый. Газета мәкаләләре белән беррәттән, шигырьләр дә яза», – диелгән. Аларның газеталарда еш басылуы, әдәбиятка мәхәббәт, Казанны шуның казаны дип тану яшь талантны безнең якларга алып килгәндер дә.

Роберт Миңнуллинны шагыйрь сыйфатында әдәби җәмәгатьчелеккә Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып йөргән еллары таныта. Бу – шигъри сүзнең зур мәйданнардан яңгыраган, талант ияләренең бик дәрәҗәләнгән чоры. Әдәбиятта Тукай һәм Җәлил традицияләре турында бәхәсләр купкан елларда, аларның яшәргә хаклыгын һәм хәтта тиешлеген раслаган шикелле, Роберт абый озын гасырлык татар тарихын тудырышкан корифейларның иҗатын санга сугып, шулар мирасына нигезләнеп иҗат итә.

Р. Миңнуллинның бигрәк тә балаларга адресланган шигърияте Тукай һәм аның мәктәбендә тәрбияләнгән башка шагыйрьләр иҗатында формалаша. Әйтик, ул Шәүкәт Галиевне остаз санаса, Шәүкәт Галиевкә Бари Рәхмәт үрнәк була. Әнә шул юл белән барыбер дә Тукайга барып чыгасың. Тукайның замандашы, аннан бер яшькә генә кечерәк Бари Сибгатулла улы Рәхмәтуллин, ерак Казакъстанның Гурьев өлкәсе Жилая Коса поселогында туса да, Г. Тукай әсәрләрен яратып укыган һәм шуның тәэсирендә үзе дә шигырьләр яза башлаган бит. Балалар шигъриятенә Тукай алып килгән алым-чараларны, форма-калыпларны, аныңча кечкенәләр күңеленә хуш, аңлаешлы, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып язуны шагыйрь вафатыннан соң, беренче чиратта, Бари Рәхмәт һәм кайбер башка каләмдәшләр кабул итеп алган, үстергән.

Бари Рәхмәтнең беренче басылган шигыре балаларга аталса да, аның да бу юнәлештә танылуы бик озакка сузыла. Бигрәк тә өлкәннәр өчен актив язган Бари Рәхмәт илленче еллардан башлап кына, нигездә, балалар әдәбияты өлкәсендә эшли, һәм бу эш нәтиҗәсен дә бирә. Роберт абыйның да зур шагыйрь булып танылуы төп юнәлешен балалар өчен язуны сайлаганнан соң дип уйлыйм. Бер шагыйрь турында гына язарга алынасың, фикерең әллә кайларга китә, хәтер төпкеленнән әллә нинди исемнәрне актарып чыгара.

Тукай, балалар өчен язганда, халык авыз иҗатыннан, рус һәм дөнья балалар әдәбиятыннан илһам ала. Чит әдәбиятлар белән бәйләнешне мин Ш. Галиев иҗатында да ачык сизәм. Роберт абый шигъриятенең үз әдәбиятыбыз белән бәйләнешләре шулай да ныграк шикелле тоела. Тукай юбилее алдыннан язылган бу мәкаләмдә, билгеле, мин аның нәкъ менә Тукай мирасы белән бәйләнешләрен чагылдырырга, калкуландырырга тиештер.

Мәктәп дәреслекләре язарга алынган Тукай әдәбият аша

балаларның тормышны, дөньяны, шул исәптән табигатьне күзаллауларын киңәйтергә кирәк дигән караштa тора. Егерменче гасыр башының дәреслекләргә куйган гомуми таләбе дә шундый була. Милләт алгарышы турында хыялланган Тукай исә тагын да алгарак китә – әлеге күзаллауларның эчтәлеген иҗтимагый барыш белән дә бәйли: балалар кешедә милли горурлык, милләтпәрвәрлек хисләре тәрбияләгән әсәрләр белән дә танышырга тиеш дип саный, дәреслекләргә авторлар иҗатыннан шул эчтәлектәгеләрен дә сайлап алырга тырыша.

Тукайның балалар өчен язган үз әсәрләре дә – тормыштан ерак, үтә хыялый, кем дә җиңел генә аңламаслык тезмәләр, табышмаклар түгел. Аларның күпчелеге кечкенә баланы авылның патриархаль тормышына, белем-аң бирүче мәктәп-мәдрәсә эчләренә алып керә; халыкның мифик затларга бәйле ышануларын чагылдыручы сюжетларга нигезләнгән экият-поэмалары да тормыш-көнкүрештә кулланырлык киңәшләр, файдалы гыйбрәтләр бирә.

Инде Р. Миңнуллинга килгәндә, ул да, Тукай кебек үк, кече яшьтәгеләрнеке саналмаган темаларны да балалар поэзиясенә кертә, шул юл белән аның олылар өчен дә кызыклы булуына ирешә. Р. Миңнуллин шигъриятькә бәйле чыгышларында бу проблеманы еш күтәрә. 1977 елгы балалар әдәбияты турында уйланулар рәвешендә иҗат ителгән «Киләчәк буын хакына» язмасында ул, Тукай балалар өчен классик әсәрләр язган, аны зурлар өчен әдәбияттан аерып карамаган, дип белдергән һәм замандаш каләм ияләрен аның кебек чын мәгънәсендә үрнәк әсәрләр иҗат итәргә чакырган иде.

Шул ук вакытта Р. Миңнуллинның Тукайга мөнәсәбәтле күпчелек әсәрләре өлкәннәр шигъриятенә карый. Алардан шагыйрь өчен Тукайның яшәү һәм халыкка хезмәт итү рәвеше эталон икәнлеге аңлашыла:

Мин Тукай булалмадым –
Бик яшьли үләлмәдем,
Ватанымны вә халкымны
Даннарга күмәлмәдем.
(«Булалмадым»).

Р. Миңнуллин милләт мәнфәгатьләрен кайгыртып, язучының халык хәтереннән беркайчан да юкка чыкмасына ышана: «Тукайның шигырьләренә мәңгелек язган икән!» («Кайрый белән»). Шагыйрьнең Тукайга тиңләшергә, үз халкы күңеленә керергә омтылуы бәхәссез. Болар – кайсы шагыйрьнең хыялында түгел соң?! Әнә шул сәбәпле, Р. Миңнуллин иҗат иткән һәм прототибы автор дип уйланылган герой кылган гамәлләрен, кичерешләрен-рухын Тукайныкы белән чагыштыра да:

Миндә дә бит аз булса да
Яна һаман Тукай җаны.
(«Тукай минем яшьтә үлгән»).

Шагыйрь – «лирик мин» гомере дәвамында Тукайны аңларга, аның портретын күз алдында торгызырга, үзендә әлеге Тукайны – шагыйрьне табарга тырыша. «Үз Тукаен» эзләү белән мәшгуль каһарман бу хакта «Тукайга

багышланган күргәзмәдә» шигырендә дә метафорик рәвештә:

Һәркемнең үз Тукае шул
Бернигә дә биргесез!
Эзлим мин дә Тукаемны –
Ул әлегә билгесез, –

дип белдерә. Тукайны табуның бер юлы – үз туган ягың, шагыйрьнең Ватаны. Шуны аңлаган каләм иясе «Шагыйрьнең туган җирләре» әсәрендә остазының туган ягын, нигезен күрү теләген әйтә дә, чөнки аларда халык һәм шагыйрь рухы яши, ди.

Алда язганыбызча, Р. Миңнуллин иҗатын тамырландырган, сафландырган сулар бер Тукай гына түгел, тагын да бар, билгеле. Тукай да буш урында барлыкка килмәгән. Шул сәбәпле Роберт абый еш кына аны татарның башка танылган шәхесләре янәшәсендә тасвирлый да. «Мәгърифәтче Каюм»да, мәсәлән, каләм иясе Җәлил, Тукай һәм Каюм Насыйрины татарның өч бөек улы сыйфатында атый, ә «Тукай белән сөйләшү» һәм кайбер башка әсәрләрендә татар милләтенең, аерым кешесенең, бигрәк тә зыялыларының Тукай юлыннан барырга тиешлеге идеясен күтәреп чыга:

Юлыбыздан язмыйк, дисәк,
Тукайга иярегез!
Тукайның бөек дөньясы –
Татарлыкның асылы...
Дәвам итә Тукай елы,
Бөек Тукай гасыры!
(«Тукай белән сөйләшү»).

Р. Миңнуллин публицистикасында Тукай темасы шулай ук мөһим урын алып тора. Ул шагыйрьгә бәйле проблемаларны җирле һәм чит өлкә матбугатында да күтәрә. Мәсәлән, Башкортстанның «Уфа Тукайлы булырга тиеш!», «Тукай йолдызы» мәкаләләрендә узган гасырның бөек акыл иясе Тукайга дөнья халкының, кардәш милләтләрнең, заманыбызның мөнәсәбәтен ача, аның исемен мәңгеләштерү юлында башкарылган бик күп эшләргә күзәтү ясый, алда торган бурычларны билгели.

1998 елда Мәгариф нәшриятында басылган «Күчтәнәч» (1995) китабы өчен Р. Миңнуллинга Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. Мондый бүләкне балалар өчен язылган туплананың алуы сөендерә, ул әлеге әдәбиятның дәрәҗәсен күтәреп җибәрә. Ә бит Роберт абыйның балалар сүз сәнгатенә, мәгарифебезгә хезмәт итүе шигъри иҗаты белән генә билгеләнми. Ул кечкенәләр өчен мәкаләләр язган тәҗрибәле журналист, телетапшырулар әзерләгән редактор сыйфатында да танылган иде. Хезмәт эшчәнлегенең бер чорында шагыйрь Татарстан телевидениесендә – баш редактор, «Яшь ленинчы» газетасында корреспондент, соңрак шулай ук баш редактор, шеф-редактор булып эшләде. Роберт Мөгаллим улы балаларга мөнәсәбәтле иҗтимагый-сәяси эшчәнлек тә алып барды. Мәсәлән, ул 1988–1994 елларда Татарстан Балалар фонды рәисе вазифаларын үтәде. Исемлекне әле тагын да дәвам итәргә булыр иде.

Балалар әдәбияты халык иҗатында тамырланган, шуңа тамырлары бик борынгыга барып тоташа, диләр. Моны фольклор белән бәйләнешләре нык Тукай

мирасы да раслап тора. Ул әле педагоглар психотерапиянең бер формасы булган әкият терапиясе дигән төшенчәне кулланмаган бер заманда Тукай лиро-эпик фольклорга балалар күңелен дәвалауда, холыкларын тәрбияләүдә зур өмет баглый. Шагыйрьнең сабыйларга адресланган кече күләмле әсәрләре генә түгел, «Су анасы» әкияте дә, мәсәлән, хәзерге заман фәне балалар әдәбиятына, аның әкият төренә куйган барлык таләпләргә җавап бирә. Бу фикерне Р. Миңнуллин иҗатына карата да әйтергә булыр иде. Ике шагыйрьнең дә балаларга адресланган әсәрләрендә бала герой калкулана, аның уй-фикерләренә, эш-гамәлләренә зур урын бирелә, алар чагыштырмача кыска, аңлаешлы телдә, диалогларны мул кулланып язылган, яхшылыкның җиңүе, яктылык белән тәмамлана һәм шунлыктан зур тәрбияви көчкә ия.

Тукай, Бари Рәхмәт, Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин… Бу шагыйрьләр тезмәсендә без белеп тә атамаган исемнәр әллә никадәр, без әлегә ишетеп тә белмәгәннәрен әлеге чылбырга туар буыннар өстәр һәм, шулай итеп, Тукай исемен, Тукай мирасын рухи байлык сыйфатында киләчәккә илтер.

**Әдәбият**


*Әюпов Х.* Таң суы. Казан, 1987.

*Әюпов Х.* Йөз яктысы. Казан, 2005.

*Әюпов Х.* Сабыр савытлары. Казан, 1992.

*Бакиров М.* Күкрәгеңдә көең исән булсын // Мәдәни җомга. 2005. 15 апр.

*Галиуллин Т.Н., Юсупова Н.М.* Образ Г. Тукая как национальный идеал в татарской поэзии XX века // Филология и культура. 2012. № 3. С.128.

*Миңнуллин Р.* Әсәрләр: 7 томда. 1 т. Шигырьләр, тәрҗемәләр / кереш сүз авт. Р. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 575 б.

*Поварисов С.* Ташка язылган мәхәббәт // Мәйдан. 2006. № 6.

*Сафин Ф.* Шигъри балкыш // Мәйдан. 2008. № 12.



***Харрасова Рифә Фәтхрахман кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

*rita.rahman@yandex.ru*

УДК 821.512.145

***З.Р. Шәйхелисламов***

# ИСТАНБУЛ ҺӘМ ТУКАЙ

В статье отражается отношение Тукая к Турции. Последовательно через публицистические материалы поэта можно проследить эволюцию творческого мышления Тукая.

**Ключевые слова:** Тукай, Стамбул, Турция, патриотизм, литературные связи.

Географик яктан һәм климат буенча яшәү өчен гаять уңай урнашкан, күп гасырлар элек Византия империясенең башкаласы булган Константинополь-Истанбул, гәрчә, рәсми рәвештә, хәзерге Төркиянең пайтәхете саналмаса да, бик күп халыклар тарихында мөһим урынны алып тора. Билгеле, аның татар халкы язмышына да йогынтысы зур була. Телләрнең якынлыгы, уртак диндә булу ике арада сәүдә, сәяси, мәдәни бәйләнышларны көчәйтүгә җирлек тудыра. XVI йөзнең икенче яртысында дәүләтчелеген югалткан әби-бабаларыбызның бер өлеше Истанбул тарафларына күчеп килә, XIX гасырның ахырында ачлыктан качып та, 1917 елны Октябрь революциясен кабул итә алмаганнар да Төркиягә килеп шунда сыену урыны табалар.

Элек хаҗга барганда да татарлар Истанбул аша барганнар, күп кенә зыялыларыбыз шундагы югары уку йортларында белем алганнар, җирле укымышлылар белән аралашканнар.

XIX йөзнең икенче яртысында, бигрәк тә XX гасыр башларында татар сәүдәгәрләре Истанбулда басылган китапларны күпләп алып кайтып, Россиянең татарлар яши торган төбәкләрендә тараталар. Шул юл белән зыялыларга газета-журналлар да килеп ирешә. Кайбер төрек язучыларының әсәрләре Казанның үзендә дә басыла башлый. Мәсәлән, Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабы (1449) кат-кат басыла һәм татарлар арасында бик популяр була. Бу әсәр Г. Тукайга да көчле тәэсир ясый. Уральскида мәдрәсәдә укыганда ук ул «Мөхәммәдия»дән аерым өлешләрне көйләп-җырлап йөри, сатирик әсәрләрен язганда да аннан уңышлы файдалана.

Күңелендә Истанбулга бару уе булса да, Тукай бервакытта да анда булмаган. 1911 елның 4 мартында дусты Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында җитәрлек акча таба алса, Әстерханга – Сәгыйть Рәмиевкә кунакка җыенуын, аннан аның белән кыргыз арасына кымызга чыгу, мөмкин булса, Истанбулга да бер-ике атнага барырга теләге булуын әйтә. Шагыйрьнең Истанбулга мөнәсәбәте үзенчәлекле. Уральскида мәдрәсәдә укыганда дуслашкан, Төркиядән Габделхәмид режимыннан качып килгән, Истанбул университеты студенты Габделвәли Әмрулла тәэсирендә башта

шигырьләрен дә төрекчәрәк яза, Төркиянең әдәбиятына, сәнгатенә, мәдәниятенә күңел бирә. Ләкин үз ватанындагы хәлләр һәм чит ил матбугаты белән яхшы таныш булган зирәк акыллы шагыйрь бик тиз икенче төрле нәтиҗәгә килә. Халкың аң-белемле булсын, артта калмасын дисәң, алдынгы карашларга ияреpгә, яңача белем алырга кирәк икән. Татар халкының әдәбияты, сәнгате дә үз туган телендә, һәркемгә аңлаешлы телдә үсәргә тиеш. Тукай ул елларда кайбер милләтчеләрнең татарларны төрекләштерергә тырышуларына, искечә укыту тәртипләренә, кайбер мәгълүм шәхесләргә карата булган тискәре мөнәсәбәтен күпсанлы әсәрләрендә сатирик планда яктырта. Мәсәлән, «Хиссияте миллия» (1906) мәкаләсендә ул татарның киләчәге өчен борчылып: «Без яшьләремезне Бохарага җибәрсәк – ишәк, Истанбулга җибәрсәк – полицейский вә шпион булып кайтачаклары моңгарчы кайтканнары илә дәлилләнгәндер», – дип яза. «Тәрҗеман»ның татарларга галякасе» (1906) мәкаләсендә бу газетаның теле безнең телебезгә бөтенләй кире бер Кырым теле булуы, дөньядан артта калган «Тәрҗеман»ны алганчы, Истанбулдагы деспотизм корбаны булган, «Яшь төрекләр» партиясе чыгарган «Сабах», «Икъдам», «Тәрҗемане хакыйкать» газеталарын алдыру файдалырак булуы ассызыклана. Төркиядә деспотизм көчәю аркасында милли рухлы әсәрләр иҗат итү, илдәге сәясәт турында язу катгый тыелган. Шуңа күрә андагы язучылар фәкать солтанны, аның сарайларын мактап кына язарга мәҗбүр булалар. Тукайның «Мәддәхе Истанбул шагыйрьләре» (1908) шигыре нәкъ шушы хәлләрне чагылдыруга багышланган. «Шартлар» (1906) фельетонында шагыйрь әгәр үзеңне чын мөселман итеп танытасың килсә, менә шушы нәрсәләргә иман китерергә кирәк дип 10 шартны саный һәм шулардан берсен – Истанбулдагы кебек үзен эре тотучыга охшарга тырышырга кирәк дип күрсәтә. «Мин шушылар илә милләтче» (1908) фельетонында «Тәмәкенең дә «Госманлы сигарасы» исемлесен махсус Истанбулдан алдырам», – дип төрек тәэсиренә эләккән татарларга киная ташлый. «Халык әдәбияты» лекциясенең конспектында да (1910) шулай ук төрекләшүгә каршы фикерләр белдерелә. Шагыйрь газета-журналларыбыз да татар телендә чыга, «Төрекләр – Истанбулда, без – монда», дип татарлыкны саклап калырга өнди. 1911 елның 22 гыйнварында С. Сүнчәләйгә язган хатында да татар теленең матурлыгын үзенең татар кызының сөйләү рәвешенә соклануы аша белдерә. Гыйбрәт өчен бер төрек шагыйренең Истанбул гүзәлләре хакындагы шигырен китерә. Анда әгәр төрек кызлары Истанбул диалектында сөйләшсәләр, гашыйкларга җәннәттә дә рәхәт булмас дип куркам дигән юллар бар. Истанбул атамасы туры мәгънәсендә кайбер шәхесләрне тәнкыйтьләгәндә яки уңай яктан сыйфатлаганда кулланылган. Әйтик, «Төрле хайваннар тугрысында бераз мәгълүмат» (1908)

фельетонында Тукай «йорт хайваны булса да, … ул бүген Петербургта, иртәгә Сибириядә, берсекөнгә Истанбулда… буладыр», – дип публицист, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимовның (1857–1944) еш кына урын алыштыруыннан һәм фикерен үзгәртүеннән көлә. «Тегеннән-шуннан» (1912) фельетонында Йосыф Акчураның (1876–1935) «Вакыт» газетасында «Истанбул мәктүбләре»н бастыруы матур эш дип бәяләнә һәм «Йолдыз» газетасының бер үлчәүдәге охшаш материалларны бастыруы тәнкыйть ителә. Тукай чыгышы белән кавказлы, Төркиядә укып кайткан Ширванский (Исмәгыйлев) Мостафа Лотфины кылган гамәлләре өчен еш тәнкыйть итә. «Һәзиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа» (1912) шигырендә аның барлык әшәке сыйфатлары чагылдырыла: ул фетнә чыгаручы, акча үзләштерүче («монда кайткач симергән»), кеше аңламастай телдә газеталар чыгаручы, динле булып күренергә тырышучы, байларга ялагайланып алдынгы фикерле кешеләргә каршы эш итүче, Истанбулдан укытырга дип, хәйләләп китерткән кыз балаларны хурлыкка төшерүче һ.б. Шагыйрь аның гаебен санап кына бетерү мөмкин түгел икәнен гипербола кулланып, «ул кабахәтлектә мильярдир танылган Мостафа» дигән сүзләр белән шигырен тәмамлап куя.

Демократик карашлы Тукай алдынгы фикерләрне күбрәк Европадан, руслар аша алырга кирәк дип санаганга, үз иленең патриоты буларак та, Төркиягә башкачарак карый башлый. Күргәнебезчә, бу фикерләр шагыйрьнең публицистикасында ачык чагыла.

**Әдәбият**

*Тукай Г.* Әсәрләр: Алты томда. Академик басма. Т. I. Б. 233. Т. II. Б. 222. Т. III. Б. 194, 251, 260; Т. IV. Б. 80, 82, 161, 240

*Тукай Г.* Әсәрләр: Биш томда. Т. V. Б. 100–101.

*Миңнегулов Х.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. кит.нәшр., 1999. Б. 233–257.

*Миңнегулов Х.* Гасырлар арасында уйланулар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. Б. 287-291.

*Мубаракшина А.Р.* Отражение социально-политической ситуации Турции в творчестве Тукая // Научный потенциал мира. София, 2012. С. 78-80.

***Шәйхелисламов Заһир Рәхмәтулла улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

.

УДК 821.512.145

***А.Р. Мөбарәкшина***

# ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕ БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ РУС ТЕЛЕНДӘ

В статье рассматриваются первые переводы стихотворений Габдуллы Тукая на русский язык, которые опубликовались в «Оренбургской газете» в 1913 году после смерти поэта.

**Ключевые слова:** «Оренбургская газета», «Изгнанникъ», русская периодическая печать начала XX века, переводы стихотворений Габдуллы Тукая.

XX йөз башы татар милли әдәбиятының Яңарышына нигез салган классик шагыйрь, 27 яшьлек Габдулла Тукайның вакытсыз үлеме татар һәм төрки галәмен генә түгел, рус дөньясын да тетрәндереп җибәргәндәй була. Россия империясенең төрле өлкәләрендә чыккан рус вакытлы матбугаты 1913 елның апрель, май айларында татар шагыйренә багышланган язмаларга шактый урын бирә. Бу аеруча татарлар күпләп яшәгән өлкәләргә карый. Аерым алганда, Оренбург редакцияләре үзләренең активлыгын күрсәтә. Тукайның үлеме турында хәбәр иткән телеграмма Казаннан Оренбургка 3 апрель төнендә килеп җитә һәм иртән бик тиз бөтен шәһәргә тарала. Казанга Оренбург җәмгыяте рәисе, «Вакыт» газетасы редакциясе, мәдрәсәләр, хосусый затлар исеменнән тәгъзия телеграммалары җибәрелә [Бартольд, с. 152–169]. Шулай ук Оренбург каласындагы рус редакцияләре дә Тукай үлеменә битараф калмый. 1908–1915 елларда чыккан «Оренбургская газета» (1897–1896 елларда «Оренбургские губернские ведомости»ның рәсми булмаган өлеше буларак нәшер ителә) татар шагыйренең үлеменнән соң, аның тормыш һәм иҗат юлына багышланган мәкаләләрне еш бастыра. 1913 елның 26 апрелендә чыккан некрологта шагыйрьне соңгы юлга озату күренеше татар милләтенең уянуы, Яңарыш дулкынын кабул итү символы буларак тасвирлана: хатын-кызларның надан, иске фикерле муллаларның рөхсәтләреннән башка, хәлфәләренең сүзләренә каршы килеп, яраткан шагыйрьләре белән хушлашырга беренче тапкыр җеназага килүләрен, Европа цивилизациясенә омтылу, искелек һәм яңалык көрәшендә соңгысының җиңеп чыгуы кебек кабул ителә [Смерть мусульманского поэта...]. Гади халык арасында йорттан йортка, кулдан кулга күчеп тәрбияләнгән Тукайның авыр язмышын М. Горькийныкы белән чагыштырулар, рус әдәбиятыннан, аерым алганда, Пушкин, Лермонтовтан үрнәк алып язылган татар шагыйренең әсәрләренә үзгә игътибар бирелгән мәкаләләр дә дөнья күрә. Шул ук вакытта «Оренбургская газета» шагыйрь лирикасы-

ның шәркый сыйфатлар белән, бигрәк тә фарсы әдәбияты традицияләре белән баетылуын искәртеп, Тукай шигъриятен рус, татар, Шәрык әдәбиятларының гүзәл синтезы итеп тасвирларга омтыла [Немвродъ].

«Оренбургская газета» Тукай иҗатына багышланган тәнкыйди публицистик язмалар гына түгел, шагыйрь шигырьләрен беренче тапкыр рус телендә укучыга тәкъдим итү мәйданы булуы белән дә кыйммәтле. Әйтергә кирәк, шагыйрь иҗатын рус телендә яңгыратырга омтылыш (үзе исән вакытта цензура документларда сүзгә-сүз бирүне санамаганда) вафатыннан соң, 1913 елда ук башлана. Н. Ашмарин, С. Якуб, Акчурин тарафыннан 1914 елда «Восточный сборник»та (Мәскәү) татар шагыйренең «Мәхәббәт», «Өзелгән өмид», «Шүрәле», «Милли моңнар», «Бишек җыры», «Теләнче», «Эштән чыгарылган татар кызына» исемле шигырьләре тәрҗемә ителеп басылуы билгеле [Конова, Гараева, б. 150]. «Оренбургская газета»ның Россия милли китапханәсендә сакланган саннарга күзәтү ясаганда, Тукайның 1913 елда ук рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләре белән танышу мөмкинлеге туа. Күренекле әдәбиятчы Җамал Вәлиди 1914 елның башында чыккан «Габдулла Тукай мәҗмугаи әсәре»нең кереш өлешендә болай дип яза: *«Оренбургская газета»сының баш мөхәррире вә “Изгнанникъ” имзасы илә язучы, шагыйрь Тукаевның “Нәсыйхәт” дигән шигырене русчага тәрҗемә итеп, гәзитәсендә баскан иде, шуны бунда дәрҗ итәмез»* [Вәлиди, б. 85]. Ул «Проповедь» исемендәге тәрҗемәне дә укучыга тәкъдим итә. Җ. Вәлидидән соң «Изгнанникъ» тәрҗемәләре турында кабат бары XX йөзнең 80 нче елларында профессор Р. Нәфыйков тарафыннан искә алына. Галим «Наш Тукай» һәм «Тукай и его современники» хезмәтләрендә «Изгнанникъ» тәрҗемә итеп бастырган «Өзелгән өмид» («Разбитая надежда») шигыренең шул ук матбугатта 1913 елның 29 май санында басылуын искәртә [Нафигов, с. 12]. «Изгнанникъ» тәхәллүсе белән басылучы тәрҗемәченең кем булуы турында да төгәл билгеләнгән хезмәтләр юк. Р. Нәфыйков фикеренчә, «Изгнанникъ» тәхәллүсе артында яшеренүче автор – шагыйрь Николай Семенович Охотин (1885–?). Җ. Вәлиди сүзләренә караганда, тәрҗемәче – газетаның баш мөхәррире, ләкин ул, кызганычка каршы, мөхәррирнең фамилиясен атамый. 1912 елның 33 нче саныннан алып 1914 елның 248 нче санына кадәр «Оренбургская газета»ның баш мөхәррире булып рус шагыйре Иван Николаевич Антонов (1878–1936) торган [http://feb-web.ru/feb/periodic/bb-abc/bb2/bb2-5315.htm]. Шулай ук рус матбугатында кулланылган псевдонимнарны өйрәнүче И.Ф. Масанов хезмәтендә дә И.Н. Антоновның «Оренбургская газета»да әлеге псевдоним белән басылуы искәртелә [Масанов, с. 431]. (И. Масанов сүзлегендә Р. Нәфыйков атаган шагыйрь Н. Охотинның да «Изгнанникъ» тәхәл-

лүсе белән язуы әйтелә, ләкин аның «Оренбургская газета» белән бәйләнеше күрсәтелми.) «Изгнанникъ»ның әлеге газетада «Мусульманский концерт», «Маевка» кебек публицистик рухтагы мәкаләләре, «Уснули цепи», «Песнь славянки», «Из песень Изгнанника» кебек шигырьләре дә очрый. Димәк, Тукай шигъриятен рус укучысына беренче булып таныткан матбугат – «Оренбургская газета» һәм тәрҗемәче – «Изгнанникъ» (И.Н. Антонов) дия алабыз. «Разбитая надежда» исеме белән тәрҗемә ителгән әсәрнең барлыгы турында Р. Нәфыйков хезмәтләрендә үк билгеләнсә дә, бу тәрҗемә «Оренбургская газета»дан башка беркайда да басылмый һәм фәнни әйләнешкә кертелми. *«На мотив Абдулла Тукаева. С татарского, по подстрочному переводу»* дип билгеләнгән юлларда «Изгнанникъ»ның татар шигыренең эчтәлеген үзгәртмичә ачып бирергә, оригиналдан ерагаймау, төгәл тәрҗемә бирергә омтылу ачык сизелә. Ләкин урыны-урыны белән Тукайның укучыга тапшырырга омтылган хис өермәсе рус телендә икеюллыкларга сыеша алмыйча, строфадан строфага җәелә. Оригиналдагы 10 бәйт тәрҗемәдә 12 гә кадәр җитә. Мисал өчен, *«И мөкаддәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз? / Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!»* дигән юллар *«О, святая и нежная Муза моя! / Что так мало звучала мне арфа твоя? // Эта арфа разбита…Уж ей не цвести, / Я-же гасну… О, Муза родная, – прости!»* – дип тәрҗемә ителә. Түбәндә ХХ йөз башы рус матбугатында гына сакланган әлеге тәрҗемәне тулы килеш тәкъдим итәбез:

**Разбитая надежда**

На мотив Абдулла Тукаева.
(С татарского, по подстрочному переводу).

Уже не теми глазами смотрю я на мир…
Чую – юность прошла, обветшал мой кумир!..

Если кину я взор в небо жизни моей –
Вместо полной луны – отблеск кротких лучей…

На бумагу мою текут, как ручьи,
Молодые и чистые искры любви.

О, святая и нежная Муза моя!
Что так мало звучала мне арфа твоя?

Эта арфа разбита… Уж ей не цвести,
Я-же гасну… О, Муза родная, – прости!

Взвилась птица-душа из тюрьмы мировой,
Я для мира рожден, но для мира – чужой.

Что могу я запеть на деревьях родных?
Все засохли они… Нет листочков живых.

Не была моим другом и ты, моя мать,
Что улыбкой умела мой путь освещать…

Моя бедная мать! Ты в слезах умерла…
О, зачем ты чужим меня миру дала?

С первых ласк до последних лобзаний твоих
Был гонимым твой сын от порогов чужих!..

Всех сердец и добрей и теплей и нежней
Будет камень холодный могилы моей…

Так пускай-же в могилу и жизни и грязь
Канет горечь и сладость – непонятных слёз!

Казанга зур өметләр баглап кайткан Тукайның хыяллары чынга ашмау – төшенкелеккә, дөньяда үзен ят, ялгыз итеп хис итүгә китерә. «Бар күңелләрдән җылы, йомшак» урын, бар юанычы – әнкәсенең кабер ташы, шунда иң ачы һәм татлы күз яшьләренең тамуы, дөнья читлегеннән тарсынып очкан күңел кошы фанилыктан баш тартып, мәңгелеккә омтылуны хәтерләтә. Тиздән «МОҢЛЫ САЗЫ» – иҗатының да яшәү мәгънәсе була алмаячагы, сыначагы, сүнәчәге турында хәбәр итеп язылган «Өзелгән өмид» шигыре тәрҗемәчеләрнең игътибарын җәлеп итә. «Изгнанникъ»тан соң, 1914 елда Н.Ашмарин әлеге шигырьне турыдан туры чәчмә формада, соңрак XX йөзнең икенче яртысыннан соң П. Радимов, А. Ахматова «Разбитая надежда», Р. Бухараев «Утраченная надежда», Р. Думаева-Вәлиева «Разбитые надежды» исемнәре белән рус теленә тәрҗемәдә яңгыраталар.

**Әдәбият**

*Бартольд В.В.* Татарский поэт Абдулла Тукаев // Мир ислама. 1913. Т. 2. Вып 3. С. 152–169.

Смерть мусульманского поэта // Оренбургская газета. 1913. 26 апреля.

*Немвродъ.* Абдулла Тукаев (некролог) // Оренбургская газета. 1913. 27 апреля.

*Конова А., Гараева Н.* Новый арабский перевод «Шурале» Г.Тукая // Г.Тукай тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011. Б. 150–153.

*Вәлиди Җ.* Габдулла Тукай мәҗмугаи асаре. Казан: Мәгариф, 1914.

*Нафигов Р.И.* Тукай и его окружение. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986.

http://feb-web.ru/feb/periodic/bb-abc/bb2/bb2-5315.htm / Фундаментальная электронная библиотека.

*Масанов И.Ф.* Изгнанникъ // Словарь псевдонимов русских писателей, ученых и общественных деятелей: в 4 т. Т. I. М., 1956.

***Мөбарәкшина Алия Раеф кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре*
*aliya-891163@mail.ru*

УДК 821.512.145-2

***Л.М. Тимерова***

# И. НУРУЛЛИН ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ Г. ТУКАЙ ТЕМАСЫ

В статье анализируется малоизвестная нынешней публике драма И. Нуруллина «Тукай в Петербурге» о Тукае, где главный герой предстает как личность, творец, общественный деятель, выражающий интересы и чаяния народных масс.

**Ключевые слова:** драматургия, литературная критика, И. Нуруллин, Тукай, литература XX века.

Тукай иҗатын фәнни яктан җентекләп өйрәнүче галимнәрнең берсе – Ибраһим Нуруллин. Әлеге эшчәнлекнең үзәк линиясен хезмәттәше һәм укучысы Зәет ага Мәҗитов «Ибраһим Нуруллинга 60 яшь» мәкаләсендә түбәндәгечә билгели: «Ул Тукай иҗатын өйрәнергә үз өлешен кертеп кенә калмый, бөек шагыйрьнең иҗат йөзен ачыклау, аның татар әдәби процессындагы урынын һәм ролен фәнни дәлилләү өлкәсендә дә эшләвен дәвам итеп, Тукай шигъриятенең гомуми әдәби кыйммәтен ачыклау юлында зур казанышларга иреште» [Мәҗитов, 1983].

И. Нуруллинның бай мирасханәсендә ГабдуллаТукай темасын чагылдырган әдәби әсәрләр дә, гыйльми эзләнүләр дә зур урын алып тора. Шунлыктан ул фәнни җәмәгатьчелектә дә күбрәк тукайчы буларак танылган. Галим еш кына: «Тукай – минем бөтен тормышым», – дип әйтә торган булган. И. Нуруллинның – Тукайга багышланган прозасы, фәнни мәкаләләре, «Тукай эстетикасы», «Тукай иҗаты» монографияләре моның шулай икәнлеген ачык дәлилли. Телгә алган язмаларында галим шагыйрь тормышын төгәл яктыртырга омтыла, аның иҗат үзенчәлекләрен һәм мәгънә юнәлешен билгели.

Барлык гомерен Тукай иҗатын өйрәнүгә багышлау каләм иясе чыгарган китапларда да чагылыш таба: ике мәртәбә «Тукай турында хикәяләр» җыентыгы дөнья күрә, 1967 елда рус телендә «Поэт из деревни Кырлай» исемле китабы басыла, 1986 елда «Моңлы саз чыңнары» әсәре тәмамланганнан соң, шунда ук нәшриятлардан заказ да алына. Мәскәүдә (1977) һәм Казанда (1979) «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә басылып чыккан «Габдулла Тукай» романы әдипкә тагын да зуррак уңышлар алып килә – аның өчен Ибраһим Нуруллинга 1982 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Үзенең фәнни хезмәтләрендә, документаль-сәнгати әсәрләрендә Ибраһим Нуруллин ныклы дәлилләргә таянып эш итә. Ул шагыйрь иҗатының кыйммәтен генә ачып калмый, ә аның йомшак якларын да күрсәтә, аларның сәбәбен дә аңлата. Габдулла Тукай укучы каршына

психологик яктан бербөтен сыйфатында килеп баса, аның бөек шагыйрь сыйфатында гына түгел, тере кеше буларак та кызыклыгы, үзенчәлекле шәхес икәнлеге ачыла. Галимнең Тукайны тормыштагыча тасвирлап язуын заманында бөтен кеше дә хуплап каршы алмый. Кайбер галимнәр аны Тукайның дәрәҗәсен төшерүдә гаепләп тә чыга. Ә Тукайны ничек бар шулай яратучылар исә хезмәтне югары бәялиләр. Бигрәк тә чит милләтләр, әйтик, башкорт, рус, үзбәк, казакъ, осетин әдәбияты вәкилләре бөек шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын чынбарлыктагыча дөрес чагылдырганы өчен галимгә үзләренең рәхмәтләрен белдерәләр.

Тукай яшәгән заманның эченә үтеп керү, аның рухын күзаллау өчен, бөек шагыйрьнең үз тормышын өйрәнү белән бергә, аның янәшәсендә иҗат иткән, аның белән аралашканнарны да, аерым алганда Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, ул чагында тыелган әдип Г. Исхакый кебек бөек шәхесләр белән мөнәсәбәтләренең нечкәлекләрен, аларның көнкүрештә һәм иҗатта чагылуларын белергә кирәк. Фәннәр академиясенең Казан филиалы оештырган экспедициягә ияреп, галим Тукайның туган якларында йөреп, шагыйрьне азмы-күпме белгән, аның турында ишеткән кешеләр белән очрашып, истәлекләр җыеп кайта һәм очерк яза.

И. Нуруллин бөек шагыйрь иҗатын һәртөрле каршылыклардан, кимчелекләрдән азат итеп, бизәп күрсәтүләр белән беркайчан да килешми. Ул Тукай иҗатын олы хөрмәт хисе һәм чын фәнни игътибар белән якын килеп бәяли. Фәнни эзләнүләр алып килгән нәтиҗәләрне ул әдәби иҗатында да файдалана. Әйтик, Тукайның тормышчан образын драматургиягә дә алып керә.

«Тукай Петербургта» пьесасында, исеменнән үк күренгәнчә, Тукай белән бәйле Петербург вакыйгалары бергә туплана. Әлеге әсәре белән татар әдәбиятында «алтын дәвер» кебек билгеләнгән чорның иң күренекле вәкилләренең берсе булган Габдулла Тукайны һәм шәхес, һәм әдип буларак ачарга, фаҗигале язмышының сәбәпләрен күрсәтергә алына. Повестьның нигезенә шәхес һәм җәмгыять каршылыгы салынган. Замананың катлаулы, буталчык булуы шул чор кешесендә билгеле бер сайлау, икеләнү тудыра. Кайберәүләр, намусларын калкан итеп, Кеше дигән бөек исемгә тугры кала. Икенче берәүләр исә, идеологиягә буйсынып, алар алдында «тәлинкә тотып», шулар җырын җырлап, шәхси мәнфәгатьләрен барыннан да өстен куеп көн күрә һәм еш кына теләсә нинди түбәнлеккә төшә.

Дөрес, татар әдәбиятында танылган шәхесләрнең әдәби образларына мөрәҗәгать итү – киң таралган күренеш. Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Сөембикә, Кол Шәриф, К. Насыйри, Акмулла, М. Җәлил һәм башка шундый күренекле әдипләргә багышланган әсәрләр байтак. И. Нуруллинның «Тукай Петербургта» драмасы исә XX гасыр башының мәшһүр шагыйре Тукай образын җанландыра.

«Тукай Петербургта» драмасы, тыштан караганда – 1912 елда Тукайның Петербургка килүе,

аның аралашу даирәсе, бүтәннәргә сиздерергә теләмәгән яшерен проблемалары турында. Ә гомумән алганда, автор анда Тукай образын бай хис-кичерешләргә, күпкырлы шәхескә генә хас булган холыкка ия зур талант итеп күрсәтә, сәхнә мөмкинлек биргән дәрәҗәдә чорның иҗтимагый-сәяси җирлегендә, татар халкының идеаллары яктылыгында ачып бирә.

Пьеса тормыш фактларына гына корыла. Галим моның өчен күләмле тарихи материалны эшкә җигә, Петербург, Казан архивларында була, вакытлы матбугатны, Тукай турында замандашлары язып калдырган хезмәтләрне өйрәнә. Тукай, белүебезчә, чыннан да, 1912 елның апрелендә Петербургка килгән. Шагыйрьнең әлеге шәһәргә бару тарихы, сәбәп-шартлары пьесада төп геройның үз теле белән болай тасвирлана: «Дус-ишләр котыртты: яз җиткәч, рәтле кеше Казанның кабих һавасыннан качып, табигать эченә китә, диделәр. Үземне рәтле кешегә санауларына күңелем булып, кыш буе арка туңудан гаҗиз булган мин, фәкыйрь, тиз генә җыендым да Уфа ягына юнәлдем. Агачлар яфракка бөреләнгән, әмма кымызга иртә. Кесәдә – Петербургка чакырып язылган хат. Сабыйлык бишегеннән төшкәннән бирле шуны күрү хыялыннан җылынып яшәгән мин бичарага ни кала? Бу сәфәрне кичектереп торырга, суыклар беткәнне көтәргә кыстадылар. Тыңламадым. Телеграм. Ответ. Киттем» [Нуруллин, б. 177].

Пьесада вакыйга-күренешләр Санкт-Петербургта гына бара. Тукай, әлеге шәһәргә килгәч, Гайсә Агиевлар фатирында туктала. Бу елларда Тукайның үпкә авыруы билгеләре көчәйгән була. Петербургка аны, үзенә әйтмичә генә, шул сәбәпле дуслары чакыра. Борынгы башкалада яшәүче татар байлары арасында үз акчаларына аны дәваларга теләүчеләр дә табыла. Болар барысы да эчтәлектә ачык чагылыш таба.

Сәхнә әсәрендә холык, гадәттә, геройның эш-хәрәкәтләре аша ачыла. Бу пьесада Тукайга хас сыйфатлар, портрет үзенчәлекләре әле әсәр башында ук Нәсимә образы аша әйттерелә: «...яшүсмер кыяфәтле бер адәм! Ябык, алҗыган. Хатын-кыздан тартына» [Нуруллин, б. 165]. Әдип аның рухи матурлыгын тышкы кыяфәтеннән өстен сурәтли. Янәшәсендәге кешеләр шагыйрь авыруының бик җитди икәнен дә, озак яшәмәячәген да беләләр. Аны «бер аягы белән кабердә инде» диләр. Бу сүзләр Нәсимә тарафыннан Тукайга «гомерлек юлдаш булырга» теләгән Газизәгә атап әйтелә.

Пьесадагы Тукай образына хас сыйфатлар гына түгел, башка геройларныкы да, безнеңчә, прототипларыныкына туры килә. Шагыйрьнең ярдәмчел дуслары күп булган. Моннан тыш, аның янәшәсендә икейөзлеләр, көнләшүчеләр, аяк чалучылар да яшәгән. Автор үзәк геройның якын дуслары сыйфатында халыкка аз билгеле Хәбирне һәм татар революционеры Мулланур Вахитовны тасвирлаган. Шул ук вакытта, прототибына ничек кенә туры килмәсен, Тукай белән

очрашуы да билгеле булмасын, Совет идеологиясе йогынтысы тәэсирендә, әлеге образ пьесага махсус кертелгән дигән тәэсир кала, революционер артык идеаллаштырыла, зур көрәшче, халык каһарманы сыйфатында гәүдәләндерелә. И. Нуруллин «Тукай Петербургта» әсәрендә шагыйрьне әдәби процесс, сүз сәнгатенә гомуми караш фонында ача. Аның уңышы Тукай образын үсеш-үзгәрештә һәм каршылыклы шәхес итеп күрсәтүендә дип уйларга кирәк.

Галим-филолог, язучы Ибраһим Нуруллиның киңкырлы эшчәнлеген күзәткәннән соң, чыннан да, аның универсаль белемнәр һәм талант иясе булуын күрәбез. Аның фән һәм матур әдәбият өлкәсендәге ачышлары, башкарган хезмәтләре бәяләп бетергесез кыйммәткә ия. И. Нуруллинның сәхнә әсәрләре тудыруы, Тукай һәм иҗатчылар темасын тирәнтен өйрәнүе һәм шуны халыкка җиткерергә теләве белән бәйле. Аның Г. Тукайга багышланган фәнни хезмәтләре дә, хикәяләре дә, фәнни-популяр әдәбиятка караган әсәрләре дә бар. Шагыйрьне уздырып тезмә сүз тудыра алмаячагын белгән язучы аның олы образын сәхнәгә күтәрә, шулай итеп, әлеге теманы татар драматургиясендә генә түгел, гомумән, әдәбиятта да популяр итә. И. Нуруллин үрнәгендә Р. Батулла, Т. Миңнуллин тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр дә татар сәхнәсенә күтәрелә.

И. Нуруллинның Тукай турындагы пьесасы үз чорында тамашачы күңелен тиешле югарылыкта яуламый, чөнки әлеге әсәр фикергә корылган драма була, ә андыйлар татар тамашачысы арасында бервакытта да популярлык казана алмый. Әлеге пьеса куелган чор тәнкыйтендә дә гаеп бар – И. Нуруллин әсәренә тәнкыйтьчеләр тарафыннан тиешле игътибар бирелми. Хәтта артистлар уйнавын анализлаган язмалар да матбугатта булмый. Моңа карап кына, пьеса яхшы язылмаган, дип нәтиҗә ясарга ярамый, әсәрнең камиллеге турында сүз йөртү өчен, драма әсәренә анализ ясау кирәк.

Пьесаның конфликты гади түгел, каһарман алдында авырлык-кыенлыклар һаман туып тора, ул киртә-каршылыкларны үтү өчен һәрберсенә зур көч куя. Укучының игътибарын җәлеп итү, үзенә тарту өчен, әсәр үзәгендә мәхәббәт вакыйгалары булу мөһим. И. Нуруллин укучы игътибарын юнәлтерлек андый вакыйгаларны эчтәлеккә кертә, ләкин егет-кыз арасындагы мөнәсәбәтләр билгеле бер чикне узмый, чөнки автор шагыйрь биографиясенә чынбарлыктан тыш интригалар тудырырга теләми. Драмада Тукайның кызлар белән очрашуы, аларга атап шигырьләр язуы, фоторәсемнәр алышуы турында урыннар бар. Без Тукайның, чыннан да, Зәйтүнә Мәүлүдова һәм башка берничә кыз белән очрашканын, алдынгы карашлы туташлар белән аралашканлыгын беләбез. Әмма ул мөнәсәбәтләр артык тирәнгә керми. И. Нуруллин да вакыйга-күренешләр аша шуңа ишарә иткән кебек.

«Шагыйрь үзе шигырьләрендә яши» дигән гыйбарәне еш

ишетергә туры килә. И. Нуруллин да Тукай шигырьләрен, аерым штрихларда гына булса да, зәвыклы укучы-тәнкыйтьче буларак бәяли, шулар аша шагыйрьнең күңел дөньясын ачарга тырыша. Гомумән, әсәрдәге драматик хәрәкәтне үстерүдә шигъри текстлар зур роль уйный. Тукайны иҗатчы буларак бәяләп, драматург аның шигъриятенең үз чорында гына түгел, һәр заманда актуаль яңгыраш алуын күрсәтә.

Тукайны кеше буларак ачып бирү өчен зур җаваплылык таләп ителсә дә, драматург үз максатына ирешкән. Шагыйрь образының эш-гамәлләре, характер сыйфатлары, хатын-кызларга булган мөнәсәбәте автор тарафыннан искиткеч оста итеп сурәтләнгәнгә күрә, ул укучыны ышандыра. Шагыйрь тирәсендә образларның чагыштырмача тонык булуы әлеге образны калку, тагын да ягымлырак итә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтә алабыз: татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышлап пьеса тудыру, аның образын иҗат итү өчен, автордан гаять зур көч, җитдилек, катлаулы һәм системалы эш һәм, ниһаять, шагыйрьгә, аның иҗатына, гомумән, поэзиягә олуг мәхәббәт таләп ителә. Ул эш ашыгу-кабаланруны да, игътибарсызлыкны да, ниндидер конъюнктура таләпләрен, берьяклы социологик карашларны да кичерми. Тукай – гомумкешелек шагыйре, шунлыктан аның образы, иҗаты һәм тормыш юлы гомумкешелек кыйммәте принципларыннан чыгып бәяләнергә, ә аны шул рәвешчә ачкан пьеса сәхнәдә лаеклы урын алырга тиеш.

**Әдәбият**

*Мәҗитов З.* Ибраһим Нуруллинга 60 яшь // Соц. Татарстан. 1983. 17 апр.

*Нуруллин И.* Тукай Петербургта // Аның йолдызы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. Б. 164–238.

***Тимерова Ландыш Мулланур кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты аспиранты*
*MLand@mail.ry*

УДК 821.512.145

*А.Г. Әхмәдуллин*

# БӨЕК ШАГЫЙРЬНЕ ЗУРЛАП ҺӘМ ЯКЛАП

В статье освещается научный вклад писателя Ф. Бурнаша в развитие тукаеведения как отдельного направления татарского литературоведения. Автор подчеркивает заслугу писателя в освобождении имени Г. Тукая от клейма буржуазной идеологии, выдвижении идеи о народном характере творчества поэта, благодаря которому Тукай остается великим поэтом.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, Ф. Бурнаш, народный писатель, татарская советская литература, пропаганда.

Г. Тукайның аны чиксез зурлаган һәм олылаган, кирәк булганда яклаган күренекле шәкертләреннән берсе – ул Фәтхи Бурнаш.

Фәтхи Бурнаш әдәби иҗатка бик иртә килә. Әле мәдрәсәдә укыганда ук ул җыр-сәхнә, әдәбият белән ныклап кызыксына. Мәдрәсәдә аннан берничә сыйныф түбән укыган Нәкый Исәнбәт әйтүенчә, Фәтхи рус һәм чит ил язучылары әсәрләрен, аерата Шекспирны бик бирелеп укый. Шулай да аның иң яраткан язучысы Габдулла Тукай була. «1914–1915 елларда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укучы шәкертләрдән Фәтхи Бурнаш һәм Нәкый Исәнбәтләр тарафыннан берничә төрле әдәби, сатирик кульязма журнал чыгарыла, – дип яза бу өлкәне махсус өйрәнгән Мостафа Ногман. – Аларның битләрендә шәкертләр тормышы, яшьләр хәрәкәте турында мәкаләләр белән бергә, яшьләрнең әдәби омтылышларын чагылдырган аерым әдәби парчаларга да урын бирелә». Ф. Бурнашның боларда басылган беренче шигырьләре, эпиграммалары яшь авторның тулысы белән Г. Тукай тәэсирендә булуын күрсәтәләр.

Халык шагыйренә булган олы мәхәббәте Ф. Бурнашны гомере буе озатып һәм җылытып бара. Вакыты-вакыты белән ул аны җайсыз хәлләргә дә куйгалый. Менә мисал:

...1914 елның 15(2) апрель иртәсе. «Мөхәммәдия» шәкертләре, кыңгырау шалтырау белән үк, бинадагы иң зур дәресханәгә җыйналалар. Дүрт йөздән артык шәкерт, алларында – дини әдәбият дәреслекләре. Ишек төбенә сакчылар куелгач, дәреслекләр ябыла. Фәтхи Бурнаш кайгы мәҗлесен Г. Тукай истәлегенә нотык сөйләп ачып җибәрә. Сөекле шагыйрь турында истәлекләр сөйләнә, аның шигырь-поэмалары, аңа багышланган әсәрләр укыла. Вакыйга яшерен калмый, зур җәнҗал куба, эш полициягә барып җитә. Ф. Бурнашның оештыручы булуы беленә. Эзәрлекләүләр башлана һәм 1915 елда ул «Мөхәммәдия»дән китә.

Ф. Бурнаш – поэзиядә Тукай мәктәбенең талантлы шәкертләреннән берсе. Аның күпчелек шигырьләре Тукай иҗат иткән шигъри үлчәүдә (10 – 10, 12 – 12, 15 – 15 иҗек) язылган. Ул бөек шагыйрь үрнәгендә поэмаларында бәет формасын файдалана («Мөхәммәтҗан» поэмасында); халык шагыйренең аерым юлларына мөрәҗәгать итә («Ике дус» сатирик поэмасында: «Әй пешерде, әй пешерде, әй пешерделәр, туган!») һ.б.

Совет әдәбияты әле беренче адымнарын гына атлаган чорда тәнкыйтьчеләр полемика кылычларын кисештергән нокталарның берсендә классик мираска мөнәсәбәт, аны аңлау һәм аннан файдалану кебек мәсьәләләр ята. Социалистик революциянең беренче чорында вату-җимерү тенденциясе көчле була, аны аңлау да, эшләү дә ансатрак булган. Шулай да пролетариат революциясенең асыл эчтәлеген яңаны төзү тәшкил итә. Шуны күрмәү һәм аңламау, ә гел кире кагу, вату-җимерү омтылышын гына алга сөрү, аны халык хуҗалыгының да, культураның да барлык өлкәләренә бердәй дәрәҗәдә күчерергә тырышу икенче чиккә төшерергә мөмкин иде, һәм еш кына ул шулай булып чыга да. Тәнкыйть белән артык мавыгу, яраксызга чыгару һәм кире кагу зарарлы бер күренешкә әверелә. Ул әдәбият һәм сәнгать өлкәләрендә дә үз тамырларын җибәрә. Үткән мирастан баш тарту, алай гына да түгел, аны яңа җәмгыять өчен зыянлы дип санау бигрәк тә пролеткульчыларга хас. Монда алар «үткәндәге культура буржуаз эчтәлекле иде, шуңа күрә дә пролетариат өчен ят һәм дошман иде» дигән берьяклы һәм ялгыш караштан чыгып эш итәләр.

Ф. Бурнашның мәкалә һәм рецензияләре аның бу мәсьәләдә асылда дөрес караштa торуын күрсәтә. Язучы бу җәһәттән мәкаләдән мәкаләгә, чыгыштан чыгышка үсә бара.

Бигрәк тә ул халык шагыйре Габдулла Тукай мирасын урынсыз һөҗүмнәрдән саклау, бу мирасның гаять зур әһәмиятен аңлату буенча җитди эш башкара. Бүген һич шикләнмичә: Г. Тукай иҗатын өйрәнүчеләрнең һәм аны пропагандалаучыларның иң күренеклеләреннән берсе Ф. Бурнаш булды, дип әйтергә мөмкин. Г. Тукайны өйрәнү белемен чын мәгънәсендә фәнни нигезгә куюда Ф. Бурнаш мөһим роль уйный. Тукай мирасының әһәмиятен билгеләү, аның иҗатын тиешле фәнни-нәзари нигездә тикшеренүләргә ул лаеклы өлеш кертте.

Г. Тукай иҗаты Октябрь революциясенә кадәр үк киң танылган, татар укучыларында гына түгел, башка төрки халыклар арасында да хөрмәт казанган иде. Буржуаз караш яклылар һәм кайбер эстет-тәнкыйтьчеләр шагыйрьнең бу популярлыгын үзләренчә аңлатырга маташтылар. Шагыйрьнең популярлыгын да алар татар милләтенә, аның баена да, ярлысына да тигез карауда, төрле сыйныф һәм катлауларны үзара тиң күрүдә, аларның уй-фикерләрен, теләк-омтылышларын тигез чагылдыруда дип аңлатырга омтылалар. Бу иҗатның төп көче хезмәт иясенә,

аның күңелен биләгән, аның алдынгы карашларын чагылдырган мәсьәләләргә багышланган булуда икәнен танымау алга сөрелә, шуның белән бу мирасның бай халыкчан эчтәлеге юкка чыгарыла. Никадәр гаҗәп тоелмасын, бу караш алга таба Г. Тукайга һәм, аның кебек, иҗатлары революциянең теге ягында тәмамланган яки өзелеп калган башка революцион-демократ язучылар мирасына каршы чыгу өчен пролеткультчыларга «әйбәт» хезмәт итә. Чөнки, мәгълүм булганча, соңгылары пролетар культураны «чиста» хәлендә, ягъни аерым сыйныф – эшчеләр сыйныфы тарафыннан гына барлыкка кителгән хәлендә күзаллыйлар. Ә бу исә, үз чиратында, культура өлкәсендә пролетариатның башка хезмәт иясе сыйныфлардан һәм төркем-катлаулардан аерылуына, соң чиктә, аңарчы тудырылган культура байлыкларын танымауга, санга сукмауга китерәчәк иде. Шулай килеп чыга: шагыйрь үз иҗатында байны һәм ярлыны аермый икән, димәк, ул – тулаем буржуаз сыйныфка хезмәт иткән. Ә моннан инде: аның социалистик җәмгыятьтә кирәге дә шулкадәр генә, дөресрәге, кирәге юк! – дигән нәтиҗә сорала.

Ф. Бурнаш, иң беренче, шагыйрьнең халыкчанлыгын ачуга игътибар итә. Һәм бу халыкчанлыкның нигезләрен нәкъ менә милләтнең күпчелеген тәшкил иткән хезмәт иясенең тормышын, аның теләк-омтылышларын, тарихын һәм киләчәген аның үзенә тулы аңлатырлык тел һәм художество чаралары ярдәмендә ачып бирүендә күрә. Бу яктан «Тукай шигырьләрендә иҗтимагый моңнар» (1922) исемле шактый ук күләмле мәкаләсе бигрәк тә мөһим. Монда аның Тукай турындагы башка кулъязма һәм басылган мәкалә-хезмәтләрендәге концепциясе беренче тапкыр бербөтен төстә ачыла. Автор шагыйрь әсәрләренең изелүче сыйныфка хезмәт итүенә басым ясый. «Тукай – милләт эчендәге изүче сыйныфка һәрвакыт каршы булды», – ди ул, шуны күптөрле мисаллар ярдәмендәраслый, һәм нәтиҗә чыгара: «Кыскасы, Тукай гаммә җырчысы. Аның теле, тарызы (ягъни, стиле), ифадәсе (ягъни, сүз сөреше) гади, татарча, табигый, гавамча садә. Менә шул җәһәттән үзенә кадәр һәм үз заманасында туган шагыйрь, назыймнардан (көйләп язучылардан) аерым тора. Ул үзенең иҗаты белән гүя безгә Тукай булып күренми, гүя аның шигърияте Тукай вывескасы куеп чыгарылган гаммә моңы, гаммә зары. Шуның өчен аның үз заманасында ук Тукайга каршы бер хәрәкәт туган да иде, – дип дәвам итә ул. – Шуның өчен «Татар шагыйрьләре» исемле әсәрендә Г. Ибраһимов Тукайның шагыйрьлеген инкарь итәргә газапланган да иде. Имеш, ул Сәгыйть Рәмиев төсле һич халык, гаммә белән хисаплашмаган, индивидуальный бер моң, саз иҗат итә алмаган. (...) Имеш, ул тик халык моңланган нәрсәләрдән генә моңлана алган, аның зарларында гына үзенең күңел кылларын хәрәкәтләндерә алган... Әйтерсең лә, Тукайның шүрәлеләре, су аналары, Кабан артлары – алар иҗат түгел».

Вакыты белән Тукайның үз әсәрләрендә төшенкелек мотивларын җырлавын кайбер тәнкыйтьчеләр шагыйрь иҗатының кимчелеге итеп күрәләр. Ф. Бурнаш исә моны авторның дөньяга карашы үсешенең каршылыклар эчендә баруы белән, шул вакыттагы тарихи-иҗтимагый шартлар һәм шагыйрьнең шәхси үзенчәлекләре белән аңлата. Күзгә күренми торган меңнәрчә җепләр белән хезмәт иясенә бәйләнгән олы талантның төшенкелеге дә халыкның шул вакыттагы рухи халәтен чагылдыра, билгеле бер тарихи дәвердәге үсеш дәрәҗәсен күрсәтә.

Әлбәттә, 1920–1930 елларда канатын киң җәйгән вульгар социологизм тәэсире Ф. Бурнашка да билгеле бер дәрәҗәдә кагылмый калмаган. Шуның нәтиҗәсендә аның тәнкыйтендә әдәби әсәрләрнең һәрвакыт идея ягына гына игътибар итеп тә, аларның сәнгати эшләнешләрендәге үзенчәлекләрне күреп җиткермәү, һәрнәрсәдән иҗтимагый мәгънә эзләү, тарихилык принцибын аңлап бетермәү кебек кимчелекләр урын алгалый.

Аның Г. Тукай турында язганнары арасында да кайбер төгәлсезлекләр күренә. Мәсәлән, ул шагыйрьнең әдәбиятны, аның үсеш тарихын тирән белүен шик астына куярдай саксыз фикер әйтә, «башта ул рус әдәбияты белән өстән-өстән генә таныш булган» дигән сүзләр яза, яки, әнә ул Шәрык әдәбиятының Тукайга тәэсирен бары тик сүз һәм сурәт кулланышында гына күрә. Халык шагыйре иҗатын өйрәнгән галимнәрнең бүгенге казанышлары яктылыгында мондый фикерләрнең хакыйкатькә туры килмәве ачык.

Шуларның һәммәсен күз алдында тоткан хәлдә дә, Ф. Бурнашның әдәби тәнкыйть мәкаләләре үз чоры өчен дә, бүген дә гаять әһәмиятле роль уйнады һәм уйный, дип кистереп әйтә алабыз. Мисал өчен тагын да аның «Тукай хакында тәнкыйьчеләр» (1923) дигән мәкаләсен алып карарга була. Монда Ф. Бурнаш атаклы шагыйрь иҗатын бозып аңлатуларны ышандырырлык итеп ачып бирә. Мәкаләдә аерым алганда язучы Г. Ибраһимовның Октябрь революциясенә кадәр үк басылган «Татар шагыйрьләре» (1913) исемле китабы тәнкыйтьләнә. Бу хезмәтнең бөек шагыйрь мирасын ялгыш аңлатуын күрсәтеп, тәнкыйтьче Г. Ибраһимовтан хата фикерләреннән баш тартуын, шул турыда әйтеп матбугатта чыгуын таләп итә.

1926 елны Ф. Бурнаш татар вакытлы матбугатының 20 еллыгына багышлап, «Г. Тукай шигырьләре» исемле җыентык төзеп бастыра. Бу – шагыйрь әсәрләренең тулырак күләмдә туплап бастырылган җыентыгы. Ул «Төзүчедән» исемле кереш сүз белән ачыла: «Тукай әсәрләре берничә тапкыр җыелып бастырылды. Ләкин хәзер таралып беткәннәр. <...> Шуңа күрә без Тукай әсәрләрен яңадан җыеп бастырырга уйладык. <...> Хәзергә исә без Тукай иҗаты өчен характерлы булган, Тукайның төп хосусиятләрен ачып бирә алырлык әсәрләрен чүпләп җыйдык. <...> техника сәбәпләре аркасында аның

тәрҗемәи хәлен бик кыскача гына итеп бирергә, кайбер әсәрләрен кыскартып кертергә туры килде. Әүвәлге мәҗмугаләренә кергән кайбер шигырьләр бу мәҗмугагә кермәгән шикелле, бу мәҗмугагә әүвәлге мәҗмугаләрендә күрелмәгән кайбер шигырьләр дә өстәлде».

Җыентыкка Ф. Бурнаш «Тукай шигырьләренә караш» дип исемләнгән шактый ук зур күләмле, шагыйрь иҗатын иңләп алган кереш мәкалә бирә. Монда ул шагыйрь иҗатының төп хосусиятләрен күрсәтә: «Тормышы, мохитt; шуларның көндәлек тәэсирләре нәтиҗәсендә Тукайның төп кыллары: нәфрәт, зар, халык моңы, ил фаҗигасен җырлау, кайчан ачы көлү булса да, без аның иҗатында аерым алып тикшерелергә тиешле булган башка хосусиятләрне дә, башка настроениеләрне дә күрәбез». Шуларга да ул махсус туктала. Болар: «сөю-мәхәббәт», «табигать», «Тукайда чит әдәбият», «соңгы зарлар». Бөек шагыйрь иҗатының гаҗәеп киңлеген раслаган бу хосусиятләрне бәйнә-бәйнә анализлап, Ф. Бурнаш нәтиҗә ясый: «Тукай үзенең шигърияте белән революциягә кадәр килгән татар шагыйрьләре дөньясының атасы булып калачак шагыйрь».

Әдәбият галимнәре күпсанлы хезмәтләр язып, Г. Тукайның чын халык шагыйре булуын расладылар. Алар арасында үзенең мәкаләләре һәм шагыйрьнең бөеклеген раслап ясаган чыгышлары белән «тукаеведение» дип аталган фәнгә лаеклы өлеш керткән Фәтхи Бурнаш исемен дә телгә алабыз.

***Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы.***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 821.512.145

***Хәнәфи Бәдигый***

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ – ТУГАН ЯК ҖЫРЧЫСЫ
## (Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм...)

2016 год Указом Президента Республики Татарстан объявлен Годом экологии и защиты окружающей среды. В статье предпринята попытка осветить любовь Г. Тукая к родному краю, особенно к его природе.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, родной край в произведениях Г. Тукая, родная природа, окружающая среда.

*«Аулыбызның ямен, суы тәмен*
*беләм,*
*Шуңа күрә сөям җаным, тәнем*
*белән*

дигән балачактан ук һәркайсыбызның күңеленә тирән сеңеп калган бу кайнар хисле, тирән мәгънәле шигъри юлларны язганда («Туган авыл». «Әдәбият», 1909) Г. Тукайга әле нибарысы 23 яшь кенә булган.

Яшь шагыйрьнең туган як табигатенә җылы мөнәсәбәтен белдерүе, ошбу якты дөньяга үзе дә шул ямьле яз башында килгәнгәме, яз көннәрен тасвирлаудан башлана:

*Кышлар үтеп, яз көннәре килер исә,*
*Сахраларда йомшак саба җиле исә.*
«Яз галәмәтләре» («Фикер», 1906).

*Тыныч торма, каләм, дәртеңне яз!*
*Тагын җитте мөнәвәр яз, аяз яз.*
«Яз» («Ялт-йолт», 1912).

Г. Тукай туган як табигатен рәссамнарча сурәтләп кенә чикләнми, ә бәлки аны авыл халкының тормыш-көнкүрешен, тырыш, авыр хезмәтен, яшәү рәвешен, уй-фикерләрен фани вә бакый дөнья хәлләре белән бергә үреп чагылдыра:

*Терелә, җанланадыр халкы галәм,*
*Яңара халкы Хаува, халкы Адәм.*
*Шулай шул: уйлата яз төрле якны,*
*Димәк ки, бер мәматне, бер хәятны.*
(Шул ук шигырьдә).

Мөнәвәр нурлы, якты. Гәрчә балачагы үксез бала булып, өйдән-өйгә, кулдан-кулга күчеп йөреп, рәхәт күрмичә, кайгы-хәсрәт эчендә узса да, шагыйрьнең шул халәтеннән зарланмыйча, туган ягын шулкадәр саф, самими, ягымлы, яшь аралаш көлеп, кайнар хисләр белән тасвирлавы таң калдырып, сокландыра:

*Аерылып китсәм дә синнән*
*гомремеӊ таӊында мин.*
*И Казан арты! сиңа кайттым сөеп*
*тагын да мин.*
*Ул таныш кырлар, болыннар*
*тартты әвәл хиссеми;*
*Тарта торгач, куймады, кайтарды*
*ахры җисмеми.*
*Җөмләтән изге икән ич: инешең,*
*чишмәң, кырың,*
*Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә*
*ындырың;*
*Һәр фосулы әрбәгаң: язың, көзең,*
*җәй, кыш көнең:*
*Барча, барча ак оек, киндер, чабата,*
*ыштырың!*

*Һәм көтүчең, этләрең, үгез, сыер, сарыкларың;*
*Барчасы яхшы: бүре, җен, шүрәле, сарикъларың.*

«Туган җиремә»
(«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре», 1911. Шигырь «Туган илемә» исеме белән бирелгән).

Әлеге юллар бөек рус шагыйре М. Ю. Лермонтовның *«Ватан»* шигыренә аваздаш булып яңгырагандай:

*Мин сөямен ватанымны бик сәер сөю белән,*
*Бу сөюнең сүрелмәсен мин үзем генә беләм.*
*Яратам мин ни өчендер, белмим шуны үзем дә,*
*Кырга карыйм, салкын тынлык күрәм аның йөзендә.*
*Урманнарның шаулаганын тыңлап торам ерактан,*
*Ватанымның диңгез төсле елгаларын яратам...*
*Мин яратам салам белән ябылган ызбаларны,*
*Тәрәзәсенең рамнарын матурлап сырлаганны.*
*Бәйрәмнәрдә җәйге кичләр, җылы кичләр килгәндә,*
*Әй, күңелле авылларда яшьләр уйнап-көлгәндә.*

Туган җир, туган авыл Г. Тукай өчен ватанга тиң һәм ул аның ямен Лермонтовча гаять тәэсирле сүзләр ярдәмендә дә, гади халыкка бик яхшы таныш булган күренешләр, образлар аша да сурәтләп биргән.

Билгеле, Тукайның авыр язмышлы балачагы Пушкин, Лермонтовларның кайгы-хәсрәтсез, бәхетле балачакларыннан бик нык аерылып тора. Ул аның «Исемдә калганнар» (1909) исемле китабындагы истәлекләрендә бик ачык итеп тасвирлап бирелә:

«Минем туганыма 5 ай заман вакыт үткәч, атам аз гына вакыт авырып, тәрке дөнья итмештер. Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам мине авылыбыздагы Шәрифә исемле карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна нам карьяның имамына кияүгә чыкмыштыр.

...Мин бу карчыкханәсендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән; тәрбияләү түгел, яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән.

Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә, бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак, балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканчы көтеп торам икән. Карчык исә үзенең “Кадалмас әле килмешәк!” дигән “шәфкатьле” фикере илә мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән».

Менә шул рәвешчә, үткән балачагыннан зарланмыйча, шагыйрьнең «Туган җиремә» исемле шигырь яза алуына гаҗәпләнмәү мөмкин түгел.

«Иртә дөнья җанлана, Мәшрикъ ягы аллана, Кояш чыгып нурлары Төшеп җиргә ялгана» («Тәүлек». «Бәянелхак», 1908), «Язның айлары, Апрель, майлары, Бик матур сызылып Аткан таңнары» («Җир йокысы». «Ба-

лалар күңеле», 1909), дип, табигатьнең саф матурлыгын тасвирлау белән бергә, шагыйрь шул ел фасылларына капма-каршы куеп, халыкның авыр, караңгы тормышта яшәвен дә ачып салган:

*Яратырга ярый кышны, вәләкин*
*зәмһәрире бар,*
*Киемсез, калтырап торган мәсакине,*
*фәкыйре бар.*
*Яратырга ярый җәйне: матур ул,*
*анда зур ямь бар,*
*Вәләкин таш бинасы юк*
*фәкыйрьләргә җәһәннәм бар.*

«Яратырга ярый»
(«Әдәбият», 1909).

Г. Тукайның «Пар ат» («Фикер», 1907), «Кошларга», «Карлыгач», «Кышкы кич», «Мәктәптә», «Эш беткәч уйнарга ярый» («Балалар күңеле», 1909), «Җәйге таң хатирәсе», «Җәй көнендә», «Яз хәбәре» («Йолдыз», 1910), «Бер имән» («Вакыт», 1910), «Елның дүрт фасылы» («Яңа кыйраәт», 1910), «Фатима белән Сандугач» («Күңелле сәхифәләр», 1910), «Җил», «Иртә» («Күңел җимешләре», 1911), «Яз галәмәтләре», «Валлаһи» («Ялт-йолт», 1912), «Буран», «Яңгыр», Җил тавышы» («Җан азыклары», 1912) кебек шигырьләрендә туган якның табигате, ел фасыллары, күк җисемнәре, җир-сулары, урман-болыннары, үсемлекләре, кош-кортлары, киек-җанварлары һ.б. турында кызыклы, күп мәгълүматлар китереп, бик матур итеп тасвирлап бирелә.

Әлбәттә, Габдулла Тукайның туган як табигатенә карата булган кайнар мәхәббәт хисләре аның атаклы «Шүрәле» поэмасында («3 нче дәфтәр», 1907) бөтен тулылыгы, бөтен матурлыгы белән сурәтләп, гәүдәләндереп, җанландырып күрсәтелә.

Әлеге уңайдан шунысына да игътибар итәргә кирәк: мәшһүр шагыйрь, киләчәкне алдан ук күргәндәй итеп, бу әсәренә карата әһәмиятле мондый искәрмә дә язган: «Ихтар: Мин бу “Шүрәле” хикәясен Пушкин вә Лермонтовларның шундый авыл җирендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуына истинадән яздым. Өмид юк түгел әле: бара торгач, үз арамыздан маһир рәссамнар чыгып, шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кыйлынган урманнарны – һәммәсен тәрсим кыйлып чыгарырлар. Авыл җирендәге хыялый хикәяләрнең һәммәсен язып чыгуда файдадан башка бернәрсә дә булмас зан идәрем. Г.Т.» («3 нче дәфтәр», 1907).

Күренә ки, чынбарлык шагыйрьнең тыйнак кына итеп фаразлавыннан түгел, ә бәлки йөз, меңнәрчә тапкыр көчлерәк, кыйммәтлерәк булып чыкты: музыкасын Фәрид Яруллин язган «Шүрәле» балеты, бу төр кыйммәтле сәнгатебезгә нигез салу белән бергә, дөньяның иң атаклы сәхнәләреннән төшмичә, туктаусыз куелып, татар халкының горурлыгына, аның визит карточкасына әверелде.

«Шүрәле» балеты аша туган җиребезнең, туган ягыбызның сихри, тылсымлы, матур табигате үзен дөнья сәхнәсенә менеп күрсәтте. Тагын кайсы халыкның табигате, Кырлай урманнары кебек, үзен дөнья халыклары алдында

шулай соклангыч дәрәҗәдә матур итеп күрсәтә алды икән?

Тукайга багышлап үткәрелгән төрле чараларда ул поэмада тасвирланган туган як табигатенең матурлыгы турында бик матур мисаллар китереп сөйләргә, туган як табигатенә карата мәхәббәт хисләрен тәрбияләргә гаять бай чыганак, хәзинә булып торуын күрсәтергә кирәк.

Г. Тукайның поэмадагы:

*«Ул авылның – һич онытмыйм, –*
*һәр ягы урман иде;*
*Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән*
*юрган иде.*
*Урманында кып-кызыл кура җиләк*
*тә, җир җиләк;*
*Күз ачып йомганчы, һичшиксез,*
*җыярсың бер чиләк.*
*Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр,*
*яшелдән чәчкәләр;*
*Һәр тарафка тәмле исләр*
*чәчкәли бу чәчкәләр» –*

дигән юллары безнең һәммәбезне дә туган ягыбызның шул гаҗәеп матур, сихри, тылсымлы табигать кочагына алып кереп китә дә инде.

Бөек шагыйрьләрнең иҗатлары шигърияткә генә түгел, тулаем әдәбият һәм сәнгатькә дә, халыкның милли аңы һәм туган тел үсешенә дә гаять зур йогынты ясыйлар. Тукай – Пушкин, Лермонтов, Һете, Һейне, Байрон, Петефи, Шевченко, Абай, Җәлил һ.б. кебек, халык үзе тудырган милли, чын мәгънәсендә татарның беренче халык шагыйре булуы белән бергә, Муса Җәлил язганча, «әдәби телебезгә нигез салучы» да. Шуның белән бергә, аның иҗаты милли кысалар белән генә чикләнеп калмаган, бәлки дөнья әдәбияты үрнәкләре белән дә тыгыз үрелгән. Аның Пушкин, Лермонтов, Майков, Крылов, Некрасов, Кольцов, Толстой, Байрон, Һете, Һейне, Шиллер, Шекспир һ.б. шигырьләрен, әсәрләрен тәрҗемә итүе, шулар үрнәгендә халык әкиятләренә нигезләнеп поэмалар иҗат итүе шул хакта сөйли. Ул татар әдәбиятын гына түгел, төрки халыклар әдәбиятларын да рус һәм дөнья әдәбияты, мәдәнияте белән тоташтыручы.

Рус поэзиясендә Пушкинның даһилыгы беренчеләрдән булып, төрле стильләрне кушып иҗат итүгә нигезләнсә, Тукайның бөеклеге дә халыкның җанлы сөйләм теле белән язма, ягъни китап телен һәм стильләрне бергә үреп иҗат итүдә гәүдәләнә. Бу җәһәттән караганда Тукай иҗаты идея-эстетик, социаль-иҗтимагый роле белән генә түгел, бәлки әдәби тел, матур әдәбият өлкәсендәге реформаторлыгы белән дә зур әһәмияткә ия.

Иҗаты киң катлау халыкка багышланган булганга, Тукайны авыл да, шәһәр дә, мөгаллим дә, шәкерт тә, сәүдәгәр дә, приказчик та, дин вә базар әһеле дә, зыялылар һәм кара эшче дә белгән, укыган, аңлаган, чөнки шигырьләрендә ул аларның барчасын тасвирлап биргән; әмма бердәй итеп түгел: гади халыкны үз итеп, байларны, өстен катлауны фаш итеп. Шул җәһәттән караганда Тукайның тел-стиле гаҗәеп дәрәҗәдә бай, сыгылмалы, иң мөһиме – халыкчан булуы белән сокландыра.

Г. Тукайның туган якка карата булган кайнар хисләре турында сөйләгәндә, безгә аның дөнья-

күләм танылган зур шагыйрь булуын онытмаска, шуның белән бергә аның туган ягыбызга, туган телебезгә, халкыбызга карата булган саф хисләренең бала чактан бирелүенә дә игътибар итәргә кирәк. Әнисе Мәмдүдә дә, аның әтисе Зиннәтулла да үзләре өчен генә булса да шигырь чыгарырга яратканнар. Авыл халкы да гел эшләп кенә тормаган, бәйрәм дә иткән: болыннарда, су буйларында уйнап, җырлап, биеп күңел дә ачкан. Тукай боларны күреп, белеп, аңлап, шул кешеләр арасында үскән.

Шигырьләренә дә халыкчанлык, туган телебезгә, туган як табигатенә соклану, мәхәббәт хисләре кече яшьтән үк күчкән. Ул шагыйрь буларак бик тиз өлгереп җитә: әсәрләрен дөнья поэзиясе үрнәкләре белән үреп, шул югарылыкта, шул биеклектә торып иҗат итүгә керешә.

**Сүзлекчә**

Җисмеми – гәүдәмне (үземне).
Җөмләтән – барчасы.
Зан идәрем – уйлыйм.
Истинадән – таянып.
Ихтар – искәртү.
Маһир рәссам – оста художник.
Мәмат – үлем.
Мәсакине – мескеннәр.
Сарикъ – карак.
Тәрке дөнья итмештер – дөнья куйган, үлгән.
Тәрсим кыйлу – рәсемен төшерү.
Фосулы әрбәга – елның дүрт фасылы.
Хәят – тормыш.
Хиссеми – тойгымны.

***Бадыйков Канәфи Габделбәр улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент*

УДК 821.512.145:821.512.164

*Г.Х. Кыясова*

# ТӨРЕКМӘН-ТАТАР РУХИ МӘДӘНИЯТЕ ҮСЕШЕНӘ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘДӘБИ МИРАСЫНЫҢ ТӘЭСИРЕ

В статье анализируется творчество Г. Тукая в контексте туркмено-татарских межлитературных связей. Стихи, переводы, публицистические статьи татарского классика пользовались огромной популярностью среди туркмен. Тукай стал основоположником новой национальной поэзии, ее неповторимого классического стиля.

Ключевые слова: татарская и туркменская литературы, духовное наследие, литературные взаимовсвязи, публицистика.

XIX гасыр һәм XX гасыр башы төрекмән һәм татар рухи мәдәнияте үсешендә аерым урын алып тора. Бу чорда әдәбиятның тәэсире сизелерлек арта һәм тагын да ераккарак, тирәнгәрәк үтеп керә. Ул вакытта Мамметвели Кемине, Гурбандурды Зелили, Сейитназар Сейди, Абдырахым Зынхары, Аннагылыч Матаджи, Талыбы, Молланепес, һәм төрекмән классик әдәбиятының башка күренекле вәкилләре яшәделәр һәм иҗат иттеләр. Шушы ук чорда татар әдәбияты аренасына да Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Муса Җәлил һ.б. шундый бөек шагыйрьләр, нәширләр, меценатлар чыкты. Күп гасырлар дәвамында татар поэтик әдәбияты көнчыгыш мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булды, ә XIX гасыр азагыннан башлап көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятының файдалы йогынтысы тәэсирендә иҗат итте. Бу чор төрки дөньяның рухи аренасына күп гаҗәеп талантларны, әдәби сүзнең танылган мастерларын чыгарды. Шуларның иң алдынгысы, татар халкының бөек улы Габдулла Тукай иде.

Төрекмән халкы бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗаты белән XX гасырда, сугыштан соңгы елларда ныклап кызыксына башлады. Төрекмән халкы шагыйрьнең шигъри, тәрҗемә һәм публицистик мирасы белән аның гомум билгеле булган «Хөррият хакында», «Государственная Думага» һ.б. әсәрләре аша беренче тапкыр танышты.

Г. Тукай төрекмән әдәбияты тарихына яңа милли шигърияттнең нигезен салучы һәм аның классик стилен тудыручы, татар халкының бөек улы буларак кереп калды. XX гасыр башы татар әдәбиятында «халык» һәм «шагыйрь» төшенчәләре Тукайдагы кебек бер-берсеннән аерылгысыз булган башка күренекле шәхесләр юк.

Татар әдәбиятында Тукайның халыкчанлыгы, бердәмлеге әдәбият мәйданында беренче тапкыр тулы мәгънәсендә ачыла. Аның барлык иҗаты сугышчан рух һәм демократик идеаллар-

ны яклау сугарылган. Шагыйрь «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырендә болай ди:

Әйдә халык-
ка хезмәткә,
хезмәт өчен-
дә йөзмәккә;
Бу юлда һәр-
төрле хурлык-
ка, зорлыклар-
га түзмәккә!

Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, М. Акъегет, Р. Фәхретдин һ.б. үзенә кадәр иҗат иткән язучылар һәм галимнәр иҗатында ачык чагылган милли мәгърифәтчелекнең яхшы традицияләрен дәвам итеп, Тукай татар җәмәгатьчелеген гасырлар дәвамында билгесезлектә яшәткән дини фанатизм һәм наданлыкка каршы кискен көрәш ача. Бу проблема аның иҗатының башлангыч чорындагы публицистикасындагы һәм шигырьләрендәге сатирада аеруча ачык чагыла. Ул шигърият һәм публицистика арасындагы тематик һәм традицион-лексик чикләрне сызып ташлагандай итә. Шуңа да Тукай иҗаты татар әдәбиятының шул чор эпохасына кергән ялкынлы көрәшче образы үрнәген күз алдына китерә.

Габдулла Тукай 1907 елда үзенең эшчәнлеген яңа иҗтимагый һәм иҗади идеалларга багышлау өчен милли мәдәниятнең һәм тарихның бишегенә – Казанга килә. Әлеге вакыйга уңаеннан үзенең өметләрен ачык белдереп, «Пар ат» шигырендә ул болай ди:

Мондадыр безнең бабайлар
төрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең
хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм
монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем,
җәннәтем һәм монда хур...

Тукай иҗаты үз халкына хиыссыз хезмәт итүгә нигезләнгән. Шагыйрь халкының матди һәм рухи тормышына тирән үтеп кереп, тиз арада мәгърифәтчелек романтикасына күтәрелә. Аның иҗаты, башлыча, интеллигенциянең халыкка булган мөнәсәбәтенә багышланган. Нәкъ менә шушы мәсьәлә М. Горькийның «Разрушение личности» (1909) мәкаләсендә бөтен кискенлеге белән күтәрелә: *«Народ – не только сила, создающая все материальные ценности, он – единственный и неиссякаемый источник ценностей духовных, первый по времени, красоте и гениальности, творчества философ и поэт, создавший все великие поэмы, все трагедии и величайшую из них – историю всемирной культуры».*

Татар шагыйре бөтен халыкны да сукырларча идеаллаштырудан ерак тора. Үз халкын яратса да, алар арасында күп гасырлардан бирле килгән наданлык, томаналык, рухи изелгәнлек, язмышы белән килешеп яшәү кебек күптәнге чирләрне гафу итәргә теләми. Үзенең «Дин вә гавәм», «Йолдыз»дан да курка», «Мич башы кыйссасы» һ.б. әсәрләрендә үз халкының көчле һәм көчсез якларын күрә һәм бәяли алган. Тукай үзе өчен дә, замандашлары өчен дә үрнәк халык герое итеп аңлы, әхлаклы кешеләрне күрәсе килә.

Г. Тукай нәфис сүзнең иҗтимагый мәгънәсен бик яшьли аң-

лый – аның иҗатында сүзнең көче матурлык һәм изгелек өчен көрәштә чагылыш таба. Ул кешенең, халыкның ирегенә аркылы төшүче һәртөрле көчләрне алдан ук төгәл сизеп алган һәм киң җәмәгатьчелек хөкеменә чыгарган. Әдәби сатираның әһәмиятен шагыйрь югары бәяләгән. Тукайның барлык шигърияте һәм публицистикасы тирән сатира белән сугарылган. Узган буынның традицияләргә нигезләнгән бай тәҗрибәсенә таянып, аның шигърияте һәм публицистикасы бер-берсе белән үзара тыгыз бәйләнештә.

Тукай иҗатының халыкчанлыгы турында сөйләгәндә, шагыйрьгә бик тирәннән аңлаган патриотизм хисе хас булуын да ассызыкларга кирәк. Шагыйрь өчен Ватан төшенчәсе – халык тарихы, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге, тулаем халык язмышының гәүдәләнеше. Тукай аңында халык һәм туган җир тарихы аерылгысыз. Туган илне ярату, халыкны һәм азатлыкны ярату кебек үк, тирән шигъри ихтыяҗга әверелгән, туендыручы иҗат чыганагына әйләнгән.

Шагыйрь үзенең соңгы көннәренә кадәр татар халкы Россиядә яшәүче башка милләт вәкилләре белән татулыкта, бердәмлектә яшәгәндә генә бәхеткә һәм азатлыкка ирешә ала дигән ныклы фикердә була. Ул ышаныч белән болай дигән: «Милләтләр дә бертөрле гомуми эш чыгып, тәрәккъый җилләре иссә, үзләренең таралышган урыннарыннан чыгып, бер җиргә җыелалар...» («Юбилей мөнәсәбәте илә», 1913). «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» шигыре патша юбилеена гына багышланмаган, ә бер җирдә яшәүче рус һәм татар халкының күпгасырлык дуслыгы, күңел түрендәге уртак максатка бәргәләшеп тарихи хәрәкәте турында:

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Нәкъ менә шул халыкларның тарихи бергәлеге татар шагыйрен иҗатка рухландырган да инде. Бу идея XX гасыр шагыйрьләренә генә хас булмый. Әлеге проблеманы бу шигъри юллар язылганча күп еллар алдан ук бөек төркмән классигы Махтумкули Фраги күтәреп чыга, халыкларны бердәмлеккә һәм оешканлыкка чакырып, үзенең «Держава туркмен» шигырен иҗат итә.

Туркмены! Если бы мы дружно
жить могли,
Мы осушили бы Нил, мы б на
Кульзум пришли!
Теке, йомуд, гоклен, языр и алили,
Все пять – должны мы стать
единою семьею.

Төрек дөньясы тәрҗемә әдәбияты эшчәнлеге тарихына кагылышлы күп кенә мисаллар китерергә була. Халыкларның иҗади мирасы үзләренең рухи мәдәнияте, уртаклыгы белән бер-берсенә шулкадәр якын, шуңа да ул гомумтөрки әдәбиятына гаять зур йогынты ясый. Тәрҗемә теориясенең роле һәм мәгънәсе турында немец галиме-романтик Август Шлегель йөз еллар элек болай дигән: *«Художественный перевод – смертельный поединок, в результате которого кто-то один – тот, кто переводит, или*

*тот, кого переводят, терпит сокрушительные поражения» (Перевод и совершенство речи. Т. 1. / сост. Б. Камолиддинов, М. Нагзибекова. Душанбе: Тадж. Нац. Ун-т, 2004; Т. 20. Душанбе, 2005 / (на тадж. яз.)).* Әдәбият өлкәсендә ирешкән уңышларны игътибарга алып, төрекмән тәрҗемәче-мәгърифәтчеләре күрше халыкларның бай әдәби мирасы тарихын өйрәнеп, әдәби мөнәсәбәтләрне һәм традицияләрне үстерү өлкәсендә иҗади батырлык эшләделәр. Тәрҗемә эшчәнлеге нәтиҗәсендә төрекмән халкы төрки халыкларның күренекле язучылары һәм шагыйрьләре иҗат иткән әдәби, публицистик әсәрләр белән танышты, ә бу исә күрше халыкларның тормышын өйрәнүдә үзенә күрә чыганак ролен үтәде. Моның гүзәл үрнәге – Габдулла Тукай әсәрләрен төрекмән теленә тәрҗемә итү. Г. Тукай әсәрләре беренче тапкыр зур күләмдә 1961 елда «Abdylla Tokaý. Goşgular hem hekaýalar» исеме белән дөнья күрә. Бу басмада шагыйрьнең 109 шигыре һәм 26 хикәясе урын алган. Бөек татар шагыйрьнең иҗади мирасы белән төрекмән укучыларын таныштыруда Социалистик хезмәт герое, атказанган сәнгать эшлеклесе, Төрекмән халык язучысы Берди Кербабаев, Алты Чарпяров, Анна Мухатова, Берди Солтанниязов, Дайхан Акмамедов һ.б. шәхесләренең роле зур булды. Шулай итеп, төрекмән укучылары, татар халкы белән тыгыз дәрәҗәдә халык фольклорына, традицияләренә һәм мифологиясенә нигезләнгән Тукай поэзиясе дөньясына үтеп керә алдылар. Тукай иҗаты халык поэтик иҗатын, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне чагылдырганы өчен төрекмән һәм төрки халыкларда зур кызыксыну уятты. Зур әдәби казанышларга ия булган Тукай басмасы, тәрҗемәчеләрне, төп нөсхәдәге иҗади үзенчәлекләрне бөтен төгәллеге белән бирә алганнары өчен, чын мастерлар итеп танытты.

Габдулла Тукайның мәңге саекмас иҗаты төрки әдәбият үсеше өчен яңа офыклар, яңа перспективалар ача. Тукай үз илендә алдынгы идеяләре, карашлары өчен генә бөек халык шагыйре, булып танылмаган, ә бәлки татарга гына түгел, ә бөтен төрки телле әдәбият өчен тарихи борылыш ясавы белән дә бер адым алда барган. Милләт, халык, халыкчанлык сүзләренең нинди зур мәгънәгә ия булуын аңлап, Тукай болай ди: «Милләт образауный[1] кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең, шәхси мәнафигыннан[2] вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә гаҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ. Милләт аталарга, аналарга, мөгалимнәргә, мөгалиммәләргә, мөрәббиләргә вә мөрәббияләргә[3], чын мөхәррирлек[4] табигатьләренә вә сәляхиятләренә[5] мохтаҗ...».

Халыкны бердәмлеккә, оешмалыкка, мәгърифәткә чакырып, ул халык арасыннан шушы бөек идеалга җан атып йөрүчеләрне эзләде һәм бу шигырьне тормыш һәм иҗатында маяк итте.

Тукай XX гасырның беренче ун елында бөтен төрки халыклар-

ның мәдәниятен һәм әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертте. Ул төрки халыклар тормышында әдәбиятның әһәмиятен югары күтәрде, иҗатында аларның уйларын һәм өметләрен чагылдырды. Тукай мирасы төрки әдәбиятның алтын фондына кергән. Шигыйрь татар халкы да, шулай ук бөтен төрек дөньясын дус, тату, һәртөрле кыерсытулардан азат итеп күрү турында хыялланды. Бүген шагыйрьнең шушы бөек хыялы тормышка ашты һәм нәкъ менә безнең көннәрдә Тукай бөтен төрки халыклар күз алдында чын шигыйрь-патриот һәм даһи буларак күз алдына килә.

Тукайның әдәби мирасыннан чыгып без бүген горурланып шуны әйтә алабыз, татар классигы Габдулла Тукайның иҗаты мөкәммәл илһам чыганагы булып тора.

Язманы Г. Тукайның «Шагыйрь» дигән шигыре белән тәмамлыйсым килә. Аны төрекмән теленә институтыбызның фәнни хезмәткәре Мурадов Аннаева тәрҗемә итте:

Wagt meniň juwanlygym äkitdi
Bilim epip, sütünimi süýndedi.
Ýöne seretmezden gojalygyma,
Göwnüm hiç haçanam lagşamaz meniň.

Kükregim şygryň odundan doly,
Garrylyk – bu derdi çekmäge taýyn.
Göwnümde elmydam baharyň nagşy,
Şahyryň köňlünde gar ýok, aýaz ýok.

Garrylyk meň üçin adaty zat däl,
Dert, alada etmän ownuk zat üçin.
Ýyly ýerde dek oturman hergizde,
Şygyrlarym maňa ýylylyk çoýar.

Ölümiň ýüzüne gülüp bakaryn,
Ezraýyly görsem aýdaryn aýdym.
Men baky dünýäde, sizem panyda,
Toprak bilen gömülsede jesedim.

[1] Образауный (образованный) – белемле
[2] Шәхси мәнафигъ – үз интереслары
[3] Мөррәбби, мөррәбия – тәрбияче
[4] Мөхәррирлек – язучылык
[5] Сәляхият – сәләтлелек, талант, булдыклылык.

***Кыясова Гызылгөл Хакбирде кызы,***
*Мәхтүмколый исемендәге Төрекмәнстан Фәннәр академиясенең Тел һәм әдәбият институты директоры.*

УДК 821.512.145:821.512.161

***Хөсәен Барган***

# ТАТАР ШАГЫЙРЕ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ТӨРЕК ӘДӘБИЯТЫ

В статье освещается творчество Г. Тукая в контексте литературных связей татарского и турецкого народов. Анализируется влияние произведений Г. Тукая на узбекскую и турецкую литературы. В то же время в поэзии татарского классика находят место традиционная система образов, нравственно-этические идеалы, рожденные в произведениях турецких поэтов.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, межлитературные связи, турецкая литература, публицистика.

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай (1886–1913) – 1905 елда игълан ителгән матбугат иреге нәтиҗәсендә формалашкан яңа татар әдәбиятының тавышын «Печән базары»ннан башлап, Урта Азия һәм Истанбулга кадәр ишеттерә алган беренче татар шагыйре. Урта Азиянең төрле җирләренә барып ирешкән татар матбугаты һәм татар мөгаллимнәре ярдәмендә Габдулла Тукай татар халкының «милли шагыйре» буларак танылу ала. Фуат Көпрүлүнең Габдулла Тукай вафатына нисбәтле язылган киң һәм этрафлы мәкалә-некрологы «Төрек йорты» журналында басылып чыккач, шагыйрьнең иҗаты Истанбулның киң җәмәгатьчелегенә дә барып ирешә. Җәнап Шиһабетдин сүзләренә караганда, ул вакытларда көнбатыш әдәбиятына йөз тоткан төрек әдипләренең татар шагыйрьләрен белмәве мөмкин булмаган [Kaya Nuri, 1339, s. 2].

Габдулла Тукай Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында 1911 елның җәй аенда бер-ике атнага булса да, Истанбулга бару теләге турында белдерә [Гыйләҗев Т.Ш. Рецензияләр..., б. 219]. Бу чорда татар зыялылары һәм әдипләре арасында Истанбулга юлы төшмәгән кеше булмагандыр. Бары тик Габдулла Тукайның гына теләге тормышка ашмый кала.

Истанбулга бара алмаса да, аны гел күзәтеп яшәгән Габдулла Тукай шәһәрнең сәяси атмосферасын шигырьләрендә чагылдырган. Шуның белән бергә, Габдулла Тукай Казанда яшәгән вакытта дусларының китапханәләрендә Яңарыш чоры төрек әдәбияты әсәрләре белән һәрдаим танышып барган.

Габдрахман Сәгъди Габдулла Тукай Төркестан һәм Госманлы суфичылык шигъриятен кабатлауда гаепләнгән һәм «ялганчы классиклар» дип бәяләнгән XIX гасыр татар шагыйрьләре Шәмсетдин Суфи, Һибәтулла Ишан һәм Әбелмәних Каргалыйның шигырьләреннән аермалы әсәрләр тудырды дип язса да [Гыйләҗев Т.Ш. Габдрахман..., б. 376], аның әсәрләрен гасырлар арасында «органик бөтенлек» [Eliot, s. 3] барлыкка ки-

тергән традицияләрдән аерып карау мөмкин түгел. Җамалетдин Вәлиди фикеренчә, Габдулла Тукай кабатланмас шигырьләр тудырган [Галәү, 1913].

Традицияләр йогынтысының кимүе нәтиҗәсендә, яңа чор әдәбияты шагыйрьләре баштарак һәвәскәрлек белән мавыга башлыйлар. Үз вакытында Җамалетдин Вәлиди Габдулла Тукайның беренче әсәрләреннән түбәндәге шигырен мисалга китереп, аның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсенә игътибар иткән:

*«Ahmed Safa Efendi*
*Fazıl edipdir kendi*
*Kalemi muîn-i millet*
*Miras hakdır bendi*
*Familyası Baytirek*
*Misli dünyada seyrek*
*Mundi insanlar vücudu*
*Bizniñ milletge girek»*
[Velidi, 1918, s. VIX]

Габдулла Тукайның 1913 елда вафатына нисбәтле аның тормышы һәм шигъриятенә багышлап язылган мәкаләсеннән Мәхмәт Фуат Көпрүлү бу турыда түбәндәге бәяләмәсен бирә: «Төньяк төркиләре әдәбиятында әле дә назым түбән дәрәҗәдәдер. Мин, мәсәлән, Тукаевны укыганда, гармония метрикасы, тел метрикасы нигезендә үземне Ашикъ Пашаның «Мәгърифәтнамәсен» укыгандай хис иттем. Шуңа мөнәсәбәттә, Идел буенда яшәп иҗат итүче дустыма кечкенә генә бер киңәш бирмәкче булам: бездә гаруз метрикасының алты йөз еллап тарихы булганга, аның мөмкинлекләрен тулысынча чагылдыра алмадык. Төньяк төркиләре телебезгә ят булган бу метриканы кулланганчы, милли җырларыбызның табигый метрикасын, ягъни иҗек рифмасын кулланган булсалар, әлбәттә, отышлырак булыр иде. Бу үзенчәлек сәнгати гармонияне булдыруда гаять дәрәҗәдә мөһимдер. Гаруздагы «фаиләтүн» метрикасы унбер яки уналты иҗекле метрикага караганда күпкә аһәңсез, хәтта ачу китерә торган» [Köprülüzade, 1999, s. 286].

Габдрахман Сәгъдинең Габдулла Тукай шигырьләрен элеккеләреннән аерып каравы, Галимҗан Ибраһимовның һәм Сәгыйть Рәмиевнең аны яңа «Мөхәммәдия»ләр иҗат итүче дип түбәнсетүләре, шагыйрь әсәрләренең үткәннән илһам алып язылганлыгын һәм үткәннең бүгенге белән кисешкәнлеген күрсәткән ике фикерне чагылдыра.

XIX гасыр татар шагыйрьләренең Госманлы җирлегенә караган «Мөхәммәдия» һәм башка шуның ише халык әсәрләренә иярүен Россия хакимлеге астында булган өлкәдә тиешле мәдәни шартларның формалашып җитмәве белән аңлатырга мөмкин. Үз әдәби мирас байлыгының аз булуы аларны госманлы әдәбиятына йөз тотарга мәҗбүр иткән. Тәүфикъ Әйди, Галиәсгар Камал сүзләре белән әйтсәк, «төрек әдәбиятының «шифалы җилләре» [Әйди, 2000, б. 343] яңарыш чоры татар әдәбиятында күп кенә язучыларның иҗат офыкларын киңәйтергә ярдәм иткән.

Аерым алганда, Языҗыоглу Мәхмәт Чәләбинең XV гасырга караган «Мөхәммәдия» әсәре Габдулла Тукай иҗатында строфалар арасында бәйләнеш тудыручы «затлы текст» буларак кул-

ланыла. Форма һәм тел ягыннан «Мөхәммәдия»гә ияреп язылган әсәрләре [Kubilay Aktulum, 2000, s. 133], бер яктан, аның отышлы ягы, икенче яктан исә – уңышсызлыгыдыр.

Кечкенәдән үк ятим калган Габдулла Тукай 1895 елда Кырлайдан Уральскига (Җаек) апасы Газизә Зәбирова янына китерелә. Габдулла Тукай җизнәсе Галиәсгар Госмановның ярдәме белән Уральскидагы Мотыйгулла мәдрәсәсендә укый башлый [Татар әдәбияты тарихы, б. 10].

Мотыйгулла Төхфәтуллин (1840–1920) Кышкар мәдрәсәсендә Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф белән бергә укый [Галимуллин, б. 35], соңрак укуын Мисырда дәвам итә. Ул галим яңалык тарафдары булган. 1881 елдан башлап, Уральскидагы өченче мәчеттә имам вазыйфаларын башкарган [Төхфәтуллин, 1906] Мотыйгулла соңыннан улы Камил Мотыйгуллинны (1883–1941) да Мисырдагы әл-Әзһәрдә укыта.

1900 елда, Галиәсгар Госмановның вафатыннан соң, Габдулла Тукай яшәргә әтисенең дусты Мотыйгулла Төхфәтуллин мәдрәсәсенә күченә. Мәдрәсәгә беренче тапкыр килгәндә, Г. Тукайга тугыз яшь була. Ул төрки телдә язылган китаплар, аеруча «Мөхәммәдия» белән кызыксына [Тукай турында замандашлары, б. 46]. 1902 елдан башлап, ул Урыс Йосыф кушаматлы мәдрәсә дусты белән рус мәктәбендә рус телен өйрәнә башлый. Шул ук мәдрәсәдә укыган Шәриф Каюмовның әйтүенә караганда, ул вакытларда мәдрәсәдә «Мөхәммәдия»не уку модада булган. Габдулла Тукай һәм аның дуслары дәрестән соң, Чаган елгасы ярына йөрергә чыккач, татар халык җырларыннан «Кара урман», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» белән бергә, «Мөхәммәдия»не дә җырлый торган булганнар [Тукай турында замандашлары, б. 42–43].

Габдулла Тукай сәхраларда йөргәндә һәрвакыт «Мөхәммәдия»не көйләп, мәдрәсәдә бердәнбер музыка коралы саналган кубызда уйный торган булган.

1902–1903 елларда мәдрәсәгә Төркиядән Габделвәли Әмрулла исемле егет килә. «Төрек Вәли» кушаматлы бу егет мәдрәсәдә бер ел тирәсе яши. Шигырьләр дә язган Габделвәли белән Габдулла Тукай мәдрәсәдә якын дусларга әвереләләр. Чөнки Габдулла Тукай төрекчә белгән һәм күп кенә нәрсәләрдә алар уртак фикердә торганнар. Җай чыкканда Габдулла Габделвәлигә кушылып төрек җырлары да җырлаган [Тукай турында замандашлары, б. 46]. Габдулла Тукайның төрек телен яхшы белүенә, «Мөхәммәдия»не еш укуы белән бергә, Кырымда чыккан «Тәрҗеман», Мисырда чыгып килгән «Төрек» һәм Тифлиста чыккан «Шәркый Рус» газеталары белән танышып баруы да ярдәм иткәндер. Моннан тыш, җәй көннәрендә Габдулла Тукай, башка шәкертләр кебек казакъ далаларына мулла булып чыкмыйча, Истанбулда укып, илга кайткан яшьләр белән аралашкан. Төрек егете Габделвәли дә шуларның берсе була. Тукай белән якыннан аралашкан бу егетне Габдулла Кариев, шагыйрьнең үзе сөйләгәннәреннән чы-

гып, түбәндәгечә тасвирлый: «1902–1903 нче елларда Габдулла Тукаевлар мәдрәсәсенә Истамбулда укыган бер шәкерт килә. Ул шәкерт җәй көне килү сәбәпле, алар җәй буена Габдулла әфәнде белән бергә торалар. Габдулла әфәнденең сөйләвенә караганда, ул шәкерт үзе шагыйрь дә булган, Габдулла әфәнде белән алар бер-берсенә табган (табигатьләре белән) туры килеп, бер-берсен бик яратышып торганнар. Габдулла әфәнденең нәкыленә (сөйләвенә) күрә, шул шәкерт белән алар җәй буена ачлы-туклы торганнар; ул шәкертнең түземлелеге, әхлаклылыгы, гүзәл тәрбиясе Габдулла әфәндегә бик каты тәэсир иткән. Шуның өчен мәдрәсә бабыннан сүз чыкса, Габдулла әфәнде мәдрәсәдә иң матур хатирәгә шул шәкертне сөйли иде. Шул шәкерт белән алар җәй буе бергә җырлап, бергә йөреп, ач булсалар да, вакытларын рәхәт, хозур үткәргәннәр. Габдулла әфәнденең иң матур җәе шул төрек шәкерте белән үткән. Ул шәкертнең шигырьләреннән бәгъзыларын Габдулла әфәнде 1907 нче елларда миңа Уральскида вакытта укыган да иде, ләкин, тәәссеф ки, бер сүзе дә хәтеремдә калмаган.

Ул шәкерт мәдрәсәи Мотыйгыядә бер кышны да үткәргән, ләкин аны башка шәкертләр бер дә яратмаганнар. Ул да Габдулла әфәнде кебек илтифат итми торганрак шәкерт булган. Габдулла әфәнде бу төрек шәкертенең тәрбиясез карт шәкертләрдән шактый җәбер күргәнлеген сөйли иде. Ул шәкерт белән торган заманнарда Габдулла әфәнде төрек романнарын бик яратып укый иде» [Кариев, б. 102–103].

Габдулла Тукай көчле хәтергә ия булган. Җай чыкканда «Мөхәммәдия»дән өзекләр укып, аннан кайбер дини хөкемнәргә үрнәкләр китергән. Казанга киткәч, ул Истанбулда чыккан кайбер антологияләрне кулына төшереп, Яңарыш чоры төрек шагыйрьләренең шигырьләре белән таныша һәм кайберләрен яттан өйрәнә. Уральскида татар мохите ул вакытларда Казан, Оренбург, Уфа һәм Троицкидагы кебек көчле түгел, хәтта татарларның үзләренең типографиясе дә булмый. 1905 елда Камил Мотыйгый типография сатып алып, «Фикер», «Әлгасрелҗәдид» газеталарын һәм «Уклар» журналын чыгара башлагач, Уральскида «Прогресс» исемле китап кибете ача. Ләкин 1907 елда газета-журналлар ябылу сәбәпле, бу кибет тә ябыла [Мотыйги, 1914, б. 12–13]. 1907 елда Казанга килеп, Казан яшьләренең әдәбият кичәләрендә ясаган чыгышларын тыңлаганнан соң, Габдулла Тукай Уральскида яшәгән вакытта үзенең дөньядан артта калганлыгын, күп нәрсәдән хәбәрдар булмаганлыгын аңлап, алга таба Казанда калырга кирәклеге фикеренә килә [Тукай турында замандашлары, б. 99–100]. Чөнки матди кыенлыклар Габдулла Тукайга гомер буена үз шәхси китапханәсен булдырырга мөмкинлек бирмәгән. Ш. Шәрәф сөйләве буенча, моның өчен чын күңелдән кыенсынган Габдулла Тукай, Казанга килүенең беренче көннәреннән башлап, аннан төрек әдипләренең байтак китапларын алып укый [Тукай турында замандашлары, б. 105–106].

Габдулла Тукай шигырьләрен яттан укыган төрек әдипләре арасында Зыя Паша, Габделхак Хәмид, Габдулла Җәүдәт, Режаизадә Мәхмүт Әкрәм, Тәүфикъ Фикрәт һәм Нәмык Кәмалны атап үтәргә мөмкин. «Әлислах» газетасында Габдулла Тукай белән бергә эшләгән Вафа Бәхтияров бу турыда түбәндәгеләрне сөйли: «Истамбул-төрек классик шагыйрьләреннән Зыя Паша, Габделхак Хәмид, Г. Җәүдәт, Т. Фикрәт, шулай ук Нәмык Кәмалларны укый һәм алар белән якыннан таныша иде. Боларның шигырьләрен бик яратып сөйли иде. Күбесенең шигырьләрен яттан белә иде. Нәмык Кәмалның «Силистра» трагедиясен татарчалаштыру эшен дә ул алып барды» [Тукай турында замандашлары, б. 89].

Аерым алганда, Габдулла Тукай Габдулла Җәүдәтнең:

*«Yolunda bin hakikat verdiğim bir*
*şanlı rüyadan*
*Kalan pişani-i ömrümde bir na-bud*
*kevkebtir»*
[Kaleci, s. 292]

дип башлаган «Хижрани мөкәвкәб» исемле робагыен, Нәмык Кәмалның «Ватан мәнзумәсе»н, һәм Рәҗаизадә Мәхмүт Әкрәмнең Альфред де Мюсседән тәрҗемә иткән һәм:

*«Vakta ki gelip bahar… Yekser*
*Eşyada ıyan olur tagayyür*
*Vakta ki hezâr-ı aşk-perver*
*Yapraklar ile edip tesettür*
*Bilmem kime karşı hasretinden*
*Başlar nevehata bi-teahhür*
*Kıl gökyüzünün letafetinden*
*Safiyet-i aşkımı tahattur,*
*Yâd et beni bir dakika yâd et.»*

[Yeni Türk Edebiyatı Antolojisi, s. 46]

дип башланган «Яд ит» исемле шигырьләрен яттан укыган [Тукай турында замандашлары, б. 126–127].

Габдулла Тукай 1912 елда «Ялт-йолт» журналында бастырган «Хаксызлыктан котылдык» исемле мәкаләсендә Нәмык Кәмалның «Хөррият» касыйдәсенең ахыргы

*«Kilâb-ı zulme kaldı gezdiğin nâzende*
*sahralar*
*Uyan ey yâreli şîr-i jeyan bu hâb-ı*
*gafletten»*

бәетенең беренче ике юлын телгә ала [Тукай, 2015, б. 236–239].

Моннан тыш Габдулла Тукай «Күңел йолдызы» исемле шигырендә Габдулла Җәүдәтнең югарыда телгә алынган робагыеның соңгы ике юлын да китерә:

*«Teneffürler, terahhumlar,*
*tahatturlarla dünyadan*
*Güzârım zahmdar-ı vasl bir hicr-i*
*mükevkebdir.»*
[Вәлиди, 1918, б. 62]

Габдулла Тукайның Казандагы дусларыннан шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй инглиз шагыйре Байронның Габдулла Җәүдәт тәрҗемәсендәге «Шилон мәхбүс»ен 1910 елда «Мәхбүс» исеме белән бастыра [Battal, 1913, s. 42]. Әсәрне тәрҗемә итәргә ярдәм иткән Габдулла Тукай аның беренче басмасына кереш тә яза [Sünçeley, 2005, s. 255].

Габдулла Тукай төрек әдәбияты белән, нигездә, Мәхмәт Җәлал һәм Режаизадә Мәхмүт Әкрәмнең «Талими әдәбият» исемле хезмәтеннән әдәбият турында бай мәгълүмат китерелгән, үз эченә күп кенә төрек шагыйрьләренең, шул исәптән Мөгаллим Наҗи һәм

Рәҗаизадә Мәхмүт Әкрәмнең әсәрләрен һәм Әхмәт Мидхәт әфәнде белән Халит Зыя Ушаклыгилнең нәсерләрен алган «Госманлы әдәбияты үрнәкләре» антологиясе [Celal, 1312, s. 615]аша таныша. Моннан тыш, Габдулла Тукай даими рәвештә, 1907 елдан башлап, «Кыйсми әдәби» [Kısm-ı Edebi, 1907] исеме астында төрек шагыйрьләре Нәмык Кәмал, Тәүфикъ Фикрәт, Рәҗаизадә Мәхмүт Әкрәм, Зыя Паша, Мөгаллим Наҗи һәм Җәнап Шиһабетдиннең шигырьләрен бастырып килгән «Төрек» газетасын да укып бара.

Габдулла Тукай Габделхак Хәмитнең «Нәстәрән» һәм «Духтәри һинду» пьесалары белән дә таныш булган. Аның төрек әдәбиятын укуы турында Ш. Шәрәф түбәндәгеләрне язып калдырган: «Миннән төрек әдипләренең байтак китапларын алып укыды, «Госманлы әдәбияты нәмүнәләре» исемле китапны укыгач, «Бу китапта миңа ярарлык нәрсәләр дә бар икән», – дигән иде. Төрек әдипләреннән Габделхак Хәмиднең берничә әсәрләрен алып укыгач, аның фикерләренең ачыклыгын, шигырьләренең дә садә вә шигърияте куәтле булганын яратып сөйләде. Фәкать аның «Нәстәрән» (Кыр гөле) исемле әсәрен укыгач кына: «Шундаен куәтле мәхәббәт берлә куәтле дошманлыкның бер күңелгә җыелуына минем күңелем җитми, Габделхак Хәмиднең тасвирларын башыма сыйдыра алмыйм», – дип сөйләгән иде [Тукай турында замандашлары, б. 106].

Габделхак Хәмиднең «Духтәри һинду» пьесасы белән бәйле мәгълүматны Габдулла Тукайга Казан Болгар номерларының кырыгынчы бүлмәсендә торган вакытта аның белән күрешкән Вафа Бәхтияров бирә [Тукай турында замандашлары, б. 87].

Казанга килгәч, Габдулла Тукай укыган газета һәм журналларның саны арта. Уральскида яшәгән вакытта танышып барган «Тәрҗеман», «Төрек» һәм «Мулла Насретдин» газеталарын ул Казанда да ташламый. Шуның белән бергә, шагыйрь Истанбулда Йосыф Акчура тарафыннан чыгарылган «Төрек Йорты» журналын, 1908 елдан башлап атнага ике тапкыр чыгып килгән һәм даими рәвештә төрек әдәбиятының танылган вәкилләреннән Әхмәт Рәсимнең мәкаләләре бастырылган «Каракүз» юмористик газетасын да укый башлый.

Габдулла Тукай аеруча «Мулла Насретдин» һәм «Каракүз» газеталарының бер номерын да калдырмыйча күзәтеп бара [Тукай турында замандашлары, б. 896]. Шагыйрьнең Уральскида вакытта кулына «Мулла Насретдин» газетасын тотып төшкән фотографиясе дә бар. Аның сатирик эчтәлектәге шигырьләре, һичшиксез әлеге ике газетаның зур тәэсире астында язылган булырга тиеш.

Габдулла Тукай әлеге газеталар ярдәмендә дөньядагы иҗтимагый һәм сәяси вакыйгалар белән танышып бара. Каһирәдә «Иттихад һәм Тәрәккый» партиясе ярдәмендә чыккан «Төрек» һәм Европада чыккан госманлы оппозицион газеталарын Россиягә керту Истанбулда чыккан газеталарны кертүгә караганда

җиңелрәк булган. Татар зыялылары арасында Габделхәмиткә карата тискәре мөнәсәбәтнең барлыкка килүендә бу вакытлы матбугатның да йогынтысы булгандыр. Габдулла Тукайның «Габделхәмит» (1909) һәм «Борадәранә нәсыйхәт» (1906) шигырьләрен нәкь менә әлеге сәбәп белән аңлатырга мөмкин. «Габделхәмит» шигыре – Габделхәмит II нең тәхеттән төшерелү уңаеннан әлеге шәхескә тискәре мөнәсәбәттә язылган бер әсәр. Газеталардан үз чорының актуаль һәм тарихи вакыйгалары белән танышып барган Габдулла Тукай аларга багышлап шигырьләр дә яза. Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасының 63 нче номерында көрәштән баш тарткан «Яшь төрекләр» хәрәкәте вәкилләренең шигырьләре басылу уңаеннан Габдулла Тукай «63 нче номерлы «Вакыт» җәридәсендә мөндәриҗ яшь төрекләрнең кайбер әшгаренә каршы» дигән аңлатма биреп, «Борадәранә нәсыйхәт» шигырен яза. Аның ахыры түбәндәгечә тәмамлана:

*«Сез рәисе залимани «Йолдыз»а хәбсидеңез, –*
*Бөйлә ишләр җөмләси дә һәп сезиң тәдбиреңез.*
*Юлыңызда сез һәмишә сабит улмыш улсаңыз,*
*Бәнчә, нә мөмкин улырды һич сезең тәкъдиреңез.*
*Шимди сез ләхдә кадәр мәддахе залим улдыңыз,*
*Залимә коллык фәкать тәкърireңез, тәхриреңез»*

[Габдулла Тукаев шигырьләре, 1909, б. 22]

Биредә дә куштырнаклар эчендә телгә алынган «Йолдыз» исеме астында Габделхәмит күз уңында тотыла. Ләкин шигырьдә «рәиси җаһилани», «мәддаһи җаһил» һәм «җаһилгә коллык» гыйбарәләрендә кулланылган «җаһил» сүзе совет текстологлары тарафыннан «залим» формасында бирелгән. Шул ук шигырьдә башка сүзләрнең укылышында да төгәлсезлекләр күзәтелә. Гарәп хәрефләре белән язылган беренче текстларга мөрәҗәгать итмәү сәбәпле, Төркиядә Габдулла Тукай белән бәйле башка хезмәтләр дә әлеге хаталы һәм үзгәрешләргә дучар булган текстлар нигезендә башкарылган [Özkan, 1994, s. 198–199].

Габдулла Тукай «Габделхәмит» исемле кыска шигырендә гарәп телендә бер эпиграф куллана. Шигырьнең төп эчтәлеген түбәндәге җөмлә ачып бирә: «Кем дә кем үз халкына кое казыса, казыган коесына үзе төшәр». Шагыйрь фикеренчә, Габделхәмит II утыз ел буена төрекләрнең хөр фикерләрен үтереп килгән, азатлык тамырларын корыткан, ватанны яктырткан шәмнәрне сүндергән, мөселманнарны башка милләтләр алдында көлкегә калдырган һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, үзе дә хурлыкка төшкән [Abdullah Tukay Mecmua-yı Âsârı, s. 153]. Габдулла Тукай төрек милләтенең киләчәгенә турыдан-туры йогынты ясаган сугыш темасына карата да ачык бер шәкелдә үзенең фикерен белдергән [Вәлиди, 1913]. Биредә аның Балкан сугышы һәм татар халкының әлеге сугышка мөнәсәбәте белән бәйле язылган шигырьләрен телгә алу урынлы булыр.

Сугыш темасын Габдулла Тукайның 1911 елгы Траблусгарб һәм 1913 елгы Балкан сугышлары белән бәйле рәвештә язылган шигырьләрендә күрергә мөмкин. Балкан сугышлары турында Тукай гына язмаган әлбәттә. Моңа мисал итеп, Зыя Ярмәкинең (1887–1965) «Балкан золымы» һәм «Әдирнәдә Шүкрү Пашага» исемле шигырьләре [Гайнетдин, 1997, б. 8], Нәҗип Думавиның (1883–1933) «Балкан мәзалимы» [Думави, 1914, б. 16], Сәгыйть Сүнчәләйнең (1889–1937) «Төрек йортында» басылган «Төреккә» [Sünçeley, 1999, s. 287; Сүнчәләй, 2005, б. 110], Исхак Госманиның «Балканда» [Османи, 1913] дип исемләнгән шигырьләрен китерергә мөмкин. Хәтта төрек әдәбиятында да Балкан сугышлары белән бәйле рәвештә бу күләмдә шигырь язылмагандыр. Халык җырларын санамаганда, Балкан сугышларына багышланган төрекчә шигырьләр артык юк та [Kâzım Nâmi Duru, 1957, б. 62].

Балкан сугышларының үзенә бу кадәр игътибар җәлеп итүендә Фатих Кәриминең Истанбулдан «Вакыт» газетасына җибәреп торган «Истанбул мәктүпләре»нең дә берникадәр йогынтысы булгандыр. Соңрак китап булып басылган әлеге хатлар, бу чорда төрек зыялылары, дәүләт эшлеклеләре һәм гади халыкның барлык тойгы-кичерешләрен уртага ачып сала. Аеруча имзасыз бастырылган «Балканда золым һәм җәберләр» дип исемләнгән [Балканда золым...], яки «Истанбул мәктүпләренә» кертелмәгән бүлекләр, татар җәмгыятенең бөтен катламнарына да зур йогынты ясый.

Казандагы «Йолдыз» газетасы Балкандагы хәлләрне күзәтү өчен Истанбулга Галиәсгар Камалны җибәрә. Истанбулны бик авыр кабул иткән Галиәсгар Камал Казанга әйләнеп кайтуга, «Йолдыз»да «Истанбул мәктүпләре» [Камал, 2010, б. 239–284] басыла башлый, ләкин хатлар сериясе тәмамланмыйча кала. 5 февральдан 9 июньгә кадәр «Йолдыз»да басылып килгән «Истанбул мәктүпләре»нең дәвамы, газетаның Истанбулдагы хәбәрчесе А. Әбүзәр авторлыгында чыга [Әбүзәр, 1913].

Петербургта укыган вакытында Истанбулда «Һилал-и әхмәрдә» («Кызыл ай») ирекле шәфкать туташы булып эшләгән Ростовтан Мәрьям Рәхмәт Поташованың «Истанбул хатирәләре» [Поташова, 1913], Чистайдан Өмме Гөлсем Камалованың «Шура»да бастырылган язмалары [Камалова, 1913], язучы Кәбир Бәкернең (1885–1944) Истанбулдагы хастаханә һәм яраланган солдатлар турындагы «Истанбул хатирәләре» [Бәкер, 1913], Себердән Фуат Әнвәрнең «Әдирнә мәктүпләре» [Әнвәр Себерле, 1913] һәм Абдулла Шинасинең (1885–1938) «Әдирнә мәктүпләре» [Шинаси, 1913] татар әдәбиятында киң бер юнәлеш – Балкан сугышы әдәбиятының барлыкка килүен күрсәтә.

Габдулла Тукай Балкан халкын кечкенә бер эт баласы, ә Төркияне күктә очкан бөркет белән чагыштырып язган «Тәмсил» [Тукай, 1912, б. 2] исемле шигырен Балкан сугышлары башланып бер ай үтүгә «Вакыт» газетасында бастыра. Шагыйрь

ачыктан-ачык Төркия яклы позициядә тору сәбәпле, әсәр цензурага эләгә һәм Советлар дәверендә басылып чыккан әдәбият җыентыкларына кертелми [Әмирхан, б. 330].

Шул ук елның 23 декабрендә Габдулла Тукай Балкан сугышларына багышланган икенче шигырен – «Балкан көйләре»н бастыра. Өч өлештән торган һәм татар халык көйләренә нигезләнеп язылган әлеге шигырьнең беренче өлеше түбәндәге юллардан гыйбарәт:

*«Төркия бетә*
*дип һәркем көтә, –*
*Балканнар эше*
*Гел алга китә.*
*Тик шул Әдернә*
*Алынмый менә.*
*Яния, Шкудра*
*Тиде теңкәмә.*
*Чыталҗа яман,*
*Аузы тулган кан,*
*Туплар дисеңме,*
*Зурлар дөньядан.*
*Ай-һай, Чыталҗа,*
*Син майлы калҗа;*
*Сине йотмыйча,*
*Истамбул кайда?»*

[Özkan, s. 352]

XIX гасырда Россиядә яшәгән шагыйрьләр арасында «Төркия» сүзен кулланып, чынбарлыкта исә Русия турында язылган шигырьләр күренә башлый. Әлеге юнәлешнең башында Габдулла Тукай күп тәрҗемәләр ясаган һәм ул якын күргән Михаил Юрьевич Лермонтов тора. Лермонтовның иҗатын өйрәнүче белгечләр моңа үрнәк итеп, аның «Жалобы турка» исемле шигырен китерәләр [Мәһдиев, б. 482]. Бу чор татар матбугатында да Төркия образы аркылы Россиянең тәнкыйть ителгәнлеген күрергә мөмкин.

«Мулла Насретдин» һәм «Каракүз» кебек журналларның даими укучысы булган Габдулла Тукай дәвер йогынтысы астында татар халкының мәдәни тормышында актив катнашкан күп кенә зыялыларны көлкегә ала. Әлеге шәхесләр арасында Йосыф Акчура, Габдерәшит Ибраһимов, хәтта Исмәгыйль Гаспралы да була. Фатих Кәрими 1908 елгы Госманлы революциясеннән соң, Әхмәт Мидхәт, Әбүзыя Тәүфикъ һәм Фатыйма Галия ханымнарга карата башланган салкын мөнәсәбәтнең, 1905 елгы Рус революциясеннән соң, Исмәгыйль Гаспралыга карата да булганлыгын түбәндәгечә аңлата: «1906 елда кайбер яшьләребез үзләренә кадәр булган бар нәрсәне инкарь итү, һәркемне кимсетү юлына бастылар, Гаспралыны исә 25 яшьлек хулиган дип атадылар» [Кәрими, б. 266]. Бу яшьләр – Казанда чыккан «Таң» һәм бераз соңрак «Таң йолдызы» газеталарына мәкаләләр язган Гаяз Исхакый җитәкчелегендәге Фуат Туктаров һәм Габдулла Тукайның якын дусты Сәгыйть Рәмиев кебек социалист юнәлеш тарафдарлары. Габдулла Тукайның Исмәгыйль Гаспралыга булган салкын мөнәсәбәтен үз чорының йогынтысы астында калган әлеге төркемгә бәйләп аңлату дөресрәк булыр. Ләкин Габдулла Тукайны гомере буена нинди дә булса бер фикер яисә идеология кешесе итеп кабул итү дөрес булмас. Ул, беренче чиратта, үзенең рухы буенча нинди дә булса фикергә

караганда, күбрәк хисләргә таянып эш иткән шагыйрь. Советлар чорында Габдулла Тукай шәхесе культ дәрәҗәсенә күтәрелә. Шагыйрь тарафыннан көлкегә алынган һәм кире кагылган татар зыялылары Советлар чорында Тукай белән бәйле «мәдәни террор» [Гайнетдин, 2014, б. 327] ярдәмендә татар мәдәни тормышыннан ераклаштырылалар.

Үзбәк профессоры Бәкали Касыймов, 1905–1917 еллар арасында шигырь яза башлаган үзбәк шагыйрьләренең күбесенең Габдулла Тукайны үзләренең остазлары итеп таныганлыклары; алар арасында Хәмзә Хакимзадә Ниязи, Гулам Зафари, Тавалла, Габдулла Әвлани һәм Мирмөхсин Шәрмөхәммәдовның булганлыгы турында яза [Kasimov, s. 39]. Хуҗамаяров Тавалла 1914 елда, Габдулла Тукай вафатыннан соң бер ел үтү уңаеннан, «Садаи Төркестан» газетасында шагыйрьнең 1906 елда басылган «Милләткә» исемле шигыренә комментарий яза. Тавалла газетага биргән кыска аңлатмасында үз тормышының да Тукай тормышына охшаганлыгын, аның нечкә һәм тәэсирле шигырьләреннән күп файда алганлыгын искәртә [Tavalla, s. 5–6].

Үзбәк шагыйре Габделхәмит Сөләйман Чулпан (1897–1938) 1925 елда язган бер мәкаләсендә үзенә «Нигә ачылды күзем, кая китте йокыларым?» соравын биргәч, җавап итеп, Габдулла Тукайдан башлап Кави Нәҗмигә кадәрге татар әдәбиятын укыганлыгы турында яза [Çolpan, s. 58].

Габдулла Тукай рус һәм төрек әдипләренең әсәрләре белән якыннан таныш булуына карамастан, аның шигъриятенең көче Урта Азия далаларыннан Истанбулга кадәрге киң аланда яңа татар әдәбиятының барлыгын, аның тәэсир итү көчен киң катлам укучыга җиткерә. Шул рәвешле Идел-Урал буендагы татар әдәбияты шундый киң аланда танылу ала.

Татар әдәбияты өлкәсендә фәнни эзләнүләр алып барган кешеләрнең Советлар чорында фәннилек тышчасына төрелгән сәяси фикерләр тәэсиреннән котылуы өчен, 1917 елга кадәр Габдулла Тукай турында язылган барлык бәяләмәләрнең бергә тупланып өйрәнелүе мөһим. Борһан Шәрәф, Муса Бигиев, Фәхри Ислам Агиев һәм Фуат Көпрүлүнең урынлы һәм чынбарлыкны чагылдырган фикерләренең [Гайнетдин, 2006, б. 18–20] һәм Габдулла Тукай белән төрек әдәбияты арасындагы мөнәсәбәтнең 1990 елларга кадәр игътибардан читтә калуын, булган әйберне күрмәмешкә салышуның типик үрнәге дип санарга мөмкин.

Бүгенге көндә Идел-Урал буе татар әдәбиятының тарихын өйрәнүче татар галимнәре алдында, әдәби казанышларның «мирас чүплегенә» ташлануына һәм нинди дә булса идеологик кысаларга игътибар итмичә, яңа татар әдәбиятының төрек әдәбияты белән бәйләнешләрен үзәккә алган фәнни тикшеренүләр үткәрү бурычы тора.

**Әдәбият**

*Әбүзәр А.* «Истанбул мәктүпләре» // Йолдыз. 1913. 5 февраль. № 940; 7 февраль. № 941; 10 февраль. № 942; 12 февраль. № 943; 14 февраль. № 944; 17 февраль. № 945; 19 февраль. № 946; 24 февраль. № 948; 26 февраль. № 949; 28 февраль. № 950; 7 март. № 953; 14 март. № 956; 21 март. № 959; 28 март. № 962; 4 апрель. № 965; 2 май. № 977; 7 май. № 979; 9 июнь. № 993.

*Әйди Тәуфикъ.* Кардәшләр кочагында. Казан: Аваз, 2000.

*Әмирхан Равил.* Иманга тугрылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

*Әнвәр Себерле Фуат.* Әдирне мәктүпләре // Вакыт. 1913. 15 август. № 1275; 1913. 17 август. № 1276.

Балканда золым һәм җәберләр // Вакыт. 30 декабрь. № 1095.

*Бәкер Кәбир.* Истанбул хатирәләре // Вакыт. 1913. 14 июнь. № 1224.

*Вәлиди Җамалетдин.* Татар шагыйрьләре // Вакыт. 1913. 26 июль. № 1259.

*Вәлиди Җамал.* Габдулла Тукай Мәҗмугаи асаре. Казан: Мәгариф, 1918.

Габдулла Тукай шигырьләре. Дүртенче дәфтәр. Казан: «Үрнәк» матбугаты, 1909.

*Гайнетдин Мәсгуд.* Балкан сугышы һәм татар әдәбияты // Заман-Татарстан. 1997. 17 апрель. Б. 8.

*Гайнетдин Мәсгуд.* Без элек тә без идек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.

*Гайнетдин Мәсгуд.* Г. Тукай һәм әдәби тәнкыйть // Дин вә әдәп. 2006. май. Б. 18–20.

*Галәү.* Шигырь тирәсендә // Вакыт. 1913. 25 апрель. № 1184

*Галимуллин Ф.Г.* Мотыйгулла хәзрәт һәм Габдулла Тукай // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни башлангычлар. Казан: ИЯЛИ, 2011. Б. 35.

*Гыйләҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 219.

*Гыйләҗев Т.Ш.* Габдрахман Сәгъди Тукай турында // Габдрахман Сәгъди. Казан: Җыен, 2008.

*Думави Н.* Хәсрәт чаткылары. Казан: Матбаа-и Кәримия, 1914.

*Камал Г.* Әсәрләр. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

*Камалова Гөлсем.* Төрекләр арасында // Шура. 1913. № 1. Б. 16

*Камалова Гөлсем.* Төрекләр яшәячәк // Шура. 1913. № 6. Б. 175–176.

*Камалова Гөлсем.* Таали-и Нисван җәмгыяте // Шура. 1913. № 7. Б. 203–204.

*Камалова Гөлсем.* Төрек хатыннары //1913. № 8. Б. 232–233.

*Кариев Габдулла.* Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы // Мәктәп. 1913. № 4. Б. 102–103.

*Кәрими Фатих.* Истанбул мәктүпләре.

*Мәһдиев М.* «Тарихтан сабак», Җамал Вәлиди. Казан: Җыен, 2010.

*Мотыйги Камил.* Мәшһүр шагыйрь Габдулла Тукаев турында хатирәләрем. Казан: Электро-Типография «Өмет», 1914.

*Османи Исхак.* Балканда // Вакыт. 1913. 3 март. № 1114.

*Поташова Мәрьям Рәхмәт.* Истанбул хатирәләре // Вакыт. 1913. 16 май. № 1201; 1913. 29 май. № 1211; 1913. 13 июнь. № 1223; 1913. 10 июль. № 1245.

*Сүнчәләй Сәгыйть.* Әсәрләр һәм хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

Татар әдәбияты тарихы. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

*Төхфәтуллин К.М.* // Фикер. 1906. 15 октябрь № 38.

*Тукай Г.* Әсәрләр. Т. 4. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015.

*Тукай Г.* Тәмсил // Вакыт. 1912. 7 ноябрь. № 1067. Б. 2.

Тукай турында замандашлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

*Шинаси А.* Әдирнә мәктүпләре // Вакыт. 1913. 3 сентябрь. № 1287; 1913. 4 сентябрь. № 1288; 1913. 5 сентябрь. № 1289.

Abdullah Tukay Mecmua-yı Âsârı. a.g.e.

*Battal A.* Nazariyât-ı Edebiyye. Kazan: Ümit Matbaası, 1913. S. 42.

*Celal M.* Osmanlı Edebiyat Numuneleri. Dersaadet: Matbaa-i Safa ve Envar, 1312.

*Çolpan.* Adabiyat Nadir. Taşkent: Çolpan Naşriyatı, 1994.

*Eliot T.S.* Edebiyat Üzerine Düşünceler, Cev. Sevim Kantarcıoğlu. İstanbul: Paradigma yayınları, 2007.

*Kaleci Vahit*. Abdullah Cevdet'in Türkçe Şiirleri. İstanbul: İstanbul Üniversitesi Edebiyat Fakültesi Yeni Türk Edebiyatı Kürsüsü (Yayınlanmamış Mezuniyet Tezi), 1972.

*Kasımov Begali.* Salom Kelajak. Taşkent: Gafur Gulam Namıdaki Adabiyat va Sanat Naşriyatı, 1986.

*Kâzım Nâmi Duru.* İttihat ve Terakki Hatıralarım. İstanbul: Sucuoğlu Matbaası, 1957.

*Kaya Nuri.* Türk Şairleri. İstanbul: Mahmud Beg Matbagası, 1339.

Kısm-ı Edebi // Türk. 1907. 30 Mayıs. No: 194.

*Köprülüzade Mehmet Fuad.* Abdulla Tukayev // Türk Yurdu. 1913. 16–29 Mayıs. Sayı: 40; Ankara: Tutibay Yayınları. 1999.

*Kubilay Aktulum.* Metinlerarası ilişkiler. 2 baskı. Ankara: Öteki Yayınevi, 2000.

*Özkan Fatma.* Abdullah Tukay'ın Şiirleri İnceleme-Metin-Aktarma. Ankara: Türk Kültürü Araştırma Enstitüsü. 1994.

*Sünçeley Segıyt.* Eserler Hem Hatlar. Kazan: Tataristan Kitap Neşriyatı, 2005. S. 255.

*Sünçeley Said.* Türkge // Türk Yurdu. 16–29 Mayıs 1913. Sayı: 40. Ankara, Tutibay Yayınları, 1999.

*Tavalla.* Ravnakü'l-İslam. Taşkent: Özbekistan Respublikası Fanlar Akademiyasınıng «Fan» Naşriyatı, 1993.

*Velidi Cemaletdin.* Abdulla Tukay Mecmua-yı Asarı. Kazan: Maarif matbaası, 1918.

Yeni Türk Edebiyatı Antolojisi IV Ekrem, Hamid, Sezai ve Ara Nesil, Haz. Mehmet Kaplan, İnci Enginün, Birol Emil, Zeynep Kerman. İstanbul: Marmara Üniversitesi Yayınları. No: 626, 1997

***Доктор Хөсәен Барган,***
*Истанбул университеты доценты*
*huseyinbargan@yahoo.com*

УДК 398

*И.Г. Закирова*

# ФОЛЬКЛОРДА СУ ИЯЛӘРЕ ҺӘМ СУ КУЛЬТЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ МИФОЛОГИК МОТИВЛАР

Статья посвящена анализу татарских мифов, легенд и верований, связанных с культом воды и образами водяных духов. В тюркской мифологии вода является эквивалентом первоначального хаоса; стихией, ответственной за появление и возрождение всего живого. Мотивы, связанные с культом воды, можно разделить на две группы: вода как объект почитания и мотивы, посвященные духам-хозяевам водоемов.

**Ключевые слова:** живая вода, водяные духи, Су анасы (водяная), культ воды, жертвоприношения.

Күпчелек халыклар өчен дөнья төзелеше, төрле дөньялар турындагы мифологик карашлар уртак. Дөнья үзеңнекенә һәм ятлар яши торганга бүленә. Бу ике дөнья арасында аерым ориентирлар белән билгеләнгән чик үтә. Халыкның башка, ягъни үзен чолгап алган ятлар дөньясы, аның вәкилләре, ияләре белән үзара мөнәсәбәте, элемтәләре аерым ритуаллар ярдәмендә җайга салынган. Ритуал ярдәмендә һәр якның хокуклары, вазыйфалары, бурычлары билгеләнә. Шул рәвешле һәр йола һәм ритуал җәмгыятьтәге яшәү тәртипләренең бер элементы булып тора. Шушы йолалар аша кеше үзенең дөньядагы урынын барлый, үзен шул дөньяның бер өлеше буларак кабул итә.

Төрле дөньялар арасындагы чикне, кабул ителгән тәртипне бозмау – кешенең, гаиләнең, җәмгыятьнең иминлеген тәэмин итүгә китерә. Ятлар дөньясына үтеп керү җәмгыятьтәге тотрыклылыкны, гармонияне бозуга китерә.

Татар халкының ятлар дөньясы, аларның вәкилләре – төрле ияләр турындагы ышанулары мифологик хикәятләрдә сакланган. Бу әсәрләрнең бер үзенчәлеге шунда, алар чынбарлыкта булган вакыйга буларак бәян ителә. Төрле ияләр белән очрашуларны бәян иткән бу әсәрләр бүгенге көндә татар фольклорында иң популяр жанр булып тора.

Татар халкының су белән бәйле мифологик карашларын чагылдырган мифологик хикәятләр, ышанулар, йолалар күп. Аларны шартлы рәвештә ике төркемгә аерырга мөмкин: суны сакральләштерү һәм су ияләре – су хуҗалары образлары белән бәйле мотивлар. Еш кына су яки сулыкны сакральләштерү су иясе образын олылау белән кушылып та китә.

Мифологик хикәятләрнең иң күп таралганы – кешенең Су иясе белән очрашуын тасвирлый торган әсәрләр. Татар халкының мифологик хикәятләре буенча Су ияләре елга, күлләрдә яши. Татар халкында «Иясез су юк» дигән

ышану бар. Мифларда Су анасы матур хатын-кыз итеп сурәтләнә: «Су кызы бик матур, үзе сагышлы булган. Озын чәчләреннән су агып тора икән» [Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар, б. 284]. Киресенчә, шыксыз итеп тә сурәтләнергә мөмкин: «Аның гәүдәсе кеше гәүдәсенә охшаса да бик үк зифа түгел: толымы җиргә җиткән – бик озын, башы бик зур, озынча, күзләре бик зур, тум кара, атылып чыгып тора, күкрәге дә бик киң алга калкып тора, тәне бакырсыман-кызыл була» [шунда ук, б. 285].

Габдулла Тукай үзенең «Су анасы» әкият поэмасын татар халкының су ияләре турындагы мифологик ышануларына нигезләнеп яза. Поэма турында Г. Тукай «Бер авыл малае авызыннан» дигән искәрмә бирә. Поэманың нигезендә су анасының басмага чыгып чәчен тараву турындагы хикәят ята. Шагыйрь Су анасын түбәндәгечә сурәтли:

Карасам: бер куркыныч хатын
утырган басмага,
Көнгә каршы ялтырый кулындагы
алтын тарак;
Шул тарак белән утыра тузыган
сачен тарап
[Тукай, б. 283].

Су ияләре белән бәйле хикәятләр берничә сюжетка корылган. Аларда Су анасының ярда яки басмада алтын тарак белән чәч таравы, билгеле бер вакытта Су ияләренең тынычлыгын бозарга ярамау, тыюны бозучыларның җәзалануы турында сүз бара.

Татар халык ышанулары буенча көн үзәге, көндезге 12 белән 2 арасында Су коенырга гына түгел, сулыклар янында булырга да ярамый. Бу вакыт башка дөнья вәкилләренең вакыты.

«Су анасы» поэмасының текстыннан аңлашылганча, Су анасы нәкъ шул вакытта чәч тарарга чыккан. Чөнки су буенда вакытны оныткан малайдан башка бер кеше юк. Малай да вакытсыз йөрүен аңлап куркуга төшкән.

Җәй көне. Эссе һавада мин суда
койнам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым
белән суны сөзәм.
Шул рәвешле бер сәгать ярым
кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм
дип уйлагач,
Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз
киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән, – юк
янымда юлдашым.

Малай Су анасының алтын тарагын урлап кача. Риваятьләрдә Су анасының аерылгысыз атрибуты итеп аның алтын тарагы күрсәтелә. Ул ярга яки басмага чыгып утырып чәчен тарый, куркып, алтын тарагын онытып калдырырга да мөмкин. В.Я. Пропп, төрле халыкларның фольклорын тикшереп, алтын яки алтынланган һәр әйбер икенче дөнья белән бәйләнешне күрсәтә дигән нәтиҗәгә килә [Пропп, б. 284].

Халык ышанулары буенча, вакытсыз су буенда йөргән кешенең, ул исән калса да, тынычлыгы бозыла. Икенче дөнья ияләре аның артыннан өенә килеп, тынычлыгын ала. «Су анасы» поэмасында да шушы ышану тасвирлана.

Малай Су анасының алтын тарагын урлап, ике дөнья арасындагы гармонияне боза. Бары алтын тарак иясенә кайтарылганнан соң гына дөнья үз урынына урнаша.

Г. Тукай әлеге поэмасын балаларга атап язган булу әсәрдә дидактик басымның көчәюенә китерә. Бала, беренче чиратта, кеше әйберенә тияргә ярамый, дигән нәтиҗәгә килергә тиеш.

Поэманың эчтәлегенә яткан дөньяның гармониясен тәэмин иткән үзара хөрмәткә корылган мифологик эчтәлек икенче планга күчкән. Үзара хөрмәт бу очракта кешенең табигатькә мөнәсәбәтен дә чагылдыра. Поэмадагы Су анасы – ул табигать, су символы да. Поэмада табигатьне саклау, аңа сакчыл караш турында да сүз бара.

Су аллалары, су ияләре бик борынгыдан килгән мифик образлар. Су аллалары дөньяның күпчелек халыкларына мәгълүм. Борынгы греклар диңгез алласы Посейдонны олылаганнар. Борынгы римлыларның диңгез алласы – Нептун. Ул аларда пантеонның иң югары баскычларын биләүче аллалардан саналган. Рим халкы 23 июльдә Нептун хөрмәтенә Нептуналия бәйрәме уздырган. Алар Нептуннан корылык җибәрмәвен сораган [Мифы народов мира, с. 211].

Төркиләрнең дә Җир-Су дигән аллалары булган. Бу Изге Җир-су алласы, ягъни «Ыдук Йири-Субы».

Төркиләрне яклап, саклап торган әлеге алланың исеме VIII гасырга нисбәт ителгән Күл-Тәгин истәлегенә куелган ташъязмада сакланган:

Үзә түрк тәңриси
Түрк ыдук йири субы анча тимис:
Түрк будун йок болмазун тийин
Бодун болсун, тийин
[Малов, с. 29].

(Но) вверху небо тюрков
И священная Земля и Вода тюрков так сказали:
«Да не погибнет, говоря, народ тюркский,
Народом пусть», – так говорили
[Малов, с. 37].

Вакытлар узу белән диңгез, су аллалары, су хуҗалары белән алмаштырыла. Кешеләр һәр сулыкның үз иясе, хуҗасы бар дип ышаналар.

Болгар чорында да Су анасын чибәр хатын-кыз итеп күзаллаулары мәгълүм. Дөрес, ул Болгар җирендә түгел, ә кайдадыр еракта – Йура җирендә яшәүче зат итеп сурәтләнә. Болгар чорының Су анасы турындагы күзаллаулар Абу Хамид ал-Гарнати сәяхәтнамәсендә урын алган: «...И изнутри его вышла девушка, похожая на потомков Адама: белая, краснотелая, черноволосая, толстозадая, прекраснейшая из женщин. И взяли ее жители Йура и привезли на сушу, и это существо стало бить себя по лицу, и рвать волосы, и вопить. А Аллах сотворил ей в ее средней части, от пояса до колен, нечто вроде белой кожи, похожую на крепкую плотную ткань, покрывающее ее срам, будто изар обвязанный вокруг пояса и прикрывающий ее срам» [Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати…, с. 34].

Әл-Гарнати Су кызының үз стихиясе судан аерылганнан соң озак яшәмәвен, җирдә үлүен яза [шунда ук, с. 34].

Татар мифларында Су анасы белән беррәттән, су ияләре буларак Су бабасы, Су атасы, Су иясе яки хуҗасы, Су кызы, Су ирәне дә күрсәтелә. Кайбер мифларда аларны бер гаилә итеп тә сурәтлиләр. Сулыкларның төп хуҗасы – Су бабасы, Су анасы – аның хатыны, Су иясе – уллары. Су анасы төн уртасында басмага чыгып улларын юа. «Су бабасы бар тирә-як суларның иң тирәнендә генә торып, шул тирәдәге суларның барсына да боерык таратып тора. Ул инде бик картайган, бүтән су ияләре аны олылап, ни кушса, шуны эшләргә көтеп кенә торалар. Ул бик кирәк чагында гына, бик зур йомышларда гына эшләр карый, боерыклар чыгара». «Су иясе нинди генә су булмасын, шунда тора. Бабасына бер генә дә охшамаган: ул аз гына җүләрсымак итеп эш эшли. Тегермән буаларын ерып җибәрә, балыкчылардан балыкны куа, кешеләрне, терлекләрне тотып су астына тарта да, шунда буып үтерә» [Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар, б. 283–284].

Татар һәм башкорт фольклорында Су ияләренең исемнәре дә бар:

Су анасы – Сылубикә,
Су атасы – Сөләйман, –

диеп аларга мөрәҗәгать итәләр [Татар мифлары, т. 1, б. 127].

Татарлар дога кылганда «Су атасы Сөләйман, су анасы Сылубикә хакы-хөрмәте өчен» дип, дога колалар. Бу мәҗүсилекнең ислам дине белән керешеп китүен күрсәткән бер күренеш булып тора.

Татар халкының бер ышануы Су аналарының килеп чыгуын, аларның кара көчләргә каравын күрсәтә: «Яшен аткан шайтан урманга төшсә – убыр, җиргә төшсә – албасты була, суга төшсә – Су анасына әверелә» [Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр, б. 515].

Бу турыда русларда легенда да бар: «Был на земле только Бог и дьявол. Бог сотворил человека – и дьявол попробовал сотворить, но сотворил не человека, а черта, и как он ни старался, ни трудился, все же не мог сотворить человека, все у него выходили черти. Бог увидил, что дьявол уже сотворил несколько чертей, рассердился на дьявола и велел Архангелу Гавриилу (старшему из всех ангелов) свернуть их (сатану и всю нечистую силу) с неба, Гавриил свергнул. Кто упал в лес стал – леший, кто в воду – водяной, кто на дом, «Кормилец» [Дилакторский].

Бу ышанулардан күренгәнчә, мәҗүсилек чорында изгеләштерелгән затлар, монотеистик дип кабул ителгәннән соң, явыз шайтани көч буларак күзаллана башлый. Шулай итеп, каршылыклы образ туа.

Су ияләре образы татар һәм башкорт халкының уртак мирасы «Түләк» дастанында да урын алган. Бу әсәр татар халкында язма дастан булып популярлашса [Госманов, б. 225–300; Әхмәтҗанов, б. 14–33], башкортлардан XX гасырда да телдә сакланган күпсанлы вариантлары язып алынган [бу турыда: Башкирский народный эпос]. Башкорт вариантларын язып алып, бастыру эше XIX йөздә башлана.

Дастан ике стихия вәкилләре – җир егете Түләк белән Су кызы Сусылуның мәхәббәтенә багышланган. Әсәрдәге төп вакыйгалар Түләкнең Ачылы күл буена барып чыгып Су кызын күрүе, аңа гашыйк булуы белән башланып китә: «Тут он заметил на берегу у воды отблеск каких-то лучей. Удивился Залтуляк и стал осторожно приближаться к тому месту, где сверкали лучи. И что же он видит: на берегу, на плоском камне, сидит водяная девушка и, распустив косы, расчесывает золотым гребнем черные волосы длиною в шестьдесят коласов. Свет над Асыл-Куль [– озером] исходил, оказывается, от той прекрасной девушки, которая вышла из воды и прихорашивалась. Изумленный красотой девушки, долго стоял егет и не мог прийти в себя» [Башкирский народный эпос, с. 420–421] Башкорт версиясендә Су кызы үзен нурдан яралуын, кеше булмавын әйтә. Җир кешесе белән нурдан яратылган Су кызының тиң булмавын белдерә.

– Сибәр егет, шаулама,
Атым минем – Һыуһылыу,
Мине һорап даулама;
Егет, һиңә тиң булмам,
Нурзан тыуган токоммон,
Ерзә йөрөтеп хурлама;
Ер улыма тиң булмас
Нурзан тыуган кыз бала.
Егет һүзең озайтма,
Ебәрә күр, ер улы,
Атам белһә, яу, һалыр,
Башыма киәмәт һалыр

[Башкирский народный эпос, с. 209].

Успокойся, красивый егет,
Имя мое – Хыухылу,
Ты не добивайся меня,
Егет, не могу быть ровней тебе.
Я создана из лучей,
Не глумись [надо мной] заставив по земле ходить,
Не буду равной сыну земли
Девушка, созданная из лучей,
Егет, не уговаривай меня,
Отпусти меня, сын земли,
Если узнает отец, на тебя пойдет войной,
На голову твою падет беда

[Башкирский народный эпос, с. 421].

Нурдан яратылу кызның башка дөнья вәкиле булуын күрсәтә. Фольклорда нурдан яратылу илаһи дөнья белән бәйләнешкә дә ишарә итә.

Дастанның шушы ук версиясендә су асты дөньясы да тасвирлана: «Спустившись на дно озера Асылыкуль и открыв глаза, Заятуяк увидел совсем иной таинственный мир. На просторных лугах пасутся бесчисленные стада, в журчащих речках золотые рыбы играют, а в глубоких озерах – утки, лебеди, дикие гуси» [Башкирский народный эпос, с. 423]. Татар версиясендә су асты дөньясы исә, анда кояш-ай булмау белән характерлана: «Бер заман көн, ай күренмәс йиргә чыкды. Бер булат сарай торыр. Алда – йанындин бердәй [дәрйалар] акып барыр: [йанында] балдин, йәнә алдында сөт дәрйасы акып барыр» [Госманов, б. 243].

Ике стихия вәкиленең мәхәббәте фаҗига белән, геройларның һәлакәте белән тәмамлана, бу аларның мөнәсәбәте гайре табигый булуын күрсәтә.

Татар халкында су ияләре белән бәйле ышанулар хәзергә

кадәр саклана, су ияләренең күңелен күрер өчен төрле йолалар башкарыла, тыюлар-табулар бар.

Су ияләре культы белән бәйле йолаларның берсе – киленгә «су юлы күрсәтү» йоласы. Ул туй йолалары циклына кергән, хәзерге көнгә кадәр үтәлә торган йола. Яшь киленгә су юлы күрсәтү йоласының төп максаты – киленне су иясе белән «таныштыру». Яшь килен беренче тапкыр суга баргач, шул суның хуҗасына бүләк бирә. Бу түгәрәк икмәк, акча булырга мөмкин. Килен икмәкне чишмәгә яки коега сала, су иясенә ошарга, аның күңелен күрергә омтыла. Бу йола күп халыкларда мәгълүм йолалардан. Мәсәлән, осетин халкында ул үзенең асылын саклап калган. Ул осетиннарда донмоконд дип атала, туйның төп йолаларыннан берсе. Бу – су хуҗасы Донбеттырга киленне күрсәтү йоласы [Мифы народов мира, т. 1, с. 392].

Татар халкында чишмәдән беренче тапкыр су эчкәндә анда акча яки чәч өзеп салу йоласы хәзерге вакытка кадәр саклана. Суга: «Сиңа яулык, миңа саулык» дип «бүләк» салу борынгыларның су иясенә корбан бирүнең эзе булса кирәк. Борынгы заманнарда су иясенә корбан бирү әкиятләрдә сакланган. Дәрья төбендә яшәгән аждаһага билгеле бер вакыт саен корбан биргәннәр. Диңгездә давылга эләккән диңгезчеләр дә, диңгез патшасына жирәбә салып корбан биргәннәр.

Су иясенә корбан бирүнең бер төре «Яңгыр боткасы пешерү» йоласында башкарыла. Мәҗүсилек чорында Су ияләренә корбан суеп, корылык җибәрмәвен яки яңгыр сораганнар.

Су иясе кара төстәге терлекләрне ярата дип ышаналар. Шуңа күрә тегермәнчеләр дә бары кара төстәге терлек кенә асраган. Корбанга да кара төстәге терлек суелган. Әлеге йоланың эзләре балалар фольклорында, эндәшләрдә сакланган:

Яңгыр, яу, яу!
Кара сарык суярмын,
Ботын сиңа куярмын.

Шулай ук балалар су коенып чыкканда:

Исәнлегем саулыгым,
Тазалыгым – байлыгым
Сиңа яулык –
Миңа саулык, –

дип чыгалар. Бу да су анасына бүләк бирүне аңлата.

Хәзерге көнгә кадәр сакланган ышануларда яз көне су анасының улавы тасвирлана. «Су анасы язын бик елады, егет-оланнар, су кермәсен, батар», – дип ышаналар [Автор материалларыннан]. Яз көне су анасына корбан бирәләр, икмәк, күмәч һ.б.

Кояш баеганнан соң, су коенырга, су алырга барырга да ярамый. Бу – су ияләренең вакыты, аларны бимазалау тыела. Башкорт халкында Кояш баегач су алырга туры килсә, алар «Кунак төштө, кунак төштө, һыу бир» (гость приехал, гость приехал, дай воды) – дип, су иясеннән рөхсәт сорыйлар [Хисаметдинова, с. 354]. Башкортларда да Су иясенең дүрт исемен әйтеп су алу йоласы бар: Вәсәккәһем, Раббаһым, Шарабаһым, Тәһүрә (Васаккахим, Раббахым, Шарабахым,

Тахура) [шунда ук, с. 355]. Кояш баегач су коенган, су алган кеше авырып китәргә мөмкин. Бу тыю шулай ук «Су пәрдәсе» дигән ышану белән бәйле. «Кояш баегач су пәрдәсен яба икән, шуңа кичен су алырга ярамый», диләр [шунда ук, с. 355].

Су белән бәйле ышануларның берсе – «Су тоту». Ул да төрки халыкларда шактый таралган ышану. Кеше үзе беренче тапкыр күргән чишмәдән су алганчы, анда берәр нәрсә (чәч, җеп, тәңкә) сала. Хәзерге көнгә кадәр чишмәгә икмәк китерәләр. Су иясенең күңелен күреп, чишмәгә, кер юар өчен, сырлы бәләк яки чүмеч, чынаяк куялар.

Су белән бәйле йолаларның күбесе суны сакральләштерүгә кайтып кала. Ягъни суның сихри, гайре табигый көчен тану. Бу мотив татар халкының борынгы ышануларыннан килә һәм безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Татар фольклорында да дөнья халыкларының күбесенә мәгълүм Тере һәм Үле сулары турындагы ышану чагылыш тапкан. Тере суны икенче төрле тереклек суы, мәңгелек суы һәм Әбелхәят дип атыйлар. Легендалар буенча, Әбелхәят суын эчкән кеше үлемсезгә әйләнә, яки ахырзаманга кадәр яши. Ә тере суы үлгән кешене дә терелтү сәләтенә ия.

Мәңгелек су эзләү турында эпизод «Коръәндә» дә бар. «Аль-Кахф» («Пещера») сүрәсендә Муса пәйгамбәрнең хезмәтчесе белән ике диңгез кушылган җирне эзләп юлга чыгуы тасвирлана: «Әлбәттә, туктамыйча китәрмен, ике диңгезнең кушылган җиренә барып җиткәнче, яки туктамыйча озын заман китәрмен» [Коръән, 18:60]. Муса пәйгамбәрнең юлга чыгуының сәбәбе Хозыр г-мне эзләп табу.

Муса пәйгамбәр хезмәтчесе белән ике диңгез кушылган җиргә читкәч, анда кипкән балыкларын онытып калдыралар. Кипкән балыклар терелеп, суга, диңгезгә кереп китә. М.Б. Пиотровский бу эпизодны тере су белән бәйләп аңлата: «Её коснулась живая вода, но этого в тексте не сказать» [Пиотровский, с. 105]. Галим ике диңгезне Тигр һәм Евфрат елгалары белән бәйләп карый һәм әлеге сюжетның чыганакларын да күрсәтә:

«Истоки этого сюжета много древнее чем Роман об Александре. Каран сохранил память и об этих, древнейских связах сюжета. «Место слияния двух морей», где происходит кораническое действие, – это там, где Тигр и Евфрат (пресное море), соединившись, вливаются в Персидский залив (соленое море). Там же, в районе Бахрейна, подземные реки Аравии выходят в море, создавая на дне его пресные родники. В эти места (на Бахрейне, древнем Дильмуне) древние месопотамии помещали рай, место вечной жизни. В этих местах происходило действие многих древних сказаний о поисках источника вечной жизни» [шунда ук, с. 111].

Бу сюжет Көнчыгыш халыкларында Александр Македонский исеме белән бәйле рәвештә дә яши.

Александр Македонскийның мәңгелек су эзләве Көнчыгыш халыклары фольклорында һәм

әдәбиятында чагылыш тапкан. Низами Гянжевиның «Искандар-наме» поэмасында Александр Македонскийның үлемсезлек биргән мәңгелек су эзләп юлга чыгуы бәян ителә [Низами]. Искәндәрнең тере су эзләве Таҗетдин Ялчыголның «Тарих намә-и болгар» әсәрендә дә тасвирлана: «... Сократ прибыл в область Йунан (Греция), где был хакимом у Искандара и, указав ему на путь к «Источнику жизни», они отправились на север» [Усманов, с. 161].

Шушы ук сюжет Насреддин Рабгузиның «Кыйсасел әнбия» дигән китабында да бар. Анда да Александр Македонскийның тереклек чишмәсен эзләве бәян ителә: «Көннәрдән бер көнне патша үзенең дус фәрештәсенә әйтте: «Аллаһы Тәгаләгә камил коллык кылу өчен мин озын гомер телимен». Фәрештә әйтте: «Әгәр озын гомер теләсәң, җирнең төньягында караучылыкта бер чишмә бар. Шул чишмәнең суын эчкән кеше ахырзаманга кадәр яшәр» – диде. Зөлкарнәен тереклек чишмәсен эзләде. Әмма насыйп булмады [Рабгузый, с. 285].

Насреддин Рабгузи тереклек чишмәсен кем табуын да хәбәр итә: «Хозыр г-мгә насыйп булып, ул чишмәдән эчте» [Рабгузый, с. 285]. Дини риваятьләрдә Хозыр г-мнең мәңгелек суын эчкән бердәнбер кеше һәм үлемсезлеккә ирешкән пәйгамбәр булуы сурәтләнә.

Искәндәрнең тереклек суын эзләве хакындагы эпизод Баһавиның «Бүз егет» дастанында да бар.

Җаны үлемгә йиткәндә,
Йирнең йөзе бозылып,
Көннең күзе тотылып,
Мәңге суны табалмай
Егерме дүрт яшендә
Искәндәр үткән дөньядан
[Дастаннар, с. 327].

Александр Македонский кебек үк, Чыңгыз ханның да үлемсезлек эликсиры, ягъни мәңгелек суы эзләве мәгълүм. Чыңгыз хан үлемсезлек эликсиры тапкан дип даны чыккан бөек даос Чан Чунь белән очраша. Бөек хан сүзне нәкъ үзен кызыксындырган сораудан башлый: «Святой человек, какой эликсир бессмертия привез ты для меня из своей далекой страны?» «Я знаю много средств, чтобы защитить жизнь, но ни одного, чтобы дать бессмертие», – очень мудро ответил китайский монах» [Лунквист; Мишель Хоанг, с. 311].

Татар халкында кешенең бу дөньяда вакытлы булуын аңлаткан: «Беркем дә мәңге суы эчмәгән», – дигән мәкаль дә бар.

Мәңгелек суы турындагы ышану әкиятләрдә дә шактый очрый. «Алтын Алма» дигән әкияттә тере суының авыруларны, үлемне терелтү сәләтенә ия булуы тасвирлана. Герой берсеннән тере, икенчесеннән үле суы агып торган ике чишмә таба. Тере суны күзләренә тидергән сукыр карт күрә башлый, агачка әверелдерелгән гаскәр терелеп кеше була [Әкиятләр, т. 1, б. 232–233].

«Аучы» дигән әкияттә тере суы чишмәсе турындагы эпизод үзгәреп, зур су буларак сурәтләнә. Үлгән кешене анда алып барып югач та, ул яңадан терелә [Әкиятләр, т. 2, б. 56]. «Аучы егет

һәм җәнлекләр» дигән әкияттә дә үле һәм тере сулары ярдәмендә үлгән кешене терелтү турында сүз бара: «... әүвәле хуҗага үле суын сипте, аннары тере суны сипте. Теге терелеп сикереп торып утырды» [шунда ук, б. 64].

«Яшьлек суы» дигән әкияттә дә үле һәм тере сулары турында сүз бара. Гомумән, татар әкиятләрендә бу ике су параллель кулланыла, һәм үле геройны ике су ярдәмендә генә терелтеп була.

Алтай эпосы «Козын-Эркеш»тә дә Байым-Сурның Козын-Эркешне терелтү өчен тере су – котык суга мөрәҗәгать итүе тасвирлана:

Изрубленное тело сложила,
Целебной водой омыла
[Козын-Эркеш, с.].

Алтай теленнән Котык су – җан суы дип тәрҗемә ителә.

Башкорт эпосы «Урал батыр»да да мәңгелек чишмәсе тасвирлана. Әлеге кобаерда мәңгелек чишмәсе – җанчишмә дип атала, һәм ул үлемсезлек бирүче чишмә.

«...Был дөньяла үлмәскә,
Кора ергә кермәскә –
Минем илдә булмаган,
Үзен берәү күрмәгән,
Дейеү батша белгән
Йәншишмәнең һыуы бар...»
[Башкирский народный эпос, с. 108].

«Чтобы в мире бессмертие обрести,
Чтобы в черную землю не уйти,
Есть живой Родник...»
[шунда ук, с. 318].

«Үлем – бер хак» булуны акылы белән кабул иткән халыкның фольклорында тере һәм үле суларын сихри көче бераз киметелгән «хәл кертә торган» су алыштыра. Бу су да ике төрле, берсе «хәл кертә торган су», икенчесе «хәлне бетерә торган су». «Таңбатыр» әкиятендә нәкъ шундый шифалы су турында сүз бара да: «Менә монда ике мичкә бар, аның берсендә көч кертә торган су, икенчесендә хәл бетерә торган су, ди» [Әкиятләр, т. 1, б. 248]. «Ике туган» дигән әкияттә дә көч бирә торган су барлыгы сурәтләнә: «Кем дә кем бу савыттан суны эчсә, эчкән кешегә бөтен дөнья халкы каршы торса да, җиңә алмый» [Әкиятләр, т. 2, б. 81].

Аерым чишмә, күл суларының хәл кертү, дәва үзлегенә ия булулары турында ышану татар халкында суның сихри көченә ышануга китерә. Хәзерге вакытка кадәр татар халкында аерым чишмәләрне изгеләштерү, аның суын дәвага алу традициясе яши. Бу очракта үзенең минерал составы белән шифалы саналган сулар турында бармый. Чишмәләрне изгеләштерү, кагыйдә буларак, берәр риваять белән канунлаштырыла. Шундый чишмәләрдән Болгар чорына караган Болгар һәм Биләр (Бүләр) шәһәрләре территориясенә кергән изгеләр чишмәсе һәм суы дәвалау үзлегенә ия саналган Габдрахман коесын мисалга китерергә була. Изгеләр чишмәсенең килеп чыгуы, кагыйдә буларак, берәр изге кешенең исеме, аның үлеме белән бәйле. Яки, Биләрдәге Изгеләр чишмәсе кебек, ил күләмендәге зур тарихи вакыйгалар белән бәйле рәвештә

сакральләштерелә: «Бүләр шәһәрен дошман явыннан саклаган Тырышмал хуҗаны һәм аның унике кызын дошманнары Хуҗалар тавына китерә. Монда алар дошман кушуы буенча, яланаяк килеш көне-төне туфрак ташып, яңа бер тау өйгәннәр. Дошманнар, биек тау өелеп беткәч, Хуҗаны һәм аның кызларын шул тау башына терелэй җиргә күммәкче булганнар. Шулчак кызлар унике йолдыз булып күккә күтәрелгәннәр, ә Тырышмал Хуҗа таудан сикереп, елга суына әйләнеп, агып киткән. Халык хәзер дә шул елга башланган чишмәне изге санап, аңа адарына, ә кызлар өйгән тауны «Кыз тавы» дип атый» [Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар, б. 38]. Әлеге чишмә хәзерге вакытта республикада яшәүче руслар, татарлар, чувашлар һ.б. халыкларның барып йөрү урыны. Өлкән яшьтәгеләр биредә корбан суеп, дога укыр өчен барса, яшьләр өчен ул – тарихның җанлы шаһите.

Күп кенә изге чишмәләрнең риваяте нәкъ менә болгар чоры белән бәйле, яки алар борынгы кала территориясендә урнашкан. Болгар чоры риваятьләрендә дошман яуларына каршы көрәшкән ил батырлары яки сәхабәләр исеме белән бәйле коечишмә тарихлары бәян ителә. Болгар шәһәре территориясендәге Габдрахман коесы Болгарга килгән ислам миссионеры Габдрахман сәхабә исеме белән бәйле [Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар, б. 25]. Бу кое «Шәһри Болгар бәетләре»ндә дә телгә алына:

Габдрахман коесыннан дәвага су алалар,
Габдрахман тау башына Нәзер корбан чалалар.
Габдрахман коесының төбе тирән, суы күп,
Габдрахман сәхабәнең исеме калган, үзе юк
[Бәетләр, б. 24–25].

Татарстан территориясендә аерым чишмә сулары, бөтен чирләрдән дәва саналса, аерым чишмәләр билгеле бер авыруга шифа бирә дип ышаналар. Мәсәлән, суын күз юар өчен «Күз чишмәсеннән» су алалар.

Изгеләр чишмәләре белән бәйле риваятьләрнең бер төре – аларның килеп чыгышлары, сакральләштерүне канунлаштырса, икенче төр риваятьләрдә бу чишмә сулары ярдәмендә шифа тапкан кешеләр, суның сихри шифалы көче турында. Әлеге төр риваятьләр һәрбер чишмә турында бар, алар хәзерге вакытта да иҗат ителә.

Халык чишмәләрне генә түгел, аерым елга, күлләрне дә изгеләштеррә. Шул ук вакытта халыкның һәрбер сулыкка игътибарлы булуы да мәгълүм.

Татар халкында суны сакральләштерү белән бәйле тагын бер күренеш бар: ул – таң суы алу. Бу эш айның билгеле бер көнендә, иртәнге беренче кояш нурлары су өстенә төшкәндә башкарыла. Бөтен шартлары үтәп алынган «таң суы» кешеләрнең күп чирләрен юып алу көченә ия санала.

Ислам дине тоткан халыклар сакральләштергән тагын бер су бар. Ул Гарәпстан территориясендә Мәккә шәһәре Зәм-зәм коесы суы. Аның суы шифалы һәм

тылсымлы санала. Ул кешеләрне дәвалап кына калмый, рухи яктан да сафландыра. Дини риваятьләр буенча, зәм-зәм суы җәннәттән чыга. Коръән аша таралган легендалар әлеге чишмәне Исмәгыйль пәйгамбәр исеме белән бәйли.

Керәшен татарлары «таң суы» белән беррәттән «кач ману» суын да изгеләштерә. Бу су белән төрле йолалар башкарыла.

Изгеләр чишмәләре, изге елгалар, күлләр буенда төрле йолалар башкарыла. Аларның берсе су буена барып нәзер корбаннары сую, яңгыр боткасы пешерү. Бу йола изге чишмә буенда башкарылган очракта да, ул суны изгеләштерүгә түгел, ә су иясенең күңелен күрүгә кайтып кала.

Татар халкында хәзерге вакытка кадәр Сулыкларны саклау, Су ияләре культы яшәп килә. Су – әдәбиятта һәм фольклорда туган җир символы, чисталык, табигать символы да. Дөньяда гармония суларны саклаудан, су ияләренең тынычлыгын бозмау белән дә бәйле.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.* Түләк һәм Сусылу хакында дастан // Әдәби мирас. Дүртенче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

Башкирский народный эпос. М.: Наука, 1977.

*Госманов М.Г.* Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.

*Дилакторский П.* Из преданий и легенд Кадниковского уезда Вологодской губернии // Этнографическое обозрение. Кн. XLII. М., 1899, № 3.

Козын-Эркеш // Улагашев Н.У. Алтай-Бучай. Ойротский народный эпос. Новосибирск, 1941.

Коран. Перевод смыслов и комментарии Валерии Пороховой. Дамаск – Москва. 1996.

Лунквист А. Воля неба. М., 2003.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюкской письменности. Тексты и исследования. М.– Л.: Изд-во АН СССР, 1951.

Мифы народов мира: энциклопедия в 2-х т. / гл. ред. С.А. Токарев. 2-е изд. М.: Советская энциклопедия. 1 том. 1991. 671 с.; 2 том. 1992.

*Мишель Хоанг.* Чингисхан. Ростов-на-Дону: Феникс, 1997.

Низами. Поэмы и стихотворения. Л., 1960.

*Пиотровский М.Б.* Коранические сказания. М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1991.

*Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки. Л.: Изд-во ЛГУ, 1946.

Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / публикация О.Г. Большакова, А.Л. Монгайта. М.: Гл. ред. вост. лит., 1971.

Рабгузи Насретдин. Кыйссасел Әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003.

Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар / Г. Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.

Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1 том. 1977. 2 том 1978.

Татар халык иҗаты: Бәетләр. Казан: Татар. кит. нәшр, 1983.

Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. Казан, 1987.

*Тукай Г.* Әсәрләр. Биш томда. 1 том. Шигырьләр, поэмалар. Казан, 1985.

*Усманов М.А.* Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972.

*Хисаметдинова Ф.Г.* Мифологический словарь башкирского языка. М., 2010.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы**,*
*филология фәннәре докторы,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*
*ilzakirova@mail.ru*

УДК 94(47)

***Ф.З. Яхин***

# Г. ТУКАЙ «БЕРДӘМЛЕК ҺӘМ ТӘРӘККЫЯТ» КОМИТЕТЫНДА

В статье раскрывается деятельность К.Мутыги в создании им комитета «Единства и Прогресса» в городе Уральске в 1903 году на примере революционной турецкой молодежи. Молодой Г. Тукай стал одним из его активистов. Они организовали периодические органы «Аль-Магариф» («Просвещение») и «Альгасруль-джадид» («Новый век»), которые издавались в рукописной форме. Автор доказывает, что прогрессивные идеи революционной турецкой молодежи Г. Тукаем и его соратниками были приняты с воодушевлением и сыграли огромную роль в формировании их эстетического идеала.

**Ключевые слова:** младотурки, конституция, монархия, парламент, буржуазия, развитие культуры, прогресс, единство, французская литература, турецкая литература, татарская литература, Уральск, рукописные периодические органы.

Уральски чоры Г. Тукайның шагыйрь һәм иҗтимагый фикер иясе буларак танылуында аерым урынны алып тора. Монда «Мотыйгыя мәдрәсәсе»нең, бигрәк тә Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинның роленә аерым тукталып үтү сорала. 1903 елда Каһирәдән Әл-Әзһәр университетын тәмамлап кайткан К. Мотыйгый, «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыту белән генә чикләнмичә, иҗтимагый эшләрен дә киң җәелдереп җибәрә. Әдәбият түгәрәкләре оештыра, кулъязма «Әл-Мәгариф» газетасын даими чыгаруны җайга сала [Яхин, с. 9–52].

Сакланып калган нөсхәләреннән күренгәнчә, бу газета асылы белән «госманлы теле»нчәрәк мәйданга куела. Моның сәбәбе бик гади булган: К. Мотыйгый Әл-Әзһәрдән госманлычага ихластан күңелен салган, шуның белән галимлеккә остарган кеше буларак кайткан. Ул анда начар укымаган. Фәннәрне бик тиз төшенеп, курсларны тиз арада узып, 1900–1903 еллар эчендә тәмам галим буларак җитлегеп өлгерә. Аның әтисе, мәсәлән, Мотыйгулла Төхфәтуллин исә, үз заманында анда 10 ел буена белем алган. Камилгә ул кадәр үк вакыт та кирәк булмаган.

К. Мотыйгый, Уральски шәһәренә кайтып, «Мотыйгыя»да укыта башлауга, шәһәр халкы тормышыннан бер-бер артлы берничә әсәр дә язып өлгертә. Аларны цензура комитетына юллый. Байлар тормышын көлкегә алып тәнкыйтьләүгә багышлаган ул әсәрләренә (асылда аларны тезмә һәм нәсер алымнары белән иҗат итә) басылырга рөхсәт тә ителә, алар дөнья да күрә торалар. К. Мотыйгый шулай төрле яклап танылу ала бара.

Аның иң әһәмиятле эшләреннән берсе — «Бердәмлек вә тәрәккыят комитеты»н оештыруында. «Әл-Мәгариф» газетасы һәм «Мотыйгыя»дагы әдәбият

түгәрәкләре шушы комитетның Уральскидагы эшчәнлегенең нәтиҗәләре буларак та күз алдына килә. Аның эшендә актив катнашкан Г. Тукай исә, К. Мотыйгыйның шәхси секретаре ролен башкара. Кульязма газетаның нөсхәләрен күчерүдә, аны халыкка таратуда Г. Тукайның ролен аз гына да киметергә мөмкин түгел.

«Бердәмлек һәм тәрәккыят комитеты» шәһәрдә мөселманнарны мәгърифәт һәм мәдәни үсеш өчен туплау, конкрет максатлар белән хәрәкәт итүгә юнәлтү белән шөгыльләнә. Әлбәттә, каршылыклар аз булмый. Татар тарихына «җәдит-кадим тартышы» буларак кереп калган, шул кысаларда гына аңлатылган иҗтимагый хәрәкәтләрнең кайсылары асыллары белән төрекләрдәге иҗтимагый-фикри алгарышларга барып тоташуы мәсьәләсе дә фәнебездә әлегә игътибардан читтә кала кебек.

К. Мотыйгый оештырган комитет һәм исеме, һәм җисеме белән «Яшь төрекләр» хәрәкәтенең 1889 нче елдан яшәп килгән «Бердәмлек һәм тәрәккыят комитеты» эшчәнлегенең бер күренеше сыйфатында бәяләнә ала. Алар сәяси, милли, иҗтимагый һәм мәдәни платформалары белән дә туры киләләр. Моны ниндидер бер вакытлы мавыгу, яисә «Яшь төрекләр» хәрәкәтен татар тормышына күчерергә омтылыш буларак кына бәяләргә ярамый. К. Мотыйгыйның, татар тормышы үзенчәлекләрен аңлап, эшен байларга, иске карашларга каршы юнәлдерүенең дә тарихи, сәяси, мәдәни әһәмияте аз булмый.

«Яшь төрекләр» үзләре Төркиядә милли иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрнең башында XIX йөзнең ахырларыннан тора башлыйлар. Алар «Яңа госманнар» сәяси-мәдәни оешмасына алмашка киләләр. Төп максат итеп илдәге монархияне юк итүне куялар. «Яңа госманнар» төрек тормышын европалаштыруда төп эшне башкаралар, илдә конституцион җәмгыять оештыралар, парламент төзеп, буржуазиягә үсеш мөмкинлекләре тудыралар да. Әмма аларның уңышлары озакка бармый [Миллер, с. 45–74]. Башлаган эшләре туктатыла. Җитәкчеләре шагыйрь һәм язучы, актив җәмәгать эшлеклесе, журналист Намык Кемал (1840–1888) кулга алына. Югыйсә, солтан булып, Габдел-Хәмит II (1876–1909) тәхеткә «Яшь госманнар» ярдәме белән утырган була. Ул солтанлык тәхетендә бер ел торырга да өлгерми, «Яшь төрекләр»нең илдә солтан идарәсен юк итәргә җыенуларын ачык төшенеп, аларны эзәрлекли башлый. Үз фәрманы белән Н. Кемалны зинданга салдыра, илдә яңа идарә юк ителә, тирания урнаша һәм «золым дәвере» башланып китә. Солтан Габдел-Хәмит II төрек байлыгына кызыккан чит илләрнең тыкшынуыннан мәмләкәтне коткаруның башка юлын күрми. Әмма бу, аның сайлаган юлы, шулай ук уңышлы булмый. 1882 нче елда Франция Тунисны яулый, 1882 нче елда Бөекбритания Мисырны басып ала. Болар гына да түгел, чит илләрнең тыкшынуы Төркия казнасына, гаскәрләренә үтеп керә. Шушы вакытта Габдел-

Хәмит II дини дошманлык идеясен таратуга зур ышаныч баглый башлый. Бу юлда эш җәелдереләп, халыкларга каршы халыклар куела [Алиев, с. 29–56]. Җәмгыятьтә оешкан милли прогрессив көчләрне юкка чыгару, сәяси хәрәкәтләрне бастыру һәм таркату, европалашуга каршы сәяси, иҗтимагый, икътисади, әхлакый һәм башка һәртөрле көчләрне туплау эше оештырыла. Милләтчелек һәм мөселманчылык идеяләре солтан тарафыннан иң уңай һәм үз сәясәтен ныгытуда яраклы дип табылалар.

Болар вакытлы күренеш кебек күзалланырга тиеш түгелләр. Әмма «Золым дәвере» төрекләрнең аңлы милли-мәдәни көчләренә зур зыян сала. Әдәбиятта төп геройның «үз эчке дөньясына качуы» тасвирлана башлый. Габделхак Хәмит Тархан (1852–1937), Риҗаизадә Әкрәм (1847–1913) романтик хисләр дөньясына бирелергә мәҗбүр булалар. Әмма европачылык һәм Европа әдипләренең тәэсирләреннән дә читләшмиләр. В. Гюго, А. Ламартин, А. Мюссе кебек романтик шагыйрьләрнең шигъри мотивлары төрек әдәбиятында актив чагылыш таба.

Алдынгы төрек әдипләре «Сәрвәти-фөнүн» журналы тирәсенә тупланалар. Төрек әдәбиятында заманча «яңа әдәбият» шул шартларда формалаша. Төрек укучысына Э. Золя, Г. Мопассан, бертуган Гонкурлар, Стендаль, О. Бальзак иҗатлары киң пропагандалана. Төрек шагыйре Тәүфыйк Фикрәт (1867–1917) иҗаты активлашып китә. Ул гади халыкның хис-тойгыларын ихлас буларак сурәтләүне, гражданлык пафосларында иҗат итүне төп юнәлеше итеп куя. Җәдитчелек юнәлешен тоткан яңа тип татар әдәбияты да шушы ук төрек әдипләре әсәрләре йогынтысын кичерми калмаган.

Бу яктан караганда, К. Мотыйгыйның әсәрләре дә тулы канлы гражданлык хисләренә бай булулары белән үзләренә укучыны җәлеп итәләр. Т. Фикрәт һәм К. Мотыйгый иҗатлары арасында охшаш һәм уртак мотивларны табуы авыр түгел. XIX йөзнең икенче яртысында, бигрәк тә соңгы чирегендә төрек прозасында үзәккә чыгарылган «кечкенә кеше язмышын» «тулы канлы» итеп сурәтләү соңрак та татар әдәбияты үсешенә шактый зур этәргеч биргән. Төрек әдипләре мәгърифәт һәм тәрәккыят идеалларын югары күтәрәләр, әсәрләрен иҗтимагый эчтәлеккә коралар, психологизмга зур игътибар бирәләр, француз натуралистлары йогынтысында язалар. Тормыш материалын әдәби әсәр вакыйгасына әверелдерү алымнарын К. Мотыйгый татар әдәбиятында уңышлы башкарган, Г. Тукайга да аның иҗат манералары тәэсир итми калмаган.

«Яңа госманнар» эшен дәвам иттерүче «яшь төрекләр» хәрәкәте вәкилләренең ахырда милләтчелеккә бирелеп китүләре, сәяси мәсьәләләрне милли мәнфәгать кысаларына кайтарып калдырулары XX йөз башы татар әдипләрен берникадәр аптыраштта калдырган, билгеле. Хәер, анысы башка мәсьәлә.

Г. Тукайның Уральски чорында язылган мәкалә-фельетон-

нарында «яшь төрекләр»нең фикри тәэсирләре нык сизелә. Аның «Кавказ тормышыннан» дип күрсәтелгән «Ай, бат!» (1907) хикәясе дә моны ачык күрсәтеп тора.

К. Мотыйгый оештырган Комитетның алга таба булган язмышы аерым әһәмияткә ия. Кульъязма газетадан кульъязма «Әлгасрелҗәдид» («Яңа гасыр») журналына, аннары басма журналга күчеп, алар Рәсәйнең эчке сәяси-иҗтимагый хәрәкәтләренә кушылып китәләр. Сайлауларда эре буржуаз партияләрнең мәнфәгатьләрен яклаучылар буларак та үзләрен күрсәтәләр К. Мотыйгый оештырган «Әлгасрелҗәдид» журналы һәм «Фикер» газетасы.

Г. Тукайның гражданлык пафосы белән сугарылган беренче шигырьләре һәм мәкаләләре дә шул матбугат органнарында дөнья күрә. Шунысы мактауга лаек: ул илдә, җәмгыятьтә, татар эчендә гаделлек урнаштыру юлларын эзләвен, сәяси дөрес юлны ачыкларга омтылышын туктатмый. Бу яктан аның аңы бик яшьли ачыла. Монда К. Мотыйгыйның һәм ул оештырган Комитетның роле зур булган, билгеле.

1905 нче елда алар Русиянең әүвәле конституцион-демократия тарафдарларына ияреп китәләр, ә 1906 нчы елның урталарыннан алдынгы революцион партияләр ягына тартылалар. Бу инде К. Мотыйгыйның да, Г. Тукайның да «яшь төрекләр» платформасыннан китү юлына керүләре хакында сөйли торган фактлар буларак бәяләнергә тиеш. Әмма ул процесс та күп төрле фикри, иҗтимагый, сәяси, әхлакый эзләнүләр белән озатылып барылган. Халык алдында, җәмгыять каршында олы җаваплылык тоеп эш итүләре аларның әдәби-журналистик эшчәнлегендә, мәкаләләрендә, язган әсәрләрендә чагылыш тапкан. Бу яктан Г. Тукай иҗаты шактый өйрәнелгән, К. Мотыйгыйның әсәрләре бүгенге җәмәгатьчелектән әлегә читтә калып килә. Бу юлда эшлиселәребез бар әле.

**Әдәбият**

*Алиев Г.З.* Турция в период правления младотурк (1908–1918 гг.). М.: Наука, 1972.

*Миллер А.Ф.* Турция. Актуальные проблемы новой и новейшей истории. М.: Главная редакция восточной литературы изд-ва «Наука», 1983.

*Яхин Ф.З.* Татарская литература в периодической печати Уральска (1905–1907 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1991.

***Яхин Фәрит Зәкиҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге мөдире*

УДК 94(47)

***Р.Г. Галләм,***
***Л.И. Фидаева***

# ТУКАЙ ТУГАН АВЫЛ
## (Кушлавыч авылы тарихыннан сәхифәләр)

В данной статье описывается история деревни Кошлауч – родина классика и литературного гения Г. Тукая. Работа интересна тем, что приведенные исторические факты автор подтверждает документально.

**Ключевые слова:** деревня Кошлауч, история деревни, Казанское ханство, документы, топонимика.

Кушлавыч – тар инеш тарафыннан ашалып ясалган тирән уйсулыкның ике ягына бүленеп урнашкан авыл. Озак еллар Тукайлар шәҗәрәсен бөртекләп торгызган Зәкия ханым Рәсүлева үзенең «Тукай эзләреннән» (Казан, 1985) дигән китабында Кушлавыч авылын болай сурәтли: «Кушлавыч... Казаннан 60 чакрым ераклыкта киң иңкүлеккә урнашкан авыл... Мари ягыннан килеп, куе Илләт урманнары аша салынган олы юл, авылның югары очыннан түбән очына кадәр үтеп Кушлавыч, Җөлби авыллары аша Казанга юнәлә.

Тирә-якта кайсы якында, кайсы шактый ук еракта шундый ук башка авыллар арасында Ямаширмә, Сәрдә, Наласа, Өчиле, Кырлай, Масра, Кышкар, Каенсар авыллары сибелгән».

Кушлавыч авылы торгынлык елларында, чын мәгънәсендә, үзенең бөек улы язмышына дучар булды. Тукайга багышлап уздырылган төрле шау-шулы бәйрәм чаралары авылны читләтеп уза тордылар. Ә авыл үзе исә бетүгә табан юл тоткан иде. Куанычлы бер күренеш буларак, соңгы дистә елларда хәл уңай якка үзгәрде. Милли үзаң уяна башлауның, тәрәккыятнең җылы җилләре Кушлавыч авылын да читләтеп узмыйча, аның яшәү көченә, якты киләчәгенә өметне арттыра төштеләр. Хәзерге вакытта Татарстаннның Арча муниципаль районына караган Кушлавыч авылында алтмышка якын хуҗалык исәпләнеп, ул якындагы Иске Җөлби авылы белән берлектә, Кушлавыч авыл советын тәшкил итә. Авылның үзендә балалар бакчасы, башлангыч мәктәп, мәчет, мәдәният йорты, Габдулла Тукайның музей-йорты, азык-төлек кибете эшли.

Казан артындагы күпсанлы эреле-ваклы авыллар арасында Кушлавыч үзенә аерым бер урын алып тора, чөнки ул дөньяга татар халкының бөек улы Габдулла Тукайны биргән авыл. Шагыйрьнең этисе Мөхәммәтгариф мулла ягыннан җиде буын бабасы да Кушлавыч авылында гомер кичергәннәр. Шунлыктан, табигый ки, Казан артында Тукай биографиясе, шәҗәрәсе белән бәйле башка күп кенә авыллар тарихы шикелле үк, Кушлавыч авылы-

ның күпгасырлык үткәне һәрьяклап җентекләп өйрәнүгә лаек. Гәрчә бу авылларның барысының да диярлек тарихы әлегә аз өйрәнелгән килеш кала бирә.

Кушлавыч авылыннан чыккан язучы Әнәс Галиевның әтисе Касыймнан язып алып калган мәгълүматлар буенча, авылга нигез Казан ханлыгы урыс гаскәрләре тарафыннан басып алынган чорда, ягъни XVI йөзнең 50 нче елларында салынган. Рәхимсез сугышта исән калган бер төркем кешеләр бу җирләргә килеп утырганнар. «Башта Мичкә бите тигән җирдә – инеш буенда яр кырыенда куыш (землянка. – *Р.Г.*) ... казып яшәгәннәр... Кайсы авылдан, дип сораучыларга, Куышлы авылыннан, дип җавап бирә торган булганнар. Тора-бара исем Кушлавычка әйләнеп киткән. Бераздан хәзерге урынга, җайлырак җиргә күчеп утырганнар. Исем үзгәртелмәгән» [Галиев, 1996].

Әлбәттә, бу мәгълүмат игътибарга лаек. Ләкин шуны да искәртеп үтәргә кирәк, хәзерге вакытта Кушлавыч исемле авыл Татарстанда гына түгел, бәлки Чуваш Республикасында да бар. Җирле риваятьләргә караганда, бу чуаш халкы монда XVI йөзнең икенче яртысында – XVII йөз башында хәзерге Татарстанның Тау ягыннан күченеп килгән. Үз чиратларында, чуашлардан булган тел галимнәре «Кушлавыч» топонимын «Наратлы урын» («Нарат урманы») мәгънәсендә аңлаталар. Шул ук вакытта, XIX йөздә яшәгән урыс тарихчысы И.А. Износков авыл исеменең килеп чыгышын кышлый торган урын (кышлау) белән бәйли [Износков, с. 3]. Шул рәвешле, бүгенге көндә «Кушлавыч» атамасын төрлечә аңлатучы фаразлар яшәп килә. Тик шулай да, топонимның тамырында «куыш» яисә «кышлау» сүзләре ята булса кирәк. Чөнки бу якларда кайчан да булса чуаш халкы вәкилләренең яшәве мәгълүм түгел. Димәк ки, авыл исемен «кышлау урыны» яисә «куышлы (землянкалы) урын» мәгънәсендә аңлату дөресрәк булыр (мисал өчен, «Салавыч» – сала, авыл урыны яисә сала, авыл урнашкан урын).

Югарыда китерелгән риваять Казан артындагы Кушлавыч авылының барлыкка килүен рус дәүләтенең Казан ханлыгын басып алуы белән бәйли. Ләкин чынлыкта авыл, күрәсең, Казан ханлыгы чорында ук булган. Мәсәлән, XVI йөз ахыры – XVII гасыр башына караган җир-йорт теркәү кенәгәләренә (писцовый кенәгәләргә) нигезләнеп, тарихчы-галим Е.И. Чернышев Кушлавычны Казан ханлыгы авыллары исемлегенә кертә [Чернышев, с. 286]. Гомумән алганда, хәзерге Кушлавыч авылы XVI гасыр урталарыннан да калмый оешкан дип ышанычлы рәвештә тәкърарларга була.

Күрәсең, ул чорларда авыл халкын ясаклы игенчеләр тәшкил иткән. Чөнки Казан өязенең 1602–1603 елларга караган җир-йорт теркәү кенәгәсендә Кушлавыч авылы күрсәтелми. Ә ул исә йомышлы татарлар (казаклар) яшәгән авылларны гына исәпкә алып, ясаклы игенчеләрдән генә торган авылларны игътибардан читтә калдыра [Писцовая книга Казанского уезда...].

1742 елда Казан өязе Алат даругасының (өлкәсенең) Мәмеш улы Ярмәк йөзенә (сотнясына) караган 45 хуҗалыклы Кушлавыч авылындагы мәчетнең гаскәриләр ярдәмендә тирә-яктагы татар-мөселман халкын көчләп христиан диненә чукындырырга тырышып йөргән чиркәү әһелләре тарафыннан җимертелүе турында хәбәр сакланган (ул елларда, гомумән, Казан өязендәге мәчетләрнең 2/3 е диярлек җимерттерелә). Шунысы да кызык, попларның «мәчетегез кайчан төзелгән?» дигән сөаленә авыл халкы «хәтерләмибез» дип җаваплый. Димәк ки, ул мәчет күптән торгызылган булып чыга.

1760 нчы еллар башында узган III ревизия (халык санын исәпкә алу) нәтиҗәләрен чагылдырган «Казан наместлыгы турында документларда» үзара бер-берсенә терәлеп үк диярлек урнашкан (чыганакта «шунда ук» дип күрсәтелгән) ике «Кушлавычны» теркәп калдырган. Аларның берсе чыганакта «деревня Кошлауш, при ключах» (ягъни, чишмәләр буена урнашкан Кушлавыч) дип бирелсә, икенчесе «починок Кошлауш» (Кушлавыч пүчинкәсе) дип бирелгән. Икесенең дә халкы йомышлы татарлардан торып (күрәсең, бу вакытта алар лашманчылыкта булып, Казан адмиралтействосы өчен урман кисү эшләренә дә җәлеп ителгән), беренчесендә 89, икенчесендә 18 (барлыгы 107) ревизия җаны теркәлгән [Казан император университеты каршындагы.., с. 249]. Күрәсең, бу ике Кушлавычны бары тик Сәрдә елгачыгы гына аерып торып, асылда монда сүз бер үк авыл турында бара.

Авылның «пүчинкә» өлеше монда соңрак күчеп чыккан кешеләр тарафыннан оештырылган булса кирәк. Чөнки «починок» дип, гадәттә, кайсы да булса авылдан аерылып башка чыккан кечерәк, яңа саланы атаганнар. Кушлавыч пүчинкәсендә янәшәдәге, «чишмәләр буендагы» Кушлавычка караганда кешенең күпкә азрак яшәгән булуы да беренчесенең чагыштырмача яңарак корылган булуы турында сөйли. Ә инде XIX гасырдан башлап, тарихи чыганаклар Кушлавычны икегә аермыйча, бер авыл итеп күрсәтәләр.

Мәгълүм булганча, Габдулла Тукай Кушлавыч авылында 1886 нчы елның 26 нчы апрелендә аваз салган. Бу вакытларда Уржум сәүдә тракты буена утырган авыл Казан губернасы Казан өязенең Олы Мәңгәр волостена караган. Халкы Кушлавыч авыл общинасын (җәмәгатен) тәшкил итеп, аның карамагында 1260 дисәтинә ( 1 дисәтинә 1,1 га чамасы) җир исәпләнгән. Ул җирләр «Мәңгәр һәм башка авыллар» дип аталган җир «дачасына» (җир биләмәсенә) караган.

Авылда 120 хуҗалык булып, аларда 411 ир-ат, 383 хатын-кыз (барлыгы 794 кеше) теркәлгән. Шулардан 14 ир-ат, 11 хатын-кыз, чынлыкта, башка авылларда яшәгән. Моннан тыш, 10 ир-ат, акча эшләү максаты белән, озак вакытларга авылдан читкә чыгып китә торган булган. Кушлавычта башка авылда (авыл общинасында) теркәлгән 2 ир-ат, 3 хатын-кыз да гомер кичергән

(мөгаен, алар авылга яңарак күченеп килгән булган). Бу вакытта авылда 8 ир-ат, 8 хатын-кыз (барлыгы 16 кеше) исәбендә мөселман руханилары гаиләләре дә теркәлгән. Болар исәбенә Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф мулла гаиләсе дә керә.

Авыл халкының төп шөгыле игенчелек һәм, шулай ук, терлекчелек, кош-корт асрау булган. 2 хуҗалык умарталар тотып, алардан 60 сумлык еллык керем алган. 2 ир-ат һөнәрчелек (күрәсең, тимерчелек) белән көн күргән. Моннан тыш, авылда бер вак сәүдәгәр дә булып, ул сәүдәдән елына 50 сум табыш ала торган булган. Тулаем алганда, авыл халкының матди хәле уртача булган («живут посредственно») [Износков, с. 3].

Гадәттәгечә, ул вакытларда волость идарәсе белән эшне авыл җәмәгате сайлап куйган староста (авыл старостасы) алып барган (аның үз мөһере дә булган). Авыл тормышына бәйле барлык әһәмиятле мәсьәләләр – үзара җир бүлешү, мәчет төзү, уракка төшү, чәчүгә чыгу мәсьәләләре, башка шундый мәсьәләләр – алар барысы да җәмәгать (авыл җәмәгате) җыенында, ягъни, мир җыенында хәл ителгән.

XX гасыр башына күз салсак, 1908 елда Кушлавычта мәчет, ибтидаи (башлангыч) мәктәп (мәдрәсә), 2 азык-төлек, вак-төяк тауарлар кибете, җил тегермәне, тимерче алачыгы 2 «постоялый двор» (ягъни, кунак-җитем кабул итү йорты), 1 «пожар машинасы» (әлбәттә, монда сүз атлы машина турында бара) теркәлгән [Описание Казанской губернии, с. 50–51].

Бу вакытларда авылга иң якын телефон станциясе, телеграф-почта бүлеге 21 чакрым, табиб фатиры – 25 чакрым, ветеринария табибы – 21 чакрым аралыкта була. Шул рәвешле, авыл халкына боларның барысы белән файдалану читен була.

Тик бернигә дә карамый, Кушлавыч авылы XVIII–XIX гасырлар дәвамында үсеш кичереп, XX гасыр башында анда халык саны берникадәр тотрыклана. Күрсәтелгән чорларда авылда халык санының үсеш динамикасын түбәндәге таблица рәвешендә дә күзәтергә була:

| Еллар | Ир-атлар | Хатын-кызлар | Барлыгы | Хуҗалык саны |
|---|---|---|---|---|
| 1760 нчы еллар башы (III ревизия) | – | – | 107 ревизия җаны | – |
| 1856 (X ревизия) | 350 | 338 | 688 | – |
| 1885 | 441 | 383 | 794 | 120 |
| 1897 | 420 | 429 | 849 | – |
| 1908 (1 нче гыйнварга) | 398 | 400 | 798 | 130 |

Шулай итеп, XX йөз башында Кушлавыч авылы 130 хуҗалыгы булган, 880 гә якын кеше яшәгән, үзенең мәчете, мәктәп-мәдрәсәсе, тегермәне, һөнәрчеләре, вак сәүдә кибетләре булган, аякка шактый нык баскан бер авыл – башка шундый йөзләгән авыл-салалар шикелле үк, Казан артындагы гадәти бер татар авылы булып күзаллана.

**Әдәбият**


*Галиев Әнәс.* Үги итмик // Ватаным Татарстан. 1996. 4 нче апрель.

*Износков И.А.* Список населенных мест Казанского уезда. Казань, 1885. XV, 3 б.

Казан император университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре. XVIII том. 4–6 чыгарылыш. 249 б.

Описание Казанской губернии. Казань, 1908.

Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов / сост. Р.Н. Степанов. Казань, 1978.

*Чернышев Е.И.* Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. Казань, 1971. Б. 272–292.



***Галләм Рәшит Габделфәрт улы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

***Фидаева Лилия Илдус кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан дәүләт медицина университеты доценты*

УДК 821.512.145:372.8

***Э.М. Галимҗанова,***
***Ф.Г. Фәйзуллина***

# Г. ТУКАЙНЫҢ «МӘКТӘПТӘ МИЛЛИ ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ» ТӨРЛЕ БАСМАЛАРДА

В данной статье рассматривается сборник-хрестоматия «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» («Уроки национальной литературы в школе»), составленный Г. Тукаем. Дается сравнительно-сопоставительный анализ трёх его изданий (1911, 1918, 1919 гг.).

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, педагогика, татарская литература.

Башлангыч сыйныфлардан ук, укучыларны үз халкының теле, әдәбияты, рухы белән таныштырып, матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләргә кирәклекне күздә тотып, Габдулла Тукай милли әдәбияттан укытырлык дәреслек төзергә алына. 1909 елда басылган «Яңа кыйраәт» китабы бу юнәлештә башкарылган эшләрнең тәүгесе булса да, анда Г. Тукайның үз әсәрләре һәм тәрҗемәләре генә булганга, ул әле әдәбияттан дәреслек ролен үтәрлек дәрәҗәдә булмый. 1911 елда дөнья күргән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» бу өлкәдә аеруча әһәмияткә ия хезмәт.

«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»ндә «Яңа кыйраәт»тә булганы кеби мәгълүм бер максат вә мәсләк тотылмаса» [1, IV] да, җыентык тематик яктан киң булуы белән аерылып тора, монда автор-язучыларның да күп булуы күзәтелә. Г. Тукай китапка 26 язучының әхлак-тәрбия мәсьәләренә караган, табигатьне тасвирлаган, халкыбыз, илебез тарихын яктырткан әсәрләрен, халкыбыз җәүһәрләреннән үрнәкләр урнаштырган. Шулай ук балаларны рус әдәбияты белән таныштыру максатыннан хезмәткә В.В. Радловның ике әсәрен керткән.

Җыентыктагы әсәрләр «педагогиканың» җиңелдән – авырга кагыйдәсене бераз игътибарга алынып, китапның башына аңлавы җиңел, садә гыйбарәле шигырьләр вә кыйтгалар куелып» [1, IV], авыррак әсәрләр мөмкин кадәр арткарак урнаштырылган.

Әдәбияттан дәреслек-хрестоматия итеп төзелгән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» җыентыгының өч басмасы бар. Беренчесе Г. Тукай үзе исән вакытта 1911 елда басылган (Казан, нашире «Мәгариф» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы); икенчесе – 1918 елда (Казанда «Мәгариф» китапханәсе, «Мәгариф» матбагасы), өченчесе 1919 елда (Казанда «Мәгариф» китапханәсе, «Мәгариф» матбагасы) дөнья күргән.

«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» совет чорында дөнья күргән томлыкларның берсендә дә урын алмаган. Сәбәбе җыен-

тыкка Фатих Кәрими, Шәһретдин Шәрәф кебек репрессия корбаннары, Гаяз Исхакый, Муса Бигиев, Садри Максуди, Габдерәшит Ибраһимов кебек эмигрант язучыларның әсәрләре кертелгәнлектән булса кирәк.

Җыентык беренче тапкыр Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать Институты тарафыннан әзерләнгән Г. Тукай «Әсәрләре»нең алтытомлы Академик басмасының VI нчы томына урнаштырылды. Җыентыкта шагыйрьнең шактый гына үз шигырьләре дә бар. Дәреслек төзү принципларын күзаллау максатыннан, җыентык тулысы белән, бербөтен итеп бирелде.

Китапның Тукай үзе исән вакытта һәм вафатыннан соң дөнья күргән басмаларын чагыштырып караганда, алар арасында шактый гына аермалыклар булуы күзәтелә. 1911 елгы басмага кертелгән кайбер әсәрләр калган басмаларда бөтенләй төшереп калдырылганнар. Шәһретдин Шәрәфетдиневнең 1909 елны Казанда басылган «Гасры сәгадәт» әсәреннән алынган «Гасры сәгадәт», «Шамаиле шәрифә» өзекләре белән бергә бирелгән «Җаһилияте заманы» 1919 елгы басмада юк. Әлеге өзектә гарәпләрнең Ислам дине кабул иткәнче булган тәртипсез тормышлары тасвирланган. Гарәпләрдә булган начар гадәтләрне, бозыклыкларны тасвирлаган өзекнең төшеп калуы, әлбәттә, очраклы гына түгелдер. Бәлки мондый әсәрнең укучы бала күңелендә нәфис хисләр уятудан бигрәк, анда сурәтләнгән вакыйгаларның куркыныч булуындадыр. Шулай ук кайбер әсәрләрдә аерым җөмләләрнең генә кыскартылуы да күзәтелә. Мәсәлән: «Шәмаиле шәрифә»дә түбәндәге: *Аллаһының тугры адымнарга ярдәмче икәненә кямил инанган иде. Өхед, Хөнәйн сугышларында сахабәләр куркып таралып киткәндә, асла урыныннан да кузгалмай тормыш иде* җөмләләре киселгән [1, 57.]

Йосыф Акчураның Галимҗан әл-Барудиның балалык елларын, мәдрәсәдә укыган чорын тасвирлаган «Мелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләренең сабыйлык вакытындан» исемле әсәре дә соңгы басмаларга кертелмәгән.

Эчтәлек ягыннан да, мәгънә ягыннан да бик үк әһәмияткә ия булмаган әсәрләрдән Хуҗа бине Габделбәдыйгнең «Аһ насыйбмы башмагым?!» исемле югалган башмагына мәрсиясе, Сәгъдинең аңа җавап рәвешендә язылган «Ни чара?» исемле шигыре дә 1918-1919 елгы басмаларда юк. Каюм Насыйри төзегән «Фәвакиһелҗөласа фил-әдәбият» («Әдәбият турында әңгәмәләр җимеше») исемле җыентыктан «Чәйнең шартлары» исемле өзекне, Габделшәкүр Әминевнең «Әдәбият» капчыгыннан алынган» «Ярдәм, ярдәм!» әсәрен, Габдерәшит Ибраһимовның тәрбияви яктан шулай ук мөһим булмаган «Янчы, яхшы урманым!» исемле әсәрләрне дә (1919 елгы басмада) наширләр кирәксез тапканнар.

М. Гафуриның «Электр фонаренә хитаб» шигыренең соңгы

өч куплеты да 1919 елгы басмада төшерелеп калдырылган.

Соңгы басмаларда наширлар тарафыннан Тукай әсәрләренә милли төс бирергә тырышу да күзәтелә. Мәсәлән, 1911елгы басмага Г. Тукай А.С. Пушкинның «Сказка о золотом петушке» хикәясеннән алынган «Хикмәтле әтәч» әсәрен урнаштырган. Әлеге әсәрдә Мәмәт атлы Хират ханы тирәсендә барган вакыйгалар сурәтләнгән. 1918, 1919 елгы басмаларда, вакыйгалар үзебезнең җирлеккә күчерелеп, Мәмәт атлы Хират ханы Гәрәй атлы Казан ханы дип бирелгән, диңгез исә Идел елгасына әйләндерелгән.

Соңгы ике басмада җөмләләрне стилистик яктан шомарту очраклары да күзәтелә. Мәсәлән: *«Мәктәпдә милли әдәбият дәресләре» кеби олуг бер китап мәйданга куярга мөмкин икәнен күргәч...* җөмләсендәге *китап* [1, II] сүзе 1918–1919 елгы басмаларда *китапны* дип үзгәртелгән [2, I], [3, I] *«Татарда тел юк, әдәбият юк» диюче мөтәгассыйбларны (искелек яклыларны, фанатикларны) (бөтен мәгънәсе илән) кызгандым* җөмләсе [1, II] *«Татарларда тел юк, әдәбият юк» диюче мөтәгассыйбларны (бөтен мәгънәсе илән) кызганам* формасында бирелгән [2, I], [3, I]; *Яшь балаларның илә мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән* җөмләсендәге *илә* сүзе *иң* белән алыштырылган [1, 4]; *Мин анда чыгып, адашып, куркып* җөмләсендәге *адашып* [1, 10] сүзе *адашудан* формасын алган. *Шулай мәшәкатьләнә торгач, Кырлай исемле бездән җиде генә чакрым авылдан Сәгъди исемле бер ир баласыз кеше килеп, мине үзенә алып киткән* җөмләсе [1, 8] *Шулай мәшәкатьләнә торгач, бездән җиде генә чакрым Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди исемле бер кеше килеп, мине үзенә алып киткән* дип шомартылган [2, 12], [3, 12].

Басмаларда шулай ук җөмләләргә үзгәреш кертү сәбәпле мәгънә үзгәреше барлыкка килгән урыннар да очрый. Мәсәлән: «Мөкаддимә» өлешендә Г. Тукай: *«Моның кирәклеге фикере аңлы мөгаллимләремезнең башында эшләнеп чыгып, андан милли гәзитәләремез сәхифәләренә дә гакес иткән иде (чагылган иде)»,* – дип язган булса [1, I], соңгыларында: «*Моның кирәклеген фикерле, аңлы мөгаллимләремезнең башында эшләнеп чыгып, андан милли гәзитәләремез сәхифәләренә дә гакес иткән иде»,* – дип бирелгән [2, I ], [3, I]. *«Мәгъсум, бераз юынды, сабакдашларындан яхшырак киемләр алып килде, анасы янына барды»* [1, 19] җөмләсендәге *килде* сүзенең *киде* [2, 21], [3, 21] сүзе белән алышынуы җөмләгә икенче мәгънә төсмере бирә.

Г. Тукай үзе бастырган 1911 елгы басмага кергән әсәрләрне чыганаклары белән чагыштырып чыккач та, кайбер кызыклы үзгәрешләрне күзәтергә мөмкин. Тукай әлеге әсәрләрдәге чит телләрдән: гарәп, фарсы, төректән кергән сүзләрне, балаларга аңлаешлырак итәргә теләп булса кирәк, татар формалары белән алыштырган. Мәсәлән: *лязем – кирәк, сәнә – ел* һ.б.

Шулай итеп, «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең төрле басмаларын чагыштырып караганнан соң, соңгыларында (1918, 1919) совет хакимияте идеологиясенең әкренләп әдәбиятыбызга, мәдәниятебезгә үтеп керә баруы күзәтелә, чөнки әлеге басмаларда без шул чор өчен әһәмияте булмаган, күбрәк дин белән бәйле әсәрләрнең кыскартылуын күрәбез. Шуңа күрә дә Тукайның алтытомлык «Әсәрләр»енә үзе исән вакытта чыккан басмасы (1911) урнаштырылды.

**Әдәбият**


1. *Тукаев Габдулла.* Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: Үрнәк, 1911. 144 б.
2. *Тукаев Габдулла.* Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: Мәгариф, 1918. 120 б.
3. *Тукаев Габдулла.* Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. Казан: Мәгариф, 1919. 112 б.



***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145:398

*Х. Ярми*

## ТУКАЙҺӘМ ХАЛЫК ИҖАТЫ

Статья ученого-фольклориста, Заслуженного деятеля науки ТАССР Х.Х. Ярмухаметова (Хамита Ярми) анализирует влияние татарского фольклора на вторчество Г. Тукая. Поэт широко использовал в своей поэзии и публицистике образы народной литературы, музыки, пословиц и т.д., что не только обогатило его творчество, но и сделао воистину народным. Впервые статья была опубликована в сборнике "Габдулла Тукай: материалы научной сессии, посвщенной 60-летию со дня рождения поэта" в 1946 г. Текст публикуется без изменений.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, татарский фольклор, народные песни, сказки, народная музыка, литературные традиции.

Тукай үз иҗатының идея һәм художество байлыгын көчәйтүгә, бер яктан, бөек рус әдәбиятын өйрәнү, аннан үрнәк алу юлы белән килсә, икенчедән, халыкның иң яхшы сыйфатларын, иң бөек хисләрен чагылдырган халык аваз иҗатыннан да нык файдаланды. Ләкин шул ук вакытта Тукай фольклорга тәнкыйтьсез баш июдән ерак торды. Ул фольклор материаллары арасыннан халыкның иң прогрессив идеяләрен, киләчәк турындагы якты өметләрен чагылдырган өлешен сайлап ала белде һәм демократик теләкләрне тормышка ашыруда аннан тиешенчә файдалануны төп бурычы итеп куйды. Тукай шигырь һәм поэмаларының бик күп өлешен халык иҗаты стилендә, халыкка аңлаешлы телдә язды. Менә шуның өчен дә: *«Халык җырларындагы төп аһәң,* – ди Фатих Әмирхан, – *кайгы, хәсрәт, авыр моң аһәңе аның шигырьләрендә төп көй әсасы иде. Менә шуңа күрә халык аны бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды. Аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды. Менә халыкның шул тойгысы Тукайның тормышында бердәнбер таянычы, бердәнбер газасы иде»*[1].

Тукайның халык иҗаты белән кызыксынуы, аерым әсәрләрен халык иҗаты мотивлары нигезендә язуы һәм, гомумән, аның фольклорга карашы турында матбугатта, революциягә хәтле дә һәм революциядән соң да, төрле-төрле фикерләр әйтелде. Ләкин бу тикшеренүләрнең иң зур күпчелеге Тукайның фольклор белән кызыксынуына гомуми бер караш ташлау төсендә генә барды. Тукайның халык иҗаты материалларын системалы рәвештә өйрәнүе, аны туктаусыз җыйнавы, бигрәк тә аны нинди принциплардан чыгып җыйна-

[1] Ф.Әмирхан // «Кояш» газетасы. 1913. № 88.

вы, Тукайның татар фольклористикасы өлкәсендә бездә беренче буларак кыйммәтле теоретик фикерләр әйтүе кебек мәсьәләләр ничектер тиешле рәвештә яктыртылмады. Шагыйрьнең фольклор стилендә язылган шигырьләренең төп чыганакларын билгеләү, аерым шигырьләренең төп чыганакларын билгеләү, аерым шигырьләренең халык поэзиясе стиленә якын булуын ачу кебек мәсьәләләр хәзергә хәтле тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәделәр.

Шуның белән бергә, Тукайның фольклорга мәхәббәт белән каравын, аның фольклорга якын торуын шагыйрьнең фәкать биографик моменты белән генә бәйләп тикшерү, аның халык иҗаты белән кызыксынуын фәкать аның авылда туып үсүе белән генә чикләп калдыру кебек күренешләр дә булды. Билгеле, Тукай революциягә хәтле булган караңгы татар авылында туып үсә һәм үз яшендәге балалар, әйләнә-тирәсендәге зурлар тарафыннан җырланган төрле җырлар, әкиятләр аның яшь күңелен дулкынландыралар. Авыр тормышта кайгы-хәсрәт, моң-зар белән яшәгән халыкның җырлары яшьтән үк үз әйләнә-тирәсен аңлап белергә омтылган Тукай күңеленә тиз кереп урнаша. Тукайда гомумән халык иҗатына, бигрәк тә халык җырларына зур мәхәббәт туа. Мәктәп яшеннән үк халык телендә йөргән җырлар, бәетләрне оста, сокланырлык итеп җырлап бирә алу белән бергә, үз әйләнә-тирәсендәге вакыйгалар, төрле кызыклы хәлләр турында ул үзе дә җырлар һәм бәетләр чыгара башлый.

Халык аваз иҗаты киң тамыр җәйгән авылда үсүнең Тукай иҗатына билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясавы һичшиксез. Ләкин Тукайның зур иҗаты турында, аның фольклор белән кызыксынуы, аны җыйнавы, татар фольклористикасы өлкәсендә кыйммәтле фәнни хезмәтләр калдыруы турында сүз барганда, аның бу өлкәдәге хезмәтләрен бары тик биографик моменты белән генә чикләп калдыру дөрес булмас иде.

Тукайның халык иҗатын чын күңелдән яратуын, аны туктаусыз өйрәнүен аның иҗтимагый позициясеннән чыгып карарга кирәк. Тукай 1905 ел революциясе тарафыннан күтәрелгән шагыйрь буларак, беренче буржуаз революция куйган таләпләрне көчәйтерлек, пропагандаларлык фикерләрне халык иҗатыннан табып, шуларны классик югарылыгына күтәрә, фольклор нигезендә ул халыкка аңлаешлы, аңа якын һәм аны дулкынландырырлык әсәрләр тудыра. Тукай сәнгатьнең халыкчанлыгын аңлап эш итә һәм аның халык иҗатына тирән мәхәббәт баглавы шагыйрьнең эстетик һәм политик принциплары белән бик нык бәйләнгән.

Халык җырларына бәя биреп, Тукай: «*Халык җырлары бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу кадерле мирас, кыйммәтле мирас!.. Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә, аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска, иҗтиһат итәргә кирәк.*

*Белергә кирәк ки, халык җырлары халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер. Бу бертөрле сихерле көзгедер. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын, вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр»*[2], – ди.

Күренә ки, Тукай халык җырларына, гади бер кызыксынучы булып кына түгел, бәлки аларга халыкның тарихын, аның тормыш һәм кичерешләрен ачык чагылдыручы «тутыкмас бер көзге» һәм көчле иҗтимагый көрәш коралы дип карый. Халык җырлары аркылы Тукай халыкның зарын, моңын, ireккә булган омтылышын күрә. Ул гомумән халык иҗатында, бигрәк тә җырларда, бетмәс-төкәнмәс тирән мәгънә, саф йөрәк һәм халыкның вөҗдан киңлеген күрә. Әнә шул караштан чыгып ул: «*Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул, әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри»*[3], – дип, үз халкының буржуаз җәмгыять шартларында төрле кара көчләр тарафыннан җәберләнеп, кимсетелеп сыкрануын ишетә. Һәм ул талант иясе булган халыкның көченә, аның киләчәгенә ышана. Ул халык җырларына төшенкелек мотивлары түгел, бәлки ирек, азатлык өчен көрәш мотивлары хас икәнен бик ачык аңлый. Халыкны «әллә нинди кара көчләр»нең басып торуы белән үзенең килешә алмавын, разый булмавын белдерә. Һәм: «Ләкин бу хәл вакытлы гына килгән бер авыру кеби гаризи бер хәлдер», – дип, халыкның югары катлаулар тарафыннан изелү, мәсхәрәләнүенә ачы протест белән чыгып, халык азатлыгы өчен актив көрәш юлына баса.

Тукайның халык иҗатына менә бу яктан, искелеккә каршы, яңалык өчен көрәштә көчле корал итеп каравы аның бөтен иҗаты буенча кызыл җеп булып сызылып бара. Димәк, Тукай халык иҗаты белән балалык чагында күңеленә сеңеп калган рухи байлык булганы өчен генә түгел, ә бәлки аңа идеология өлкәсенең зур тармагы булган матур әдәбият аркылы халык теләкләрен тормышка ашыру чарасы итеп карый. Ул: «*Халык моңнарыннан халык хисләре белән хисләнеп, мин үзем дә күңелемнән кайнап чыккан “шигырь” дип әйткән мазбут хиссиятләрем белән халык күңелен шурәлечә генә кытыкларга тырыша идем»*[4], – ди.

Нәкъ менә шулай фольклорга мөрәҗәгать итү, иң көчле әсәрләрен халык иҗаты җәүһәрләренә нигезләү аркасында, Тукай иҗаты иң авыр реакция елларында да халыкны искелек калдыклары һәм тираниягә каршы көрәшкә чакырып килде. Халык иҗаты Тукай иҗатының демократиягә һәм ирек өчен көрәшкә өндәү мотивларының төп һәм көчле нигезе булып торды.

---

[2] Тукай Г. Халык әдәбияты: җыентык. Казан: Татгосиздат, 1946. Б. 29.
[3] Шунда ук. Б. 30.
[4] Шунда ук. Б. 45.

Татар халкы арасында гасырлар буенча яшәп килгән фольклор әсәрләре Тукайга халыкның милли үзенчәлеген күрсәтүгә, чынбарлыкны дөрес чагылдыруга хезмәт итте. Фольклор әсәрләрендәге художество байлыгы, андагы стиль һәм формалардан урынлы һәм оста файдалану Тукайны татар әдәбиятында тиңдәше булмаган сугышчан реалистик язучы булу югарылыгына күтәрде.

Югарыда әйткәнебезчә, Тукай халык иҗаты белән яшьтән үк бик нык кызыксына. Бигрәк тә тормышының Уральск чорында (1895–1907 еллар) ул халык көйләрен өйрәнеп һәм ул көйләргә язылган йөзләрчә җырларны халык авызыннан язып алып, аерым бер җырлар дәфтәре тезеп калдыра. Бу җырлар аңа бик зур рух байлыгы бирәләр һәм Тукайның киләчәктә халык шагыйре булып формалашып китүенең нигез ташлары хезмәтен үтиләр. Шуның белән бергә шул ук елларда рус язучыларыннан Крылов, Пушкин һәм Кольцов әсәрләре белән якыннан танышу һәм аларның халык иҗаты йогынтысында язылган шигырьләрен каткат укып тикшерү Тукайда халык иҗаты алымнарыннан файдаланып язу һәм аларга мәхәббәт бәйләүдә икенче бер зур адым һәм этәреш була. Крыловның халык иҗаты стилендә гади һәм аңлаешлы тел белән язылган тирән эчтәлекле мәсәлләре Тукайда гомумән матур әдәбиятка, бигрәк тә бөек рус әдәбиятына аерата зур мәхәббәт тудыра. Шул бөек язучылар үрнәгендә эшләү Тукайның гомумән язучы булып формалашуына гына түгел, бәлки аның фольклор мотивлары нигезендә халык теләкләрен чагылдырган югары идеяле әсәрләр тудыручы шагыйрь булып үсеп китүенә бик нык ярдәм итә.

Тукай үз иҗатының беренче елларында ук үзе мөкатдәс санаган азатлык идеяләренә шигырьне хезмәт иттерүне төп максат итеп куя.

Иҗатының беренче елларында ук ул социаль мотивлары белән нык сугарылган «Дусларга бер сүз» (1905), «Иттифак хакында» (1905), «Яз галәмәтләре» (1905), «Хатирәи бакырган» (1906), «Государственная Думага» (1906) кебек шигырьләрен яза. Бу шигырьләр шул елларда язылган әсәрләреннән тел һәм шигырь төзелеше, формалары ягыннан гына түгел, бәлки, иң әһәмиятлесе, үзләренең эчтәлекләре ягыннан да бик нык аерылып торалар. Тукай, халык шагыйре буларак, киң массага каратылган социаль фикерләр белән сугарылган шигырьләрен мөмкин кадәр татар телендә, халыкка аңлаешлы телдә һәм формада язуны максат итеп куя, шуның юлларын эзли. Менә шуның өчен дә аның:

*Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,*
*Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк,*
*Диңгез якасында торып без сусамыйк,*
*Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.*
(«Дусларга бер сүз», 1905)

һәм дә:

*Тырышыйк, и хас вә гам,*
*Һәр көн үзгәрә заман.*
*Җитәр йокламыйк һаман,*

*Таңлар атты бәдәвам...*
(«Иттифак хакында», 1905)

кебек шигырьләрнең «Бәдәвам» һәм «Йосыф» китаплары үлчәүләрендә язылулары һичбер очраклы хәл түгел.

Ни өчен соң Тукай үз иҗатының беренче чорында бу «Бәдәвам», «Кисекбаш», «Йосыф – Зөләйха»ларга мөрәҗәгать итә? Чөнки ул вакытларда бу китаплар киң масса арасында шактый таралган, һәрбер йортта дип әйтерлек табарга мөмкин булган һәм халык кулындагы бердәнбер рухи азык урынында йөргән китаплар иде. Тукай үзе дә халык әдәбияты турындагы мәгълүм лекциясендә «Таһир – Зөһрә» хакында: «*Бу – татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы. Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, еламыйча үскән ирләребез вә хатыннарыбыз сирәктер»*[5], – ди.

Әнә шулай халыкка мәгълүм булган бу китаплар исеме астында, алар стиле һәм алар үлчәвендә халыкка яңа фикерләр әйтү һәм азатлык идеяләрен халыкка мәгълүм булган чаралар аркылы җиткерү Тукай иҗади эзләнүләренең бер төре булып тора. Кабатлап әйтәбез: Тукай үз иҗатының беренче чорларында, фәкать эзләнү рәвешендә, бу әсәрләрнең формаларыннан һәм шигъри үлчәүләреннән генә файдалана. «Бәдәвам»лардагы дини-мистик эчтәлек, алардагы феодализм чорына хас булган мотивларга Тукай баштан ук тәнкыйть күзе белән карый.

Тукай халык әдәбияты белән шактый таныш булуына карамастан, иҗатының беренче елларында фольклорны органик рәвештә үз иҗатына кертеп, үз идеяләренә хезмәт иттереп җибәрерлек дәрәҗәдә ул әле үзен хәзерлекле итеп сизми. Тукайның 1907 елга хәтле булган чорын аның фольклорны өйрәнү һәм татар әдәбиятында халыкчанлыкка таба көчле сикереш ясауга зур хәзерлек алып бару чоры дип санарга мөмкин булыр иде.

1907 елда Тукай «Ишек бавы», «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өметләре» кебек, чын-чыннан халык иҗатына нигезләнеп язылган әсәрләрен дөньяга чыгара башлый. Тукайның менә шундый әсәрләре үк бу чорларда аның халык иҗатына художество байлыгы итеп карап, фольклорны якыннан өйрәнә башлавын ачык күрсәтә. 1907 елда «Шүрәле» әсәре языла. Менә инде шушы әсәреннән соң Тукайның халык иҗаты белән чын-чыннан ныклы кызыксыну, аны фәнни өйрәнү чоры башлана дип әйтергә мөмкин.

Тукай татар фольклористикасы өлкәсендә чын мәгънәсе белән фәнни һәм төпле теоретик хезмәт куючыларның беренчесе булды. Дөрес, Тукайга хәтле үк татар фольклорын җыйнау һәм аны билгеле бер фәнни системага салуда шактый зур адымнар ясалды. Тукай исә, татар халык әдәбияты әсәрләрен фәнни яктан өйрәнү өлкәсендә гаять зур эшчәнлек күрсәткән Каюм Насыйри башлаган эшне дәвам ит-

[5] Тукай Г. Халык әдәбияты: җыентык. Казан: Татгосиздат, 1946. Б. 40.

терү белән бергә, халык әдәбиятының гомуми культура өлкәсендә, тоткан урыны, аның әһәмияте һәм язма әдәбият белән халык әдәбияты арасындагы аерма һ.б. турында кыйммәтле фикерләр калдырды һәм татар фольклорын эшкәртү өлкәсендә шактый зур хезмәт күрсәтте.

II

Тукайга хәтле безнең әдәбиятта халык иҗатының табигатен дөрес билгеләүче, аңа Тукай кебек фәнни анализ ясаучы булмады. Тукай исә бу мәсьәләгә аерым бер лекция багышлый һәм үзенең халык иҗатына булган теоретик һәм фольклор өлкәсендә тикшеренү нәтиҗәсендә туган фәнни карашларын әнә шул лекциясендә яктырта. «Халык әдәбияты» темасына ясаган лекциясендә (бу лекция 1910 елның 15 апрелендә, Казанда «Шәрык» клубында була) иң элек ул фольклорга билгеләмә биреп: «*Халык әдәбияты, халык шигырьләре дип, инша итүче шагыйре беленмәгән, яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә масалларга әйтеләдер. Бу нәүгы әдәбият, әле дөньяда язу сәнгате булмаган чакта ук, авыздан авызга сөйләнеп, бабадан атага, атадан балага ишетелеп, буыннан-буынга калып килгән әдәбияттыр»*[6], – ди.

Тукайга хәтле һәм Тукай заманында халык әдәбиятының табигатен билгеләүдә төрле-төрле карашлар, мәктәпләр яшәп килде. Ул вакытта фольклор әсәрләрен язма әдәбияттан бөтенләй аерып, төбендә халык авыз иҗатын үзенә башка бер процесс итеп тану карашы өстенлек итә иде. Бу карашлар буенча халык әдәбияты әсәрләре, беренчедән, авторлары бөтенләй булмаган, ягъни «бөтен халык тудырган» әсәрләр дип каралса, икенчедән, фольклор әсәрләренең сәнгать әсәрләре булулары, аларның художестволылыгы бөтенләй инкарь ителде. Ә инде фольклор әсәрләренең социаль функцияләре, аларның сыйнфыйлылыгы проблемасы бөтенләй телгә дә алынмый иде.

Тукай исә фольклор әсәрләренең «язу сәнгате булмаган чакта ук, авыздан авызга сөйләнеп, бабадан атага, атадан балага ишетелеп, буыннан буынга калып килгән әдәбият» икәнен ачыклады. Шуның белән бергә, ул, халык әдәбияты, халык шигырьләренең башта бөтен халык тарафыннан түгел, бәлки аерым кешеләр – авторлар тарафыннан чыгарылганын, тик аларның язу сәнгате булмаган вакытларда иҗат ителгән әсәрләр булганлыктан, «инша итүче шагыйре беленмәгән, яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган, ягъни сакланмаган» сәнгать әсәрләре икәнен ачык итеп күрсәтте. Язма әдәбиятның төп чыганагы халык әдәбиятыннан башланып киткәнлеген әйтеп, Тукай: «Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятыбызга бер дә шөбһәсез нигез булачактыр»[7],

[6] Тукай Г. Халык әдәбияты: җыентык. Казан: Татгосиздат, 1946. Б. 26.
[7] Шунда ук. Б. 33.

– дип, фольклор әсәрләренең тарихи функцияләрен билгеләп үтте. Тукай югарыда әйтелгән лекциясендә, халык әдәбияты үрнәкләреннән бик күп мисаллар китереп, фольклорның төп жанрларыннан булган әкиятләр, җырларга фәнни классификация ясый һәм жанр өчен дә характерлы булган якларны ачыклап үтә. Шушы ук лекциясендә халык җырларына һәм аларга ияртелеп язылган «ясалма җырларга» – шагыйрьләр тарафыннан халык иҗаты стилендә язылган шигырьләргә тукталып, бу төр шигырьләр турында бик күп мисаллар китерә һәм боларга карата төпле фәнни анализ ясый. Фольклор белән язма әдәбият арасындагы төп аерма – фольклорга хас булган үзгәрүчәнлек тә Тукай игътибарыннан читтә калмый: «Халык җырлары, халык әдәбияты кайчакта шулай аерым шәхесләрнең кәефенә карап төрләнә дә. Хикәя вә масалларда да хәл шушылай ук; мәсәлән, бер хикәя сөйләүче үзенең хикәясен: “бар иде урман буенда бер карт белән бер карчык”, дип башласа, шул ук хикәятне икенче кеше: “бар иде, ди, диңгез буенда бер карт”, – дип башлый»[8], – ди.

Тукай фольклор әсәрләренең тышкы формаларын һәм төзелешләрен тикшерү белән генә чикләнми. Ул фольклор әсәрләренең эчке табигатенә, аларның социаль функцияләренә туктала: «*Халык җырларын дикъкать белән укылса, халыкның күңелендә нәрсәләр сакланганын, барчасын күреп буладыр»*[9], – дип, халык иҗаты әсәрләрендә – үткәннең көчле яңгыравы, бүгенгенең якты чагылышы, киләчәкнең матур өметләре тупланганын билгеләп үтә.

«Тәфтиләү», «Ашказар», «Сак-Сок», «Касимский Ибрай», «Җизнәкәй» һәм «Башмагым» көйләре Тукай заманында татар халкы арасында бик нык таралган иде. Тукайның, бездә беренче буларак, бу көйләрнең тууу тарихын язуы, бу һәм башка көйләргә җырлана торган меңнәрчә халык җырларын җыйнап, «Халык моңнары» җыентыгы кебек аерым китаплар чыгаруы шулай ук Тукайның фольклор өлкәсендә эшләгән зур фәнни хезмәтләре булып тора. Ләкин ул үзенең бу хезмәтләренә башлангыч эшләр дип кенә карый иде: «Халык җырлары чын үзебезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек кабиләләренең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм. Шунлыктан халык җырларына мөхәббәтемнең бер әсәре булсын дип, шушы мөлахәзәләремне язарга җөрьәт иттем»[10], – ди. Һәм: «Безнең җырланмакта булган көйләребезнең һичберсе дә бер-бер сәбәпсез, бер-бер нәрсәнең тәэсиреннән башка чыкмаган булса да, мөгаттәэссеф аларның сәбәпләрен вә тарихларын тикшерергә кулымда материал

[8] Тукай Г. Халык әдәбияты: җыентык. Казан: Татгосиздат, 1946. Б. 37.
[9] Шунда ук. Б. 31.
[10] Шунда ук. Б. 41.
[11] Шунда ук. Б. 23.

булмады. Җырларымыз вә көйләремезнең тарихын вә мәнбәгъләрен тикшерергә бер заман махсус хезмәт куярмын да, шаять халыкка шул турыда әсаслерәк мәгълүмат бирермен дигән өмитем бар әле»[11], – ди ул шул мәгълүм лекциясендә. Ләкин шагыйрьнең кайнар иҗат белән үткән гомеренең вакытсыз өзелүе аңа үзенең бу зур теләген тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде.

III

*«Мин шүрәле – һәм дә татар урманнарында гына була торган “милли шүрәле” булганга, мин җәй көне урман буена ат ашатырга килгән яшүсмер Гайнетдин вә Сәйфетдиннәрнең дә җырларын тыңладым.*

*Ул Гайнетдиннәрнең бәрәңге пешерер өчен яккан утлары минем күземә күренгән шикелле, аларның ут әйләнәсенә утырышып җырлаган җырлары һәм моңлы күңелләреннән чыккан хиссият утлары минем йөрәгемә тәэсир итәләр иде...*

*Халык хисләре белән хисләнмәгән кешеләр өчен гади бер кычкырып утыру булган бу җырлаулар минем күңелемнең иң нечкә кылларына тукыналар иде. Шуннан соң мин дә аларныкы шикелле үк итеп, алар вәзене белән, алар көенә үк салып, үз хисләремне мәйданга чыгара башладым»*[12], – ди Тукай.

Тукайның халык иҗаты байлыклары белән чын күңелдән кызыксынып, халыкның хиссиятен түкми-чәчми җыйнап алуны максат итеп куюын менә бу югарыда китерелгән юллар бик ачык күрсәтәләр.

Тукай, кайда гына булмасын, фольклор әсәрләренә колак сала һәм аларны халыкта җырлаганча, халыкта сөйләгәнчә язып алуны максат итеп куя. 1912 елда Тукай авылда авырып ята. Менә шул вакытта да ул Казанга, «Ялт-йолт» журналы редакциясенә язган бер хатында: «Шулай да, ягъни хәзергә шигырь язмый торсам да, җырлаудан тартынмыйм», – ди һәм авылда язып алган җырларыннан берничәсен язып җибәрә.

Тукайның «Сак-Сок» бәете белән бик нык кызыксынуы һәм аның төрле вариантларын җыйнавы шулай ук бик характерлы:

*«Бу “Сак-Сок” хикәясе халыкның бернәрсә белән дә чикләнмәгән киң фантазиясеннән (хыял) туган бер хикәядер»... «Мин – шушы сатырларны язучы кеше, бу “Сак-Сок” дип аталган “милли фантазия”без хакында күп-күп кешеләрдән күп-күп истифсарларда булындым».*

«Сак-Сок бәете»н беләсезме? Белсәгез, язып китерсәгез иде дип үтендем»[13] – ди Тукай. Менә шушы «Сак-Сок бәете» белән кызыксынуы һәм аның халык арасында булган төрле вариантларын җыйнау эшендә күрсәткән тырышлыклары аркасында, Тукай кулында бу фантастик бәетнең бик күп вариантлары җыйнала. Тукай шулардан үзен-

[12] Тукай Г. Халык әдәбияты: җыентык. Казан: Татгосиздат, 1946. Б. 45–46.
[13] Шунда ук. Б. 58–59.

чә мөһим белгәннәрен сайлап, «Халык моңнары» җыентыгында бу бәетнең шактый тулы бер җыйналмасын һәм үз гомерендә җыйнаган күп кенә фольклор материалларын аерым бер җыентык итеп бастырып чыгара. Шулай ук Тукайның 1946 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан табылган җырлар дәфтәре[14] безнең көйгә салынган ярым сюжетлы җырларыбызны туплауда, аны билгеле бер тәртипкә салуда гаять зур бер хезмәт дип каралырга тиеш. Болардан башка ул фольклор материалларын үзенең лекциясендә мисал рәвешендә бик күп санда китерә һәм иҗатының төрле дәверендә җырлар, бәетләр һәм әкиятләрне аерым-аерым рәвештә матбугатка чыгара бара.

Тукай тарафыннан матбугатта игълан ителгән фольклор материалларының саны түбәндәгечә:

1. «Халык моңнары» җыентыгында: кыска көйләргә булган җырлар – 51, озын көйләргә булганнары – 14, пешми калган җырлар – 3, яртыгыналар – 2, рестаннар җыры – 10 һәм «Сак-Сок» бәетләре – 72 юл.

2. «Халык әдәбияты» темасына ясалган лекциясендә әкият – 1, халык мәкале – 1, бәет үрнәге – 2 һәм 15 җыр китерелә.

3. Соңгы вакытта табылган җырлар дәфтәрендә барлыгы 28 көйгә 312 җыр язылган. Шунысы бик характерлы, Тукай дәфтәрендәге җырлар белән Каюм Насыйриның «Фәвакиһел җөләса»сындагы һәм Тукайның үзенең үк «Халык моңнары» җыентыгындагы җырлар арасында бик нык ошаш һәм параллельләр бар.

Тукайның бу күп сандагы җырлары кайдан һәм кемнәрдән язып алганлыгы, аларны нинди урыннарда җыйганлыгы хәзергә безгә мәгълүм түгел. Тукай җырларының чыганакларын, язылып алыну урыннарын һәм ул җырларның хәзерге көндә халык арасында сакланган параллельләрен табу фольклор өлкәсендә эшләүчеләр алдында торган зур кирәкле һәм кичектерелмәслек бер эш булып саналырга тиеш.

## IV

*«Русларның Пушкин вә Кольцов кеби иң зур шагыйрьләре дә халык җырларына тәкълит итеп, бер төрле “искусственные песни”, ягъни соңгый җырлар яздылар.*

*Болай халык җырларына тәкълит итеп язган шагыйрь тәкълит итмичә язылган шигырьләрдән хис, мәгънә, тасвир ягыннан һич тә ким булмавы өстенә, халыкның үз көе, үз вәзене, үз формасы илә язылганга, халык күңеленә бигрәк гүзәл тәэсир итә вә урынлашадыр.*

*Бу җөмләдән Кольцовның “Ник йоклыйсың, мужик?”, “Сукачы җыры”, Пушкинның “Кызлар җыры” саналалар.*

*Ә бездә халык җырларына тәкълит итүчеләр бильгомум булдымы? Әлбәттә, безнең Кольцовларыбыз, Пушкиннары-*

---

[14] Г. Тукайның 1946 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан табылган бу җырлар дәфтәре 1946 елда Татгосиздат тарафыннан чыгарылган «Тукай Г. Халык әдәбияты» дигән җыентыкның азагында тулысынча басылды.

*быз булмаганга, мин: “Халык җырларына тәкълит итүчеләр бильгомум булдымы?” дигән сөальне тәкрар әйтәм дә: ник булмасын – булды дип, үз сөалемә үзем җавап бирәм»*, – ди Тукай.

Һәм бөек рус әдәбиятында Пушкин, Лермонтов тарафыннан башланып, Кольцов һәм Некрасов кебек шагыйрьләр тарафыннан дәвам иттерелгән менә бу бөек традициянең иң матур үрнәкләре татар әдәбиятында Тукай иҗатында үзенең киң чагылышын тапты.

Фольклорның ачык йогынтысын Тукайның 1907 елда язылган «Ишек бавы», «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өметләре» (Бишек җыры), «Шүрәле» әсәрләрендә; 1908 елда язылган «Егет илә кыз», «Күк сыер», «Авыл җырлары» (1, 2, 3 нче көлтәләр һәм аерым җырлар), «Таз», «Су анасы», «Алтын әтәч» (Пушкиннан тәрҗемә), «Чын вә Ялган», «Яңа Кисекбаш» әсәрләрендә; 1909 елда язылган «Япон хикәясе», 1910 елда язылган «Кәҗә белән сарык», «Кәҗә турында» әсәрләрендә; 1912 елда язылган «Өч хәкыйкать», «Казан вә Кабан арты», «Ни кирәк тагы» әсәрләрендә күреп була. Болардан башка Тукайның проза белән язылган күп кенә әсәрләрендә дә фольклор элементларының йогынтысы бик еш чагыла.

Тукайның шигырьдә фольклор әсәрләренә мөрәҗәгать итүе аның 1907 елда язылган «Ишек бавы» әсәреннән башланып китә, дидек. Бу әсәр электә туй вакытларында җырлана торган «Ишек бавы» җыры тәэсире астында ярым җыр, ярым такмак рәвешендә языла. Бу шигырь Тукайның халыкның гореф-гадәт һәм җолаларына бәйләнгән авыз иҗатына бик нык игътибар биргәнлеген күрсәтә. Яки аның шул ук 1907 елда «Ишек бавы»ннан соң ук язылган «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өметләре» дигән әсәрен алырга мөмкин.

Халыкның тормыш-көнкүреше, электән калган гадәт-җолалары белән бәйле булган фольклорны өйрәнү, аннан гына тәм табу Тукайны һич тә канәгатьләндерми. Ул халыкның киң фантазиясен күрсәткән, аның төрле-төрле мифларга ышану вакытыннан калган әсәрләре белән бик нык кызыксына башлый. Ул халык арасында бик күп еллар буенча яшәп килгән экиятләрдән халыкның үткенлеген, акылын, тапкырлыгын күрсәтә торган әсәрләрне сайлап алып, шулар нигезендә «Шүрәле» кебек классик әсәрләр тудыра.

«Мин бу “Шүрәле” хикәясен Пушкин вә Лермонтовларның шундый авыл җирләрендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуларына истинадән яздым. Өмет юк түгел әле: ихтимал үз арабыздан мәшһүр рәссамнар чыгып, шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кыйлган урманнарны – һәммәсен тәрсим кыйлып чыгарырлар. Авыл җирләрендәге хыялый хикәяләрнең һәммәсен язып чы-

[15] Тукай Г. Академик басма. Т. 1. Казан: Татгосиздат, 1943. Б. 428.

гуда файдадан башка бернәрсә дә булмас зан идәрем»[15], – ди.

«Шүрәле» дә Тукайның авыл табигатен шул хәтле бай һәм матур итеп тасвирлавы, шүрәле кебек күрер күгә коточкыч «урман хуҗасын» тез чүктерүче, акыллы, батыр һәм тапкыр авыл кешесенең онытылмаслык образын бирүе татар әдәбиятында ул вакытка хәтле күрелмәгән әдәби югарылыкта эшләнде. Тукай үзенең татар теленә булган мәхәббатенең халык җырларын, халык әдәбияты җәүһәрләрен яратудан, аларны өйрәнүдән килеп чыкканын кат-кат әйтә. Фольклорга нигезләнеп язылган «Шүрәле» Тукайның саф татар телендә язылган иң зур һәм иң күренекле әсәрләреннән берсе. Һәм әгәр дә без Тукайның киң массага аңлаешлы татар телендә яза башлавы аның нә шул «Шүрәле» исемле әсәреннән башланып китте дисәк, ялгышмаган булырбыз.

Тукай үз әсәрләрен тематик һәм эмоциональ баетуда фольклорның барлык жанрларыннан бик оста файдалана. Әгәр жанрлар зурлыгы тәртибе белән киткәндә, татар халык әкиятләре мотивларыннан файдаланып язган әсәрләренә аның «Шүрәле», «Су анасы», «Таз», «Кәҗә белән сарык» әкиятен, тәрҗемәләрдән «Өч хакыйкать», «Япон хикәясе», «Алтын әтәч» әсәрләрен кертеп булыр иде. «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән сарык» кебек оригиналь әсәрләрдә Тукай татар халык әкиятләренең һәм форма һәм эчтәлек ягыннан халыкка аңлаешлы һәм иң якын булганнарын файдалана. Аерым әсәрләрендә легендар һәм әкиятләрдән файдалану классик төс ала. Мәсәлән, «Яңа Кисекбаш»та иске Казан шәһәре һәм Кабан күле турында халык арасында бик күп санда йөргән легендалардан бик урынлы, бик уңышлы рәвештә файдалану белән бергә, бу әсәренә әкият элементын да кертә. Поэмадагы Кабан күле асты тормышы, анда төшү белән Карәхмәт тарафыннан күрсәтелгән «батырлыклар», татар халык әкиятләреннән «Йөзми» дигән әкияттән алынган булса кирәк. 1900 елны Т. Яхин тарафыннан чыгарылган җыентыкка китерелгән «Йөзми» исеме әкиятнең герое, бер картның йөзенче улы Йөзми, үзенең дошманы дию артыннан куып йөри торгач, диюләр дөньясы – су астына барып төшә. Әкияттәге диюнең су асты тормышы белән, «Кисекбаш»тагы Кабан күле астында «яшәүче» дию тормышы арасында брнинди дә аерма юк. Әкияттәге мотивлар белән «Кисекбаш»та китерелгән күренешләр арасында бик нык ошашлык бар.

Яки менә Тукайның «Чын вә Ялган» исемле шигырен алыйк. Монда чын белән ялган арасында булган талаш-тартыш мотивы рус галиме Афанасьевның «Рус халык әкиятләре» җыентыгында китерелгән «Правда и Кривда» исемле әкиятеннән алынган булуы күренә. Афанасьев әкиятендә чын белән ялган арасында: дөньяда чын белән тору яхшымы, әллә ялганлап тору өстенме? Дигән темага бәхәс чыга. Болар бу бәхәсне хәл итү өчен көймәләргә утырып, дөнья гизәргә китәләр. Тукайда да шигырь:

*Әүвәле дөньяда җир юк. Су гына булган, диләр.*
*Анда йөзгәннәр, имеш, тик Чын белән Ялган, диләр.*
*Бу ике дошманга тәңредән бирелгән бер көймә,*
*Бәс, утырганнар көймәгә берсе каршы берсенә, –*

дип башланып китә. Афанасьев әкиятендә чын белән ялган арасында чыккан сугыш чынның җиңүе, ялганның җиңелүе белән бетә. Ләкин Тукай әкияттән төп мотивны гына ала да, нәтиҗәне үзенчә хәл итә:

*Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан, ди дә,*
*Чын батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә,* – ди.

Әгәр дә без Тукайның бу «Чын белән Ялган» шигыренең Россиядә кара реакциянең бик каты хөкем сөргән һәм барлык хакыйкатьне юкка чыгару өчен бернинди кабахәтлекләрдән дә тартынмый торган бер чорда[16] язылганын искә алсак, Тукайның «халык өскә чыгарга тиеш» дигән нәтиҗәне китереп чыгара торган халык әкиятенә үзенчә нәтиҗә ясавы һич тә гаҗәп түгел. Тукай бу «Чын белән Ялган» шигырен, әлбәттә, шул вакыттагы капиталистик җәмгыятьтә өстенлек иткән ялган һәм икейөзлелеккә протест һәм аны ачы тәнкыйть итү йөзеннән яза. Ләкин ул үзе яшәгән чорларда чын белән ялган арасында барган көрәштә чынның, һичшиксез, җиңеп чыгачагына ышана. Шул ук «Чын белән Ялган» шигыреннән соң язган «Өмет» (1908) шигырендә:

*...Юк, коячым, мин беләм, син батмагансың мәңгегә,*
*Син дә, вөҗдан, бер торырсың, ятмагансың мәңгегә...* – ди.

Тукай татар халык җырларына зур мәхәббәт белән караганлыктан, аларны җыйнау белән генә чикләнеп калмый, бәлки ул халык җырларының тулы эчтәлекләрен, идея юнәлешләрен аңларга тырыша һәм татар җырларының тышкы төзелеш, формаларын өйрәнеп алар турында тулы фәнни фикер әйтә: «*Аннан соң безнең халыкта җырлар өчен әүвәлге ике юлның күп вакытта бер дә әһәмияте дә булмыйдыр. Әүвәлге ике юл анчак скрипка уйнаганда бер кәррә кыл тартып кую кабиленнән генә бер нәрсәдер. Мәсәлән, гавамнан берәү җырлый: "Сандугачлар су ташый – кайда икән су башы". Ул бу сүзләрен җыруга санамый, бәлки тыңлаучыга үзеннән бер нәрсә көттерә. Тыңлаучы: "Бу нәрсә әйтмәкче була икән?" дип көтеп торган чагында гына, ул: "Безнең җанкәй ялгыз башы – Хөзер булсын юлдашы" дип куя. Шулай көтмәгәндә генә килеп чыккан бу матур сүзләр тыңлаучының колакларына вә күңеленә, әлбәттә, хуш килә. Бу тарыз җырлау, табигый рәвештә сайланган булса да, бик муәффәкыйтьле сайланган. Әүвәл юк кына сүзләр берлән тыңлаучының колагын торгыз да, аннан соң мәгънәле сүз әйт. Бик яхшы бит! Шулай, көтеп алган кадерле була*»[17], – ди Тукай.

---

[16] «Чын вә Ялган» 1908 елда языла.
[17] Тукай Г. Халык әдәбияты: җыентык. Казан: Татгосиздат, 1946. Б. 28–29.

Ләкин Тукай татар халык җырлары өчен әнә шундый төзелеш кенә хас дип өзеп куймый. Ул татар җырларының кайберләрендә беренче ике юл белән соңгы ике юл арасындагы мәгънә берлеге булуын да инкарь итми һәм шул фикерен исбат итү өчен күп кенә мисаллар да китерә. Татар халык җырларыннан бигрәк тә кыска җырларның әнә шундый үзенчәлекләре Тукай иҗатына тәэсир иткән уңайлы бер факт булып та торды. Тукай менә шушы халык җырлары үлчәве һәм стиле үрнәгендә соңыннан үзе «халык җырлары нигезендә төзелгән ясалма җырлар» дип атаган җырларын иҗат итте. Аларга үзенең сатирасын тагын да үткенләндерүдә көчле чыганаклар итеп карады:

*Яңгыр ява сибәләп,*
*Төймә-төймә төймәләп;*
*Чыгтай мулла үкереп җылый,*
*Тәүбә-тәүбә тәүбәләп.*

*Безнең урам аркылы*
*Ага суның салкыны;*
*Тарта Казанның яшьләрен*
*Рәмиевләр алтыны.*

Менә шулай Тукай башта татар халык җырларыннан халыкка таныш булган бер юлны китерә дә, халык җырының икенче юлы урынына шул ук җыр үлчәвенә салынган бөтенләй яңа сүзләр, яңа фикерләрдән торган юллар тудыра. Тукайның шулай иҗат ителгән җырлары сан ягыннан түбәндәгечә: 1 нче көлтәдә – 14 җыр, 2 нче көлтә – 12 җыр, 3 нче көлтә – 13 җыр һәм төрле урында тагын 14 җыр. Барлыгы 53 җыр. Бу җырлар турында Тукай үзе:

*«Менә бу “соңгый җырлар” да вакытында бик оригинальный вә нәүзәһур нәрсәләр иде. Чөнки көленергә тиеш бер нәрсәдән бер-ике юллык сүзләр белән тиз генә көленеп ташланыла иде. Бу озын-озын мәкаләләр хезмәтеннән артыграк эш күрә иде...*

*...Башта әйткәнебезчә, халыкның бу тарыз җырлавы бик муәффәкыятьле сайланганлыктан, моның безнең һөҗүвиятебезгә (сатирабызга) дә файдасы тиде»*[18], – ди.

Һәм Тукай халык җырларының әнә шундый аз сүз белән күп мәгънә аңлату үзенчәлеген бик оста тота белә.

Татар халык җырларындагы тирән мәгънәле тапкыр сүзләр алымыннан файдаланып, Тукай безнең әдәбияттагы сатира жанрын үстерүгә һәм аны бик нык алга җибәрүгә зур хезмәт итте. Халыкның лирик җырларыннан ул үз шигырьләренең художество көчен тагын да ныграк үстерүдә файдаланды.

Мәкальләр һәм әйтемнәр фольклорның иң борынгы жанрларыннан саналалар. Мәкальләр турында Максим Горький: «Гомумән мәкальләр һәм әйтемнәр хезмәт халыкларының бөтен тормыш, социаль-тарихи тәҗрибәләрен үрнәк рәвештә калыпка салалар», – ди. Тукай халыкның әнә шул күп еллык тормыш тәҗрибәсе нигезендә туган мәкальләр – үткен сүзләреннән дә мәгънә һәм сәнгать көче таба белде. Проза әсәрләрендә «Суга алмаган зур күтәрер» («Казан хәбәрләре». «Ялт-йолт», 1910),

---

[18] Тукай Г. Халык әдәбияты: җыентык. Казан: Татгосиздат, 1946. Б. 34.

«Тисә тиенгә, тимәсә ботакка» («Тәнкыйть кирәкле шәйдер», 1907) кебек әйтемнәрне бик еш китерә. Ә инде аерым шигъри әсәрләренең эчтәлеген баету, үзе тасвир итәргә теләгән образларны тагын да тулырак сурәтләү өчен, Тукай мәкальләрне бик күп җирдә урынлы һәм уңышлы куллана.

Мәсәлән, ул «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» (1907) шигырендә:

*Күзсез булгач –*
*Нишләсеннәр,*
*Дөньяда юк*
*Сукырга суд, –*

ди. Халыкта бу әйтем «сукырга суд юк» формасында йөри. «Өч хакыйкать»тә (1912) Тукай халык мәкальләрен шулай куллана:

*Кемдер әйткән: күктәге торна өчен*
*Күп очырганнар кулында бар кошын.*

*(Халыкта: «Һавадагы торнага ышанып,*
*Кулыңдагы чыпчыкны очырма» дип әйтелә).*

*Шунда да уйлап таба бер хәйләне:*
*Хәйләле дөнья, диләр, бит, файдалы.*

*(Халыкта: хәйләсез дөнья файдасыз).*

*«Үткән эш кайтмый» дигәнне аңладың,*
*Син мине тоттың да саклый алмадың».*
*(Халыкта: «Үткән эшкә салават», диләр).*

*Бер борыл да, әй Казан, син бу Казан артын кара:*
*Нур чәчәсең бар өязгә – үз өязең артын кара:*
*Нур чәчәсең бар өязгә – үз өязең кап-кара.*
*«Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампаның һичбер нуры»,*
*Шул мәкаль монда дөрес шул, ах, аны җен, оргыры!*
*(«Казан вә Казан арты», 1912)*

*Җәйләр үтте, җиттек инде октябрьга,*
*Җылылык юк җирдә һәм дә күктә бер дә,*
*Сентябрьдә син дә бердәй, мин дә бердәй,*
*Миһманнарны яклаучыга үпкә бергә.*

Халыкта бу әйтем «Зур диңгез дулкынламый тормас» төсендә йөри.

1907 елда язылган «Бишектәге бала» шигырендә:

*Бәхетле нарасый да! Тар бишек тә киң әле аңгар;*
*Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң әле аңгар, –*

ди. Халыкта бу әйтем «аңа диңгез тубыктан» дип йөртелә.

Тукай фольклордагы «Һәрбер ялтыраган алтын булмый» мәкален үзенең балалар өчен язылган 8 юллык бер шигыренә исем итеп куя. Менә югарыда китерелгән, әмма Тукай әсәрләренә кергән мәкаль һәм әйтемнәрне тулысынча эченә алып бетерүе мөмкин булмаган мисаллар Тукайның халык иҗатында булган тапкыр мәгънәләрне җыйнау һәм алардан файдалануга нихәтле зур игътибар иткәнлеген ачык күрсәтәләр.

Халык иҗаты жанрларыннан бәетләр дә Тукай игътибарыннан читтә калмадылар. Татар халык бәетләрен Тукайның үз иҗат фондына ничек кабул итүдә «Кәҗә турысында» дигән шигыре бик характерлы бер мисал булып хезмәт итә ала.

Кәҗә халык аңында бик әрсез һәм хәйләкәр бер хайван булып тәсмерләнә. Тукай кәҗәнең

бу хәйләкәрлеген һәм башка сыйфатларын күрсәтүгә үзенең ике әсәрен багышлый. Аның 1910 елда «Кәҗә белән Сарык» әкияте басылып чыга. Бу әкияттән соң язылган «Кәҗә турысында» (1910) дигән шигырьнең башында кәҗә хуҗасына үзенең зарын белдерә:

*Китмәсен хак сүзгә кәефең синең,*
*Күргәнең бармы кәҗә бәетен синең;*
*Әмма соң анда каты теткән мине,*
*Бер дә кызганмастан эт иткән мине, –*

ди дә, кәҗә хуҗасына халык арасында йөргән «Кәҗә бәете»н «укып» китә. Бу «Кәҗә бәете» күптәнге һәм халык арасында бик нык таралган фольклор әсәре. Аның тулы тексты 1909 елда Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» исемле җыентыгында 44 юллык бер бәет булып басылган иде. Тукай «Кәҗә бәете»н шуннан алып, беркадәр үзгәртеп һәм кыскартып (12 юлга калдырып), иң кирәкле, үткен сүзле җирләрен ала. Тукай «Хикәят вә мәкаләт»тәге тәртипне үзгәртеп бирү белән бергә, эчтәлеген, художество эшләнешен яхшырту хисабына бәетне төзәтә:

Фәезханов текстында:

*Игътибар юк ул кәҗәнең гаклына,*
*Инабәт юк ул кәҗәнең сакалына;*
*Кайда барсаң, шунда аны гайбәт кыйлгыл;*
*Язык булмас, бәлки савап булыр, имди.*

Ә Тукайда:

*Игътибар юк ул кәҗәнең сакалына,*
*Кыйнамыйча килмәс асла гакылына;*
*Ул кәҗәне кайда күрсәң, шунда кыйна,*
*Язык булмас, бәлки савап булыр, имди...*

рәвешендәге стилистик матурлаулар белән бирелә.

Югарыда саналган жанрлардан башка Тукай иҗатында халык драммасы әсәрләрен («Өйләнү түгел сөйләнү», «Егет илә кыз» һәм башкалар), табышмак, башваткычлар («Бу кайчак була?» – русчадан тәрҗемә) һәм фольклор мотивлары буенча язылган бик күп әсәрләрне табарга мөмкин.

Тукай үз халкының иҗат көченә чын күңеленнән ышанды һәм халык тарафыннан гасырлар буенча тудырылган фольклор әсәрләренең язма әдәбият өчен нигез, беренче башлангыч чишмә икәнлеген тирәннән аңлап эш итте. Үз иҗатының идея тирәнлеген һәм художество көчен баетуда бөек рус язучылары Пушкин, Лермонтов, Кольцов, Некрасов һ.б.лардан үрнәк алу белән бергә, Тукай татар фольклорын тирән мәхәббәт белән җыйнау һәм аны өйрәнүдә дә шул ук бөек рус язучылары традициясе буенча барды. Халыкның хезмәт һәм тормыш тәҗрибәләре нигезендә туган авыз иҗатындагы тирән эчтәлек, халык талантының чагылышы буларак эшләнгән онытылмаслык образлар, традицион мотивлар, көчле аңлаешлы тел һәм сурәтләү чаралары – болар барысы да халыкның йөрәк тибешен якыннан ишетеп, аңлап, халыкка хезмәт итүне идеал итеп куйган Тукайга иҗат көче, зур дәрт бирде.

Тукайның халык иҗатын өйрәнүе, фольклорның Тукай иҗатында ничек һәм ни дәрәҗәдә чагылуы, Тукай иҗатында халыкчанлык һәм башка шуның кебек мөһим, ләкин хәзергә хәтле тиешенчә өйрәнелмәгән мәсьәләләр һичшиксез өйрәнелергә тиешләр.

УДК 821.512.145

***Габдрахман Сәгъди***

# ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ АРАСЫНДА ТУКАЙ
## (үлүенә ун ел тулу мөнәсәбәте белән)

Статья известного востоковеда, специалиста в области истории тюркских литератур Габдрахмана Саади (1889–1956) была написана к 10-летию со дня смерти выдающегося татарского поэта Габдуллы Тукая и посвящена изучению его жизненных позиций, взглядов, а также творчества. Статья была опубликована 28 марта 1923 года в журнале «Безнең юл» № 8–9 (март, апрель). В настоящее время один из авторских вариантов данной статьи хранится в Центре письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ (фонд 89).

**Ключевые слова:** Г. Тукай, А. Пушкин, творчество, литература, лирика, величие поэта.

I

Тукайның арабыздан югалуына бу ел апрельда инде ун ел тулды. Мәгәр татар шагыйрьләре арасында вә, гомумән, татар шигъри дөньясында Тукайның тоткан, тотарга тиеш булган урыны тугры үлчәүле әдәби тәнкыйть каләмнәре аркылы әле һаман катгый рәвештә ачык аңлашылып, ачылып җитә алганы юк.

Ләкин, асылда, бу хәлне зур шагыйрьләрнең хосусиятләреннән дияргә мөмкин. Шекспир үзе үлгәннән йөз илле еллар соң, Пушкин да вафатыннан байтак еллар үткәч кенә кирәгенчә аңлашылып, шуннан соң гына үзләренә тиешле бәһане ала алганнар.

Безнең Тукай да әле безгә яхшы танылa алганы юк.

Үз заманында вә үзе үлгәннән соң Тукай турысында төрле тәэсирләр, төрле дулкыннар астында язылып үткән нәрсәләр генә Тукайның кем икәнен, аның татар шигъри дөньясында тоткан урынын кирәгенчә тулы билгеләү өчен, әлбәттә, җитми. Моның өчен бу турыда чыннан фәнни бер ысулга утыртылган яклаусыз (битараф) төпле тикшерүләр, озын, киң төшенүләр кирәк.

Шуның өстенә, Тукай инкыйлаби дәверебездә тикшерелергә тиеш. Ул безгә шул дәвердә ачыграк аңлашылачак. Аңа юксыллар хакимияте дәверендә дөресрәк күз ташларга мөмкин.

Дөрес, татар гаммәсе, татарның гомумән карты-карчыгы, егете-кызы, сабыйлары – яшүсмерләре арасында үз заманында һәм үзеннән соң хәзергә чаклы да Тукайның урыны, аның кем икәнлеге ачык мәгълүм. Аңа бөтен татар гаммәсе бүтән һәммә шагыйрьләреннән элек үзенең «Беренче шагыйребез» дигән тарихи мөһерен басып куйган иде.

Бу мөһердә Тукай шигырьләренә бәһа куюда һичбер тәэсиргә бирелмәстән, тугрыдан-тугры аның шигырьләрен укып

яки тыңлап алынган тәэссерләр нәтиҗәсендә ялгыз гомуми халык әдәби зәүкы ягыннан сугылган бер мөһер иде.

Ләкин мәшһүр бер каләм Тукай турысында кире юлга кереп, аның хакында (1913 нче елда) халык зәүкын хатага чыгара язды. Татар халык гаммәсенең бу турыдагы үлчәвен бик үк төзек, дөрес булмаган бер үлчәү итеп күрсәтте.

Шулай итеп, моның азмы, күпме тәэсире белән татар дөньясының бәгъзе почмакларында, хәтта Тукайның шагыйрьлеге турысында шөбһәнәлүләр туа язды, бәлки туды да.

Гомумән, татар гаммәсенең вә күбрәк өлеш татар зыялыларының зәвыкы дөреслеген Җ. Вәлиди вакытында үзенең «Тукай мәҗмугаи асаре»нә язган мөкаддимәсе (*кереш*) белән куәтли үткән булса да, бу янә тегенең тәэсирен җиңеп җитә алмады.

Хәзерге көндә дә татарның яшүсмерләре, бигрәк тә урта мәктәп укучылары арасында «Татар шагыйрьләре» дигән әсәрнең Тукай турысында зиһеннәрне чуалтырлык бәгъзе бер төшенчәләре һаман азмы-күпме үзенең тәэсирен күрсәтеп килгәнлеге күренә. Бу, аның Тукай хакында тарихыбызга салып калдырган бер шөбһәсе булып тора[1].

Мин «Татар шагыйрьләре»ндә Тукай тугрысында алынган үлчәүнең ялгыш вә какшаулы бер үлчәү булуын, бу урында маддә-маддә аерып күрсәтеп тормыйм. Бу хакта тәфсыйлатны (*җентекләү*) шагыйрьләребез турысында язылып яткан тәнкыйтьләремә калдырып, бу мәкаләмдә ялгыз Тукай турысында кыскача гомуми бер караш кына ясап үтәчәкмен.

II

Н. Фатов үзенең 1921 нче елда Пушкин хакында язган яңа тәнкыйди бер әсәрендә рус тәнкыйтьчеләренең Пушкин турысында бер-берсенә каршы төрле фикерләрдә булуларының бер сәбәбе итеп, Пушкин әсәрләренең мәгънәләрен аңлап җитүнең бик җиңел бер нәрсә түгеллеген күрсәтә. Моның өчен: «Пушкинны бик яхшы таныргa кирәк. Аны тану – аңлый алу өчен дә, гомумән, артык күп нәрсә белергә кирәк», – ди. Пушкинга бер генә төрле үлчәү белән якын барырга, аны бер генә яктан тикшереп карарга мөмкин түгел икәнен, бәлки аның күп яклы, күп кырыйлы, күп читле, күп төрле кыяфәтле булганын ныгытып әйтеп үтә. Аның даһи бер яңгыравык (гаксе сәда – эхо) булып, һәрнәрсәгә каршы өндәлгәнен, чакырылганын, рус берләшмә тереклегенең һәрбер яклары, һәрбер күренешләре аны кызыктырганын, ул һәрнәрсә турысында үз сүзен әйтергә теләгәнен, тәнкыйденә керешмәстән элек, бик нык күз уңына алып куя.

---

[1] Кем белә, 1913 нче елларда, Тукайның үзе исән вакытта, Тукай турысында, нинди бер сәбәп беләндер, сәлби юлдан киткән бу әдип, әдәбият вә шигырьне тикшерүдә марксизм ысулын кабул иткәннән соң бәлки элекке фикереннән кайткандыр. Ләкин шул бар: үткән ел «Татарстан»ның бер номерында Ф. Бурнашка каршы язган бер мәкаләсендә бу хакта һаман элгәреге фикерендә торганлыгына ишарә юк түгел иде.

Менә безнең Тукай турысында да мин татар җәмәгатенә каратып, шушы Фатов сүзләрен тәкрарлыйсым килә.

Тукайны, әлбәттә, шагыйрьлектә Пушкин белән тиңләштерә алмыйбыз. Пушкин янында Тукай бәлки бик кечкенә булып калыр. Ләкин, һәрхәлдә, татар җәмәгатенең, ул чактагы татар берләшмә вә мәдәни тереклегенең, гомумән, гыйльми вә мәдәни кузгалыш һәм үсүебезнең бөтен икътисади хәлләребезнең дәрәҗәсенә, үлчәвенә карап һәм шуның янына тагы Тукайдагы көчле чын шагыйрьлек талантын да кушып:

– Тукай һич шөбһәсез татарның Пушкины иде, – дия алабыз.

Әдәбиятны һәм бер халык шагыйрьләренең әдәби иҗатларын тикшереп, шуларның тарихи системасын мәйданга китерүдә яки шуларга бәһа куюда марксизм юлы белән китеп, иҗтимагыять һәм икътисад әсасендә (*нигез*) вә шундый шартлар астында торып тикшереп карасак, Тукайның күп яктан татарның Пушкины булганын аңлау бигрәк тә җиңел булыр.

Кыскасы, Тукайның шигъри иҗатларын дөрес аңлап, аның шагыйрьлек – сәнгатькәрлек талантына тугры бәһа куя белү өчен дә Тукайның үзен бик яхшы аңларга кирәк. Моның өчен янә күп нәрсәдән хәбәрең булу шарт. Моның өчен бигрәк тә татарның Тукай заманындагы берләшмә тереклегенең, гыйльми вә мәдәни хәрәкәтләренең, икътисади барышының бөтен яклары, һәммә катлаулары белән яхшы таныш булу кирәк. Татар халкының моң-зарлары, теләк вә өметләре, шатлык вә кайгылары яңгыраган һәммә почмакларны, барлык яшерен нокталарны белү кирәк. Чөнки Тукай әнә шуларның һәммәсенә чакырылган, һәммәсен үзенә алган, үзенә суырган һәм шуларны кире татар дөньясы өстендә яңгыратып калдырган бер шагыйребез ул.

## III

Тукайның вә аның шигъри иҗатларын тугры үлчәү белән яклаусыз тикшергәндә без менә нәрсәләрне күрәбез:

1) Тукай – табган (*табигый*) татарның иң беренче көчле бер сентименталист – романтик йөрәк шагыйре. Шуның өстенә ул, бу бабта татар өчен классик бер шагыйрь. Анда икенче дәрәҗәдә реалистлек тә юк түгел.

Йөрәк шигырьләрен дә (лирикада) иң күзәтелгән нәрсә: самимият, ягъни чын күңелдән булу, эчтән кайнап чыгу, йөрәк шигырьләренең чынлыгы-хакыйкате дә шунда. Тукайда менә бу хосусият төгәл мәгънәсе белән бар. Шуның белән бергә андагы бу самимият табигыйлек белән дә башкалардан күп аерым тора. Тагын бу бар: бәгъзе шагыйрьләребез кебек, Тукай аффект кешесе түгел, эмоция кешесе, ул шашмый, сабырлык белән уйлап кына таша, котырынмый, тилерми, ләкин һичвзлексез һаман дулкынлана.

2) Тукайда сүзләр бик оста да, шуның белән бергә бик табигый, бик урынлы сакланган булалар. Әйтергә мөмкин ки, Тукайда сүзләр чынлап аның фикер вә хисләре белән бергә ихтыярсыз

туалар. Анда сүз белән мәгънәне бер-берсеннән аерып булмый.

Шуның белән бергә Тукайның сүзләре, тәгъбирләре мәгънәгә тәмам тулып бүртенеп киләләр. Аның һәрбер сүзе бер яңа мәгънә, яңа хис, яңа кәеф вә зәвык күтәреп килә.

Мин, шагыйрьләрнең шигырьләрен тикшергәндә, иң элек аларның сүзләрен, тәгъбирләрен бәреп, чиертеп карыйм. Көчсез шагыйрьләрнең сүзләре, буш савыт кеби шыңкылдап торганы хәлдә, чын вә көчле шагыйрьләрнеке эче тыгызланып тутырылган савытларга охшап, дөңгелдәп торучан була.

Татар шагыйрьләре эченнән үзенең шигырьләрендә сүз вә тәгъбирләр менә шушы соңгы сыйфат белән бөтенләй аерым торган бер шагыйрьне эзләсәк, иң элек без Тукайга очрыйбыз. Бу урында аннан уздырган шагыйребез әле күренми.

Шулай итеп, бу яктан Тукай татар сүзләрен мәгънәгә дә күп баетты, аларның мәфһүмнәрен (*мәгънә, эчтәлек*) киңәйтте.

3) Тукайның бөтен шигырьләрендә аның үзлеге (шәхсияте, ягъни Тукайлыгы) бик ачык күренеп бара.

Бу хосусият янә көчле шагыйрьләрнең, бәлки, даһи сәнгатькәрләрнең хосусиятләреннән санала. Хосусан, әдәбиятта романтизм агымының бердәнбер таныган төп кануны да шушы ноктадыр.

4) Тукайның тел вә өслүбендәге аһәң һәм вәзен (*ритм*), кафия (*рифма*), тышкы вәзен, коры тышкы суык, ясалма бер аһәң генә түгел, бәлки бу анда рухтан – ми вә йөрәктән туган эчке вә тирән бер хосусият, ягъни бу андагы тәсаувырлар (*сурәтләү*), фикер, хис вә хыяллар арасындагы эчке – рухи бер сыйфат, аның фикер вә хисләре шулай оешканнар. Әнә, шушы хосусият Тукайның тел вә өслүбендә гәүдәләнгән.

5) Тукай хыялга бай һәм аның хыялы, хисе вә фикере кеби, уйнак хыял. Тукай тиз сизүчән һәм нечкә хисле бер шагыйрь. Ул Дәрдемәнд кеби фикер шагыйре түгел, хис шагыйре. Шулай булса да, аның хисләре фикер карамагы астында матур вә нәзек кыяфәттә гәүдәләнәләр. Дәрдемәндтә фикерләр йомшак хисләр белән бизәкләндерелгән булса, Тукайда хисләр фикергә чыланган була. Сәгыйть Рәмидәге кеби анда шашкынлык та юк, табигый вә түземле бер ташкынлык бар.

6) Тукай шаян, уйнаклы бер фикергә, шук-тынгысысыз бер хискә малик (*ия*), шуның белән бергә аның күз яшендә көлке, көлкесендә күз яше бар. Ачуында мәрхәмәт, ләгънәтендә шәфкать бар.

7) Тукайның йөрәкчелеге, ягъни хисе, көчәеп киткәндә үзенә һич тәкълид (*ияру*) мөмкин булмый торган табигый бер рәвеш ала.

8) Тукайның шагыйрьлек таланты һаман ачылганнан ачыла, көчәйгәннән көчәя барды. Ул үләр алдыннан да, шул хосусиятен күрсәтеп алды. Ләкин, ул үзенең истигъдадын (*талант*) ике сәбәптән тәмам ачып күрсәтә алмады. Берсе – бик аз гомерле булып, фәкать җиде еллык кына

бер әдәби тормышка ия булып кала алуы; икенче – вакытында тиешле тәрбия бирелә алмау һәм белгән-күргәннәрнең аз булуы, мәгълүматның сайлыгы.

Тукай хакында:

– Тукай вакытында үлеп яхшы итте... Аның шигъри көче – таланты сүнә башлаган иде инде... – шикелле сүзләр дә вакытында һавага очыртылмады түгел. Ләкин бу сүзләр Тукайны аңлый алмаганлыктан яки Тукайның матур «нәгыш»ен күрәлмәгәнлектән яисә тагын башка берәр төрле сәбәпләрдән генә булырга мөмкин.

Әйе, берничә еллар буе яшь кенә көйгә бер тындырмыйча йөрәгеңне өзлексез кимереп торучы бер авыруга мөбтәля булсаң *(дучар булу)*, соңра бер үпкәң тәмам череп бетеп, икенчесе дә ярым көчен югалткан булса, шагыйрьлек куәте, таланты, даимилеге кими башлаган яки сүнмәгән кайсы бер шагыйрьне күрсәтә алырбыз? Хосусан: «Мәгънәне матдә тудыра; бөтен мәгънәви – рухи көч вә истигъдад матдәнең көченнән, аның хосусиятеннән хасыйл була» дип белүче материалистлар бер шагыйрьнең җисмани куәте, матди сәламәтлеге кимү сәбәпле булган бер хәлне аның «шагыйрьлек көче кимү, таланты сүнү» дип карый алмаячаклар.

Болай карау ялгыз матдәдән аерым бер рухи көч яки «рух» дигән нәрсәнең барлыгына инанучы идеалистлар өчен генә мөмкин бер нәрсә.

Шуның өстенә тагы Тукайның, мәсәлән, үләреннән бер ел яки берничә ай гына элек сөйләгән шигырьләре аның куәте сүнгәнлекне түгел, артканлыкны күрсәтәләр[2].

Ялгыз бу вакытларда анда күрә торганыбыз шул ки, үләрен үзе алдан ачык сизеп торуы сәбәпле, Тукайда чынлап та бер өметсезлек туды.

9) Тукай тезмәдә заманында татарга яңа садә әдәби бер тел эшләп бирде. Безне җиңел әдәби сөйләргә, садә бер рәвештә әдәби көйләргә өйрәтте.

Анда чәчмәдә дә садәлек вә осталык күрәбез. Хәтта чәчмәсе тезмәсеннән дә җиңел вә садәрәк. Соңыннан күп шагыйрьләребез тезмәдә аңа ияреп, аның юлы белән киттеләр; аның тәэсире астында эшләп килделәр, яки көйләре башта аның эзеннән барып, соңыннан үзләренә истикълалият (*бәйсезлек*) казандылар.

Янә ачык әйтик: Тукай үз заманында үзенә махсус бер әдәби агым, бер шигырь мәктәбе тугдыра алды. Заманында татарда аның мәктәбенә мәнсүб (*караган, бәйле*) күп кенә шагыйрьләр бар. «Гыйффәт» бөтенләй аның шәкерте. Хәтта хәзердә дә әле Тукай шигырь мәктәбе байтак яшьләребезгә тезмәдә, тел вә өслүбтә,

[2] Мәсәлән, аның 1912 нче елдагы «Үтенеч», «Дошманнар», «Кичке теләк», «Ваксынмыйм», «Сагыныр вакытлар», «Буран», «Казан вә кабан арты», «Хөрмәтле Хөсәен ядкәре», «Авыл мәдрәсәсе», «Дин вә гәвам»ы, «Тәмсил» вә башкалалары; үләр елында: ягъни 1913 нче елда язган «Шиһап хәзрәт», «Даһигә»ләре һәм үләреннән өч ай элек язган «Хәстә хәле» дигән шигыре белән, үләреннән бер генә ай элек язган «Кыйтга»сы безгә Тукайның хәтта үпкәләре череп кабергә якынлашкан чагында да әле һаман аның шигъри куәте кимемәгәнен күрсәтәләр.

тасвир җәһәтләрендә, садәлектә тәэсирсез калмаган күренә.

10) Тукай безгә үзенең оста тәрҗемәләре белән гарәп вә бигрәк тә, рус әдәби җәүһәрләрен күчерде. Безгә рус шигъри иҗат дөньясының ишеген ачып бирде. Безне русның Пушкин вә Лермонтовларына якынлаштырды. Байрон вә Толстойлары һәм башкалары белән таныштырды.

11) Тукай бездә Шәмсетдин суфи, Әбелмәних, Һибәтулла ишан кеби иран, төркестан һәм госманлыларга сукырларча вә ялган тәкълидтән, тәсаувыф юлыннан, тәгъбир мөмкин булса, бәлки безне «ялган классиклык»ыбыздан аерып алды. Безнең үзебезгә махсус үз әдәбиятыбызның, үз эпосыбыз һәм үз йөрәкчелегебез (лирикабыз) тууына тезмәдә башлап юл салды.

12) Тукай татар әдәбиятында беренче мәртәбә шигъри һөҗү (*сатира)* ишеген ачып, шуңа ачык, киң бер юл ясады. Чын әдәби һөҗүнең безгә дөрес үрнәген күрсәтте.

IV

Инде Тукайга иҗтимагый яктан бер күз йөртеп карыйк:

1) Тукай татар җәмәгатенең билгеле бер дәвердәге бергәлек тормышында күрелгән күп хәлләрне үзенең шигырьләрендә гәүдәләндерә алды. Аларга мәңгелек тарихи хәят биреп калдырды. Шулай итеп, ул замандагы иҗтимагый мохит вә тормышыбызның һәр ягына чакырыла белеп, аның һәр ноктасын шигырьләрендә бик кыска, җыйнак рәвештә күләгәләндерә алу кабилиятен без татар галәмендә тезмәдә беренче мәртәбә Тукайда күрдек. С. Рәми белән Дәрдемәнд, бу турыда аннан күп артталар.

Тукайның күз яшьләре, дәрт вә ачулары, фикер вә хисләре, өмет вә теләкләре – һәммәсе заманындагы саф татар бергәлек (иҗтимагый) тормышыннан сызылып алынган нәрсәләр. Ул әнә шуларны татар халкына җиңел, ачык бер телдә, тәкәллефсез (*кыланусыз, табигый*) һәм тәмам шигъри бер рәвештә бирә алды.

2) Тукай заманы бездә, ягъни татарларда, буржуазия сыйныфының тәмам аерым бер сыйныф рәвешен алып көчәйгән; Шиһаб Мәрҗани вә Каюм Насыйрилардан башланган уяну-яңару дәверебезнең милли хәрәкәт дәверенә алмашынып, шул юлда куәт ала башлаган һәм буржуазиянең шушы хәрәкәтне үзенә корал итәргә тотынган бер чагы иде. Шул вакытта Тукай үзенең кискен шигырьләре белән менә нәрсәләргә каршы көрәш башлады:

а) алтын, байлык һәм байлар;

б) руханилар, ишаннар, дин;

ә) үз мәнфәгатьләре өчен халыкны алдаучы милләтчеләр;

т) байлар тирәсендә бөтәрләнүче мөхәррирләр;

ж) иске мәдрәсә, иске фикер, иске тәрбия, иске ысул, иске гадәт вә, гомумән, татардагы бөтен искелек вә тәгассыб (*фанатизм*);

х) истибдад (*чикләнмәгән хакимият, деспотизм*) вә сәяси золым;

д) татарларда хатын-кызларның хокуксызлыгы, вә аларның ирләр кулында кол булулары һәм башкалар.

Менә шуларның һәркайсына Тукай төрле юллар белән вә үз телләре, үз өслүбләре аркылы шәфкатьсез һөҗүм ясады.

Тукайда һәрнәрсәдән бигрәк гаммәгә якынлыкны, ярлыларга дуслыкны күрәбез. Тукайның үзенең дә кызганыч бер ятимлектә кагылып, сугылып үскән булуы һәм шуның өстенә ул соңра үзе матбага эшчесе – наборщик булып хезмәт иткәнлеге дә безгә мәгълүм. Ул шул вакытта матбага эшчеләрен ихтилалга (*фетнә*) да котырткан. Аларны үз хакларын дауларга өндәгән һәм заманында һаман сул канатта булып килгән. Шуның белән бергә, Тукайның бөтен гомере ярлылык, мохтаҗлык белән ачлы-туклы яшәп үткән.

Менә бу хәлләр Тукайны чарасыз мәзлумнар (*изелгән*) сафына куйды, әлбәттә, бу турыда безгә аның:

*Яратырга ярый кышны; вә ләкин*
*зәмһәрире бар;*
*Киемсез калтырап торган мәсакине,*
*фәкыйре бар.*
*Яратырга ярый җәйне; матур ул*
*анда зур ямь бар;*
*Вә ләкин таш бинасы юк,*
*фәкыйрьләргә җәһәннәм бар.*

дигән мисрагъларыннан да ачык булган нинди бер мисал эзләп торырга хаҗәт бар.

Аның «Сагыну вакытлар»ындагы:

*Бер теләнче керсә йортка син бирә*
*алсаң бер телем;*
*Әй була җанга хозур! Шатлыктан*
*әйләнми телең.*

мисрагълары һәм:

*Бер сүз әйтергә саранлансак*
*гакыллы ярлыга;*
*Гөл кеби сүзләр чәчәбез, акчалы*
*ахмакка без.*

дигән кеби шигырьләре безгә Тукайның нинди шагыйрь булганын бик яхшы ачып бирә алалар.

Шуларга тагы хәтта 21 нче елдагы кеби, дөньяда мисле күрелмәгән бер дәрәҗәдә дәһшәтле ачлык фаҗигаләре астында калган чакта да һичбер татар шагыйре охшашын тудыра алмаган бер шигырен, ягъни «Көзге җилләр»ен кушсак, Тукайның гаммә шагыйре булганлыгына шигебез калмас. Аның бу шигыре вә хосусан андагы:

*– Иң сөекле эшче әүладым бу ел ач*
*калды дип,*
*Изге шәфкатьле анабыз, мәрхәмәтле*
*җир җылый.*
*Куйсалар монда корткалар төшкән*
*тешен алтын белән,*
*– Бер телем икмәк! дип, анда назлы*
*нечкә бил елый.*
*Бер сынык юктан гына үлгән таза*
*ирләр күреп,*
*Җан алуга кызганудан анда газраил*
*елый.*

мисрагълары кайсы татар шагыйрьләрен генә түгел, бәлки гомумән үзенең самимилеге, чын, эч күңелдән саф мәхәббәт белән чыккан булуы үткен вә кискенлеге белән кайсы бер милләт шагыйрьләрен үзенә кызыктырмас? Аларның кайсыларын шигърияте белән үзеннән көнләштермәс?

Тукай үләреннән бер ай элек үзенең кайсы сыйныф шагыйре булганын үз теле белән дә бик ачык итеп:

*Булды юлда киртәләр, этдән*
*күбәйде дошманым,*
*Чөнки залимләрне, өстеннәрне*
*яклый алмадым.*

дип әйтеп китте, фәкать ул:

*Кайтмады үч, бетте көч, сынды*
*кылыч, шул булды эш,*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны*
*пакьли алмадым.*

дип «залим вә өстеннәр»дән үчен ала алмыйча үлүгә мәҗбүр булган иде. Инде эшче – ярлы халкыбыз Тукай каберенә барып:

– Кабереңдә тыныч бул, Тукай! Залим вә өстеннәрдән ала алмаган үчеңне инде менә синнән соң без алдык. Безнең өчен син ачынган, янган идең. Инде без шуның өчен синең кабереңалдында сиңа хөрмәт күрсәтүгә үзебезне бурычлы саныйбыз, дисәләр, бик урынлы булачактыр.

***Габдрахман Сәгъди.***
*1923 ел, 28 март. Ташкент.*
*Журнал «Безнең юл» 1923 ел, № 8–9 (март, апрель).*

*Текстны басмага филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*
*Л.Ш. Гарипова әзерләде*

УДК 821.512.145

*М.И. Әхмәтҗанов*

## ТУКАЙ ПОЭЗИЯСЕ ТАШЪЯЗМАЛАРДА

Татарское эпиграфическое искусство существует в Поволжье с XIII века. Иногда на каменных надгробиях оказываются исторические сведения, которых нет ни в одном государственном архиве, или уникальные образцы поэзии. Среди эпитафических надписей, обнаруженных во время экспедиций, более 10 связаны со стихами Г. Тукая. Эти надписи в основном сводятся к пяти стихотворениям поэта – «Разбитая надежда», «Завещание», «Пара лошадей», «Дитя в раю», «Родной язык». Самая ранняя из найденных надписей датируется 9 ноября 1914 года и на ней приведены строчки из стихотворения Тукая «Завещание». Подобные надписи свидетельствуют о глубокой народности творчества Тукая.

**Ключевые слова:** Тукай, поэзия, история, память, наследие, эпитафические надписи.

Тукай иҗатының халыклашуы – аның халык кулында бу замангача сакланган, шагыйрь үзе исән чагында ук басылган китапларының, археографик экспедицияләр барышында, XXI гасыр башына хәтле табылып торуында. Безгә мондый басмалар элек тә күп очрады һәм хәзер дә тапкалап торабыз.

Шагыйрь иҗатының популярлыгы – аның әсәрләренең 1930–40 нчы елларгача кулъязмалар хәлендә, гарәп графикасында укылуында. Эш барышында бу юнәлештә дә шактый ачышларга тап булырга туры килде.

Бөек Тукай иҗатының халыклашуын шулай ук, аның татар кабер ташлары йөзендә уеп язылган шигырь үрнәкләре сөйли.

Минем үземә Петербургтан алып Курган өлкәсенә хәтле булган киңлекләрдә мәгълүм булган меңләп татар зиратлары ташбилгеләре белән танышырга туры килде. Сәяхәтләр, 1972 елдан 2013 елгача дәвам итеп, яңа тарихи чыганакларга баетты.

Татар эпиграфика сәнгате XIII гасырдан бирле Идел буенда традиция буенча яшәп килә. Аның ташбилгеләре йөзлекләрендә бер генә дәүләт архивларында теркәлмәгән тарихи хәбәрләр, поэзия үрнәкләре сакланып калган. Алар арасында бөек шагыйребез Г. Тукай иҗатыннан да шигъри үрнәкләрне табарга мөмкин.

Бүгенге көндә Габдулла Тукай шигырьләре белән бәйләнеше булган уннан артык ташбилге табылды. Ул эпитафик язмаларның, нигездә, шагыйрьнең биш шигыре («Өзелгән өмид», «Васыятем», «Пар ат», «Бала оҗмахта», «Туган тел») белән бәйләнештә булуы мәгълүм. Ләкин алар эпитафик текстларда аерым строфалар рәвешендә генә катнашалар.

Истәлекле ташлар сакланган зиратлардан – Казан, Уфа, Арча, Буа, Петербургтагы Волков зиратын һәм Сембер өлкәсенең Барыш

районы Зөябашы авылы зиратын атарга мөмкин.

Тукай шигыре белән бәйле иң иске ташбилге Буа шәһәре зиратында саклана. Без аны 1981 елның октябрь аенда барып тапкан идек. Шагыйрьнең «Васыятем» дигән шигырен 1914 елның 9 ноябрендә вафат булган Мостафа Хәлиулла улының Бибифатыйма исемле кызы кабер ташыннан укыдык. Анда түбәндәге юллар гарәп хәрефләрендә каллиграфик матур рәвештә язылган:

«Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! Бар,
юнәл, кит Тәңреңә!
Бирдең арканңы моңарчы, инде бир
бит әмренә!»

Таш биек итеп, кирпечтән эшләнгән постамент өстенә утыртылган. Аны Буа шәһәрендә яшәгән кабер ташлары кисеп ясаучы оста, татар матбугатында 1917 елга кадәр язышкан журналист, педагог, тарихчы Гарифҗан Хәсән улы Вәлиди (Гарифҗан Буави) эшләгәнлеге дә мәгълүм булды. (Гарифҗан Буави үзе 1879 елда Буада укымышлы гаиләдә туа, Буа мәдрәсәсендә белем ала, үзе дә укыта, татар матбугатында мәкаләләр бастыра; 1910 еллардан Буада яши һәм татар мөселман эпиграфик ядкәрләрен эшләү белән шөгыльләнә, гомеренең соңгы елларында Буадагы татар мәктәбендә укыта. 1946 елда вафат була. Кабере билгеле.) Тукай шигырьләрен ташка кисеп язган башка осталарның исемнәре мәгълүм түгел.

Тарихы буенча икенче урында Әлмәт шәһәре иске татар зиратында 1925 елның 12 маенда вафат булган сабый бала Атлас Хәбибулла улы каберенә утыртылган ташбилге тора.

Ташбилгедә шагыйрьнең «Бала оҗмахта» дигән шигыре гарәп хәрефләрендә тулаем диярлек, бераз үзгәрешләр белән генә язылган. Ташбилгенең тулы тексты:

Май 12, 1925 –
Атлас Хәбибулла улы вафат көне –
шәүвәл аеның 22 сендә.
«Мин хәзер оҗмах түрендә,
Бер матур хур иркәли,
Мин җуанмыймын, җылыймын,
Син түгелсең, дим, әни.
Ул гыйльманнар, җаныма килүб,
Миңа бирәләр тәти.
Мин җуанмыймын, җылыймын,
Сез түгелсез, дим, әти»

Г. Тукайның бу шигыре аның биштомлыгына (II) кертелгән.

Әлеге шигырь беренче мәртәбә шагыйрьнең «Җан азыклары» исеме белән 1912 елда басылган китабында дөнья күргән була.

Шагыйрьнең бу әсәренә карата бирелгән искәрмәдә Г. Тукайның: «Үземә таныш бер кешенең, күңлемә якын бер баласы үлгәч, мәрхүм баланың кабер ташына нәкыш итәргә дип язган идем», – дигән сүзләре бар.

Әлеге искәрмәдән Тукайның татар ташбилгеләрендә шигъри багышлаулар язу традициясе булуын яхшы белгәнлеге аңлашыла. Ихтимал, ул шигырь шул вакытта ук кабер ташына язылып куелгандыр, ләкин Казан татар зиратларында хакимияттә утырган шәһәр хакимнәренең битарафлыгыннан да файдаланып, истәлекләрне җимерү күренешләре күзәтелә. Андый шартларда сабый Атласныкы шикелле ташларның Казанда саклап калу ихтималы чикле булды.

Шагыйрьнең ташбилгеләрдә иң күп чагылыш тапкан строфалары аның атаклы «Өзелгән өмид» шигыреннән алынганнар. Бу шигырь беренче мәртәбә 1910 елның 29 ноябрендә Оренбургта чыгучы «Вакыт» газетасы битләрендә дөнья күргән һәм татар ташбилгеләрендә ул, беркадәр үзенчәлекләр белән бирелеп, аның вариантлары буларак яши башлый.

Аның хәзерге ташлардагы безгә билгеле булган тәүге варианты тарихы 1961 елга карый.

Беренче үрнәк Казандагы Яңа бистә зиратында Зарипова Нәсимә Гали кызы (1910–1961) каберендә табылды. Ул кирилл хәрефләре белән язылган:

«Бар нәрсәдән кадерле,
Әнкәем, кабрең ташы.
Шуңа аксын күз яшемнең
Иң әче һәм татлысы».

Шигырьнең икенче үрнәге дә Казандагы Яңа бистә татар зиратына күмелгән (Байков Риф Рәхимьян улы. 16.05.1932–27.06.1964) ташбилгесендә сакланган:

«Бар күңелләрдән йылы, йомшак
Синең кабрең ташы.
Шунда тамсын күз яшемнең
Иң ачы һәм татлысы».

Шигырьнең өченче үрнәге Татарстанның Арча шәһәре Яңа татар зиратында М.Т. Гыйлаҗетдинов (1910–1965) ташбилгесендә кабатлана:

«Бар күңелләрдән
Җылы, йомшак,
Әни, кабрең ташы.
Шунда тамсын
Күз яшемнең
Иң ачы һәм татлысы».

Шигырьнең дүртенче үрнәге Уфа шәһәрендәге Иске татар зиратында Вәлиуллина Суфия Зыятдин кызы (1926–1971) каберенә куелган ташбилгедә саклана:

«Һәрвакыт килеп кочаклыйм,
Мин үбәм кабрең ташын.
Мин кайнар йөрәгемнән
Кабреңә түгәм яшем».

Текст 2005 елның 28 июлендә Уфа шәһәренең борынгыдан сакланып килгән татар зираты ташбилгеләрен өйрәнеп йөргән көннәрдә язып алынган иде.

Шигырьнең бишенче үрнәге дә Уфаның Иске татар зиратындагы ташбилгедән күчереп алынды. Ул истәлек Ирек Байбурин (1959–1976) кабере өстенә утыртылган:

«Бар күңелләрдәрн җылы, йомшак
Булсын синең кабрең ташы.
Шунда тамсын күз яшебезнең
Иң ачы һәм татлысы».

Шигырьнең алтынчы үрнәге шулай ук Уфа шәһәренең Иске татар зиратында Кәтиева Зөләйха (1883–1977) ташбилгесендә саклана:

«Син безнең йөрәкләребездә соңгы
Сулышыбызга кадәр сакланырсың.
Бар күңелләрдән йылы, йомшак
Синең кабрең ташы».

Габдулла Тукайның «Өзелгән өмид» шигыренең бер строфасы бер-берсеннән йөзләрчә чакрым ераклыкларда күмелгән кешеләрнең баш очларына куелган ташбилгеләрдә уелган. Бу – татар халкының шагыйрь иҗатына мәхәббәтен дә, аны олылавын да чагылдыра. Шагыйрьнең кабер ташларындагы текстлары кешеләр бакыйлыкка күчкәч, исәннәргә алар хакында хәтерне

саклауга көч бирәләр, рухи таяныч та булып торалар.

1986 елның 4 июнендә шагыйрьнең шул ук «Өзелгән өмид» шигыреннән алай бик еш кабатланмаган җиденче строфасы С.-Петербург шәһәрендәге Волково зиратының мөселман почмагында күмелгән Вельшаков Ренат Хасанович (1925–1980) каберендәге ташбилгедән күчереп алынды.

«Очты дөнья читлегеннән тарсынып
күңлең кошы.
Шат яратса да җиһанга ят яраткан
раббысы».

Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыреннән бер строфа Татарстанның Арча шәһәре Г. Тукай урамы янында ачылган Яңа татар зиратындагы Г.З. Зарипов ташбилгесенә язылган:

«Сау бул инде, хуш,
Бәхил бул – и минем
Торган җирем.
Мин болай, шулай
итәм, дип, төрле
Уй корган җирем».

Болардан тыш Сембер ягындагы Зөябашы авылы зиратында Г. Тукайның «Туган тел» шигыре язылган ташбилге дә бар.

Татар эпитафик поэзия хәзинәсендә хәзергә 500 дән артык текст тупланды. Анда, Г. Тукай әсәрләреннән тыш, Һибәтулла Салихов, Утыз Имәни кебек борынгы шагыйрьләр әсәрләре һәм XX гасырда иҗат иткән сүз осталарының әсәрләре бар. Димәк, татар ташбилгеләре поэзия китапларындагы әсәрләр белән бәйләнештә яши. Һәм ул гомуммилли поэтик хәзинәбезне тулырак күз алдына китерергә ярдәм итә. Татар халкы, шагыйрьләрнең әсәрләрен турыдан-туры күчереп алмыйча, үзеннән дәниләрдер өстәп язарга тырыша. Бу әдәбиятыбызның бер яшәү закончалыгы. Мәсәлән, аеруча XVII–XIX гасырлардагы татар шагыйрьләренең әсәрләре һәрвакыт шундый өстәмәләр белән баетылган хәлдә табылалар.

**Әдәбият**

*Тукай Габдулла.* Әсәрләр: 5 томда. Т. 2. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.

Тукай турында истәлекләр. Казан : Татар. китап нәшр., 1986. 255 б.

Археографик экспедицияләр һәм Габдулла Тукай хатирәләрдә. Казан, 2015. 132 б.

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 77

*Д.И. Әхмәтова*

# ӘСТЕРХАН ФОТОГРАФЫ И.М. БОЧКАРЕВ

На сегодняшний день известно около двадцати прижизненных фотографических изображений Г. Тукая. Не все авторы фотографий установлены. Однако сохранилось четыре имени мастеров, создавших снимки Г. Тукая, это В.П. Онуфриев из Уральска, С.И. Иванов и И.М. Якобсон из Казани, И.М. Бочкарев из Астрахани. Статья освещает жизнь и деятельность фотографа И.М. Бочкарева.

**Ключевые слова:** И.М. Бочкарев, фотографии Г. Тукая, Астрахань начала XX в.

Габдулла Тукайның Әстерханга баруын шагыйрьнең иҗатын өйрәнүчеләр шактый җентекләп тасвирлаганнар [Загидуллина]. Әмма Тукайның бу сәяхәте турында ачыкланмаган әле шактый «ак таплар» да бар. Мәсәлән, Тукайның Әстерханга килүендә турыдан-туры мөнәсәбәте булган, шул шәһәрнең фотографы Иван Митрофанович Бочкарев шәхесе шагыйрь иҗатын өйрәнүчеләрнең игътибарыннан читтә калган. Әстерхан татарларын сурәткә төшерүе ягыннан да Бочкарев иҗаты этнографлар өчен кызыклы һәм файдалы булырга мөмкин.

И.М. Бочкарев (1872, Сарытау – 1920, Әстерхан) Сарытауда туа. Аның тәүге сурәтләре (XIX гасыр азагы) Тагил, Барнаул, Урал һәм Себернең башка шәһәрләрендә саклана. Үзенең шәхси фотография салоны булмаганлыктандыр инде, ул күбрәк сәяхәт иткән, юлда сурәткә төшергән. Бочкарев үзен шулай ук тасвирый сәнгатькәр, декоратор, популяр открыткалар нәшер итүче буларак та таныткан. 1989 елда ул Пермь губернасыннан Әстерханга килә. Аның беренче хатынының да фотография эшенә катнашы бар. Әстерханга килгәч, Бочкаревлар гаиләсенең эше шактый алга китә. Биш елдан соң, 1903 елның 24 июнендә, сарытау мещаны Анна Петровна Бочкарева шәхси фотоательесын ачу өчен таныклык ала һәм үзе дә фотография белән шөгыльләнүче коллеж регистраторы Михаил Алексеевич Козлов өендә, Кутум елгасы буендагы Сапожников күпере янында ателье ача. Эш яхшы оештырылган була, шуңа да иҗади процесска кереп китү зур авырлыклар тудырмый. 1903 елның 10 августында «Астраханский вестник»та белдерү чыга: «Художественное и быстрое исполнение всех фотографических работ: портретов, групп и увеличений на невыцветающей роскошной белой глянцевой бумаге, а также платиноматовые снимки и миниатюрные марки с портретами. Имеются в продаже виды г. Астрахани» [Нагайнина]. А.П. Бочкарева үзенең ательесы белән бер ел идарә итә. Фотографияләр фирма бланкасында «Набережная р. Кутума, дом М.А. Козлова» адресы белән

нәшер ителәләр. Ателье хезмәтләрнең киң ассортиментын тәкъдим итә һәм аларны әледән-әле арттыра бар. Бер елдан аз гына вакыт үтүгә А.П. Бочкаревларның ательесында яңа кызыклы тәкъдим барлыкка килә! «Изготовляются семиэмалированные, в изящной оправе броши, запонки, брелоки и проч. с фотографическими портретами. Исполнение через 3 дня. Броши, запонки от 3 руб. Изящные подарки к празднику» [Нагайнина].

1904 елда Анна Петровна ательесын үзенең иренә тапшырырга карар кыла. 1904 елның 5 августында ул Әстерхан губернаторына үтенеч белән мөрәҗәгать итә: «Желая передать фотографию свою, находящуюся в г. Астрахани в третьем участке по набережной реки Кутума в доме Козлова, мужу своему имущественно в полное владение, просим переменить свидетельство моего получения из канцелярии Вашего Превосходительства от 24 июня 1903 года № 728 на имя моего мужа Ивана Митрофановича Бочкарева со возвратом моего при получении мужем оного свидетельства. Жена саратовского мещанина Анна Бочкарева. Саратовский мещанин Иван Митрофанович Бочкарев. 5.8.1904 года» [Нагайнина]. Мондый очракларда тиеш булганча, Иван Митрофанович полициядә тикшеренү уза, фетнә тапмыйлар, полицмейстер сер итеп кенә хәбәр итә: «Саратовский мещанин Иван Митрофанович Бочкарев поведения, нравственных качеств хороших, под судом и следствием не состоял и не состоит, в Астрахани проживает шесть лет, в Пермской губернии Нижнетагильском заводе три года, остальное время жил на родине» [Нагайнина]. Нәтиҗәдә, 1904 елның 3 сентяберендә 32 яшьлек И.М. Бочкарев фотоательеның хуҗасы була.

И.М. Бочкаревның фото эше уңышлы гына алга китә, киңәя. Аның ательесы яңа аппаратлар белән җиһазландырыла, павильонда күп төрле фон һәм мебельләр кулланыла. Төрле фотосурәтләрдән тыш портретларны светопись, карандаш, буяулар һәм һәртөрле модалы яңалыклар – фото – эмаль; алтын, көмеш, «француз алтыны» кысасындагы булавкалар, брошкилар, брелоклар белән зурайталар. Бочкарев Әстерхан һәм аның тирә-юне сурәтләнгән ачык хатлар чыгаруны җайга сала [Марков, Львов]. Башка наширләрдән аермалы буларак, ул окрыткаларын үзенең шәхси фотосурәтләреннән эшли. Алар типография ысулы (фототипия) ярдәмендә күп тиражлар белән чыгарыла. Шулай ук шәһәр күренешләрен, «Аркадия» бакчасын, матур көнчыгыш базарларын чагылдыручы аз тиражлы фотооткрыткалар да нәшер итеlә. И.М. Бочкарев шәһәр каналлары сериясеннән күп кенә сурәтләр эшли. Алар – Кутум елгасы буендагы Благовещенск монастыре һәм Варвациев каналындагы Изгеләр Петр һәм Павел әрмән соборы.

И.М. Бочкарев бүгенге көндә этнография буенча кыйммәтле әһәмияткә ия булган Идел буендагы авылларны сурәткә ала. Ул кыргыз авылларына һәм калмык

далаларына барып, аларны да фотога төшерә. Ә иң яратканы – балыкчылар. Фотографның бу темага караган сурәтләре шактый. 1871 елда Александр II нең атаклы Сапожниковлар балык хуҗалыгына килү истәлегенә багышлап ике открытка нәшер итә. Анда калку урында торучы агач бина сурәтләнгән һәм, аның янәшәсендә мондый язу бар: «Исторический дом на старинном Житнинском промысле, где останавливался и смотрел на рыбную ловлю и на море император Александр II» [Нагайнина], һәм, ниһаять, Бочкарев Каспий диңгезеннән елга буйлап өскә, Идел буйлап сәяхәткә чыга. Утыздан артык открыткалар сериясе Тинаки курортында дәвалану һәм ял итүгә багышланган.

Мастер фотография сәнгате темасына да зур игътибар бирә. «Әстерхан янындагы җиләк-җимеш бакчасы» дигән открыткада кызыклы сюжет ачыла: агачлар арасындагы юлда, күп кешеләрнең игътибар үзәгендә фотограф үзе.

Открыткаларны сату эше И.М. Бочкарев фотографиясендә, шулай ук Әстерханның Бочковский, Бирюков, Моженовлар кибетләрендә оештырыла.

XX гасыр башында Бочкарев ательесы шәһәрдә иң яхшылардан санала. Фотографның эшләре берничә халыкара күргәзмәгә җибәрелә һәм икесендә бүләкләргә лаек була. Мәсәлән, 1905 елда ул, Брюссельдә узган күргәзмәдә катнашып, Зур көмеш медальгә, ә 1906 елда Антверпендагы күргәзмәдә Алтын медаль, шәрәфле хач һәм дипломга лаек була.

1909 елда И.М. Бочкарев үзенең ательесын, Макаров йортыннан шәһәр үзәгенә – Гостино-Николаевский чиркәве янындагы Марков йортына күчерә. Бу адрес буенча ателье ике ел эшли, соңыннан ул Бочкаревның яңа фотография бүлегенә әйләнә. Нәкъ менә шушы ательеда сөекле шагыйребез Габдулла Тукай фотога төшәргә мөмкин дә инде...

1909 елда И.М. Бочкарев Әстерханга гастрольгә килгән, тумышы белән Казан кешесе булган Федор Иванович Шаляпинны фотога төшерә. Бөек җырчы Әстерханның кумыс сата торган кибетенә илтүче баскыч янында, дуслары янәшәсендә сурәтләнгән. Почмакта эте – җырчының яраткан сеттеры утыра. Бу фотография аз билгеле.

1971 елның 15 августында И.М. Бочкаревның фотоательесы Католическая (Бабушкина) урамындагы Чернов мунчасына каршы якта урнашкан, «фотография өчен махсус мода стилендә» төзелгән яңа йортка күченә. Аның беренче катында – кабул итү бүлмәсе, зал, кабинет, ашханә, йокы бүлмәсе, зур пыяла веранда. Биредә фотограф хатыны белән яши (бу вакытта ул икенче тапкыр өйләнгән, хатыны – Әстерханның мәгълүм җәмәгать эшлеклесе һәм эшмәкәре Степан Леонтьевич Николаевның кызы – Екатерина). Икенче катта «сурәткә төшү өчен пыяла америка павильоны төзелә». Янәшәсендә янә өч бүлмә, анда өч фотограф һәм ретушер эшли дә, яши дә. Ишек алдында бер һәм ике катлы ике агач флигель (өй кырына терәтеп салынган бина) һәм лапас.

Иван Митрофановичның күптәнге хыялы тормышка аша – шәхси йорты, бик шәп җиһазланган фотография ательесы һәм тасвирый сәнгать белән шөгыльләнү өчен остаханә. 1912 елдан фотоательеның рәсми адресы: «Католическая урамы, шәхси йорт».

Фотографны, үз эшенең остасы буларак, губерна тарихының елъязмасына кирәрлек вакыйгаларны фотога төшерү өчен еш чакыралар. Фотограф тормышында иң эшлекле, иң нәтиҗәле чор башлана.

И.М. Бочкарев Әстерхан җирендә булган бик күп мөһим тарихи вакыйгаларны сурәткә төшерә. Алар арасында 1913 елның июнендә Бөек кенәз хатыннары Мария Александровна һәм Мария Павловналарның Әстерхан губернасына килүләре дә бар.

И.М. Бочкарев Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында иҗтимагый җыелыш клубы бинасында урнашкан хәрби лазаретны фотога төшерә. 1916 елның 7 октябрендә ул шәһәр оешмалары йортында узган Георгиев кавалерлары җыелышын тарихта калдыра. 1916 елда фотографны Төркестан качакларын сурәткә төшерү өчен чакыралар. Качакларны күчерү һәм урнаштыру күренешләре сурәтләнгән уникe аерым фото сериясе барлыкка килә.

Иван Митрофанович гаять талантлы кеше була. Ул фотография белән генә шөгыльләнеп калмый, ә бәлки сынлы сәнгать өлкәсендә дә үзен талантлы мастер итеп күрсәтә, күп кенә сәнгать күргәзмәләрендә катнаша. Күп еллар дәвамында Әстерхан сәнгать түгәрәгенең әгъзасы була. Әлеге түгәрәккә нигез салучы кеше – танылган рәссам Борис Михайлович Кустодиевның укытучысы Павел Алексеевич Власов.

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң, фотографның тормышында авырлыклар башлана. Католическая урамындагы ательены хөкүмәткә алалар. Дөрес, ателье эшен әле дәвам итә. Иван Митрофанович гади хезмәт кешесе булудан туктап, «буржуй» ярлыгына ия була. Ул яраткан эше белән күпмедер вакыт шөгыльләнә, әмма инде даими түгел. Аның ательесы 1920 елларга кадәр эшли һәм иң ахыргылардан булып ябыла. Тиздән Иван Митрофановичның бик нык яраткан хатыны да үлә, аларның балалары булмый. Бочкаревның соңгы фотографиясе 1920 елның 12 февралендә төшерелә. Фотографның алдагы язмышы билгесез.

И.М. Бочкарев безгә, беренче чиратта, 1911 елның язында Әстерханга килгән Габдулла Тукайны фотога төшерүче һәм аның әсәрләре буенча фотооткрыткалар эшләгән шәхес буларак билгеле һәм кадерле. Бочкарев Әстерхан губернасының Калмык базары авылы (Калмыцкий рынок) укытучысы Шәһид Гайфетдинов (Гайфи) (1881–1925) белән дус була. Тукай Әстерханга килгәнче үк, Шәһид Гайфи популяр әдәби әсәрләрне иллюстрацияләү, шул ук вакытта, аларны татар театрын пропагандалау максатында файдалану өчен фотооткрыткалар сериясен уйлап чыгара. Ул сюжетлар таба,

гримлана, ә Бочкарев сурәткә төшерә. Иван Митрофанович әдәби әсәрләрнең геройлары сурәтләнгән әлеге фотографияләрне төсле һәм аклы-каралы открыткаларда нәшер итү өчен Берлиндагы нәшриятка җибәрә.

Тукай Әстерханга килгәч, иң элек Тияк (Царевой слободе) зур татар районында урнашкан, шагыйрь Сәгыйт Рәмиев яшәгән Давыт Мөхәммәтов йортының чормадагы бүлмәсендә туктала (йорт хәзер дә исән). Өч атна Рәмиев белән яшәгәннән соң, Тукай Калмык базары авылындагы Шәһид Гайфи янына күченеп китә. Анда ул мәктәп бинасындагы бүлмәдә, хуҗаның үзе белән бергә яши һәм ялын дәвам итә.

Тукай Әстерханга килү белән Гайфи аның шигырендәге темалар буенча открытка ясатырга исәпли. Ул шагыйрьнең «Бер шәехнең мөнаҗәте» шигыренә туктала. Бу сатирик шигырьнең герое «К» хәрефенә багышланган әйберләргә дан җырлый: «казы» (колбаса), «кузый» (ягненок), «каз» (гусь), «кымыз» (кумыс) һәм «кыз» (молодка, красотка). Дин әһеле, барлык мөселманнар исеменнән, Ходайдан шушы биш байлыктан үзен мәхрүм итмәвен үтенеп сорый.

Бочкарев Гайфинең хаҗи булып киенүе, ә аның хатынының яшь кыз булу күренешен сурәткә төшерә. Шәһид шәех булып, битенә ап-ак сакаллар ябыштыра. Үзенең яшь хатыны – төрекмән Нурбибәне гүзәл кыз итеп киендерә, ә калган дүрт әйберне – казы, кузый, каз, кымызны бай эшмәкәр Туликов бирә. Открыткадагы келәмдә шәех кулларын күтәреп дога укый. Янәшәсендә – чибәр кыз. Ашъяулыкта казы, кыздырылган каз, кузый һәм кымыз... Бу композиция фотографның профессиональ рәссам икәнлегенә ачып дәлил. Открытка ТР Милли музеенда саклана.

Фотография Г. Тукайның «Бер шәехнең мөнәҗәте» (1908) шигырендәге сүзләр белән рус һәм татар телләрендә төсле открыткаларда нәшер ителә.

И, Ходай! Мәгълүм сиңа, тик яхшылыкта касдымыз,
Зикремездер: казы, кузы, яшь кенә кыз, каз, кымыз.
Юкны сөйлиләр җәдитләр, чыннан әһлинсафлә без,
Мактыйбыз ич Тәңремезне иштә бу биш «каф»лә без.

[Тукай турында истәлекләр, б. 151].

Шундый ук ысуллар белән Тукайның «Егет илә кыз» һәм «Шәйтанның муенына» шигырьләре дә театральләштерелә.

Бочкаревның Тукай һәм аның Әстерхандагы дуслары белән төшкән фотолары киң танылды. Бу бигрәк тә Г. Тукай, С. Рәмиев һәм Ш. Гайфинең студиядә, бутафор көймәдә төшкән фотоларына карый. Ишкәкләрдә Шәһид Гайфи. Соңыннан ул бу фрагментны шагыйрьнең рәсеме белән почта карточкасында аерым да нәшер иттерә. Сурәтнең алгы ягына гарәп графикасында шагыйрьнең сүзләре бирелгән: «Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш: Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым. Г. Тукай» (ТР Милли музее җыелмасында). Шушы ук фото, әмма инде сәнгать ягыннан

тагын да бизәлеп, шул ук елда, почта карточкасы булып, Казанда да басыла. Открыткада – күк һәм болытлар, болыт арасыннан кояш чыга, шул фонда, монтаж юлы белән, Тукай башы куелган. Сурәтнең алгы ягына гарәп графикасында шигъри юллар язылган: «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы, шат яратса да җиһанга, ят яраткан раббысы. Г. Тукай». Бу открытка да реклама максаты белән эшләнгән (ТР милли музее җыелмасыннан). Бер уңайдан, Әстерханда Тукай үзенең озын чәчләрен кистереп, фотога кырынган рәвештә төшүен дә җиткерик.

Шагыйрь үлгәннән соң, Ш. Гайфи 1914 елда Әстерханда Тукайның ике портретын бастыра: тормыштагыча һәм сәнгатьчә. 1908 елда төшкән «идеаль» портреты аеруча зур тираж белән тарала. Фотода Тукай түбәтәй кигән һәм галстук таккан (авторы Казан фотографы Семен Иванов), шагыйрьнең бу сурәте уңышлы сатыла [Фридерих, с. 86–88]. И.М. Бочкарев төшергән тормышчан портреты да халык күңеленә хуш килә.

Тукай, Әстерханнан китәр алдыннан, Кышкы театрда, артист Зәйни Солтанов җитәкчелегендә зур кичә оештырыла һәм ул тәмамлангач, анда катнашучыларның барысын да И.М. Бочкарев фотога төшерә. Бу кичәдә беренче тапкыр театр артисты Сара Байкина чыгыш ясый. Фотода барлыгы 17 кеше була, тик аларның күбрәк сигезе генә нәшер ителә, чөнки революциядән соң цензура тарафыннан редакцияләнә. Урта рәттә сулдан: артист Зәйни Солтанов, Тукай һәм Сәгыйт Рәмиев, өченче рәттә сулдан өченче – Шәһид Гайфи.

Тукай бу фотода бик яшь күренә. Фотодагы кайбер кешеләрнең дә исемнәре мәгълүм түгел. Тукай белән күмәкләшеп төшкән бу фотода милләткә кагылышлы бернинди элементлар да юк. Ирләр заманча шәһәр костюмнары, пиджаклары кигән, уң яктагы ике хатын-кыз да шулай ук шул чордагы шәһәр киемнәреннән, фәкать берсенең генә башында шәле бар. Берничә ир-ат, шул исәптән Тукай да, татар интеллигенциясенең яраткан баш киеме – түбәтәйдән.

Бочкарев белән бөек шагыйрьне бәйләүче фактлар менә шулар. Гадәттә, мәгълүм бу сурәтләр турында сүз барганда, аларның авторы искә алынмый, ә юкса фотограф, Әстерханда бу һөнәрнең төрле өлкәләрендә эшләгән билгеле шәхесләрдән саналган.

XX гасыр башында Бочкарев төшергән әстерхан татарларының фотографияләре дә этнографик яктан кызыксыну уятырлык. Кызганыч, бу тема әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Бу язманың авторы җирле татарларның сурәтләренә 2013 елда Әстерхан өлкәсенә экспедициягә баргач тап булды. Фотолар Три протока (Җәмәле) һәм Татарская Башмаковка (Кызан) авылларында табылды. Беренче авылда шунда яшәүче Мәйсәрә Хәким кызы Умерованың (1936 елгы) гаҗәеп өй музее бар. Ул җыйган материалларны җирле әстерхан этнографлары инде күптәннән өйрәнәләр, чөнки музей экспонатлары

авыл кешеләренең көндәлек кирәк-яракларыннан тупланган. Умерова – халык җырларын, гореф-гадәтләрен өйрәнүче дә. Авылдашларының портретлары урын алган фотографияләр җыелмасы бездә аеруча кызыксыну уятты. Билгесез фотографияләр арасында И.М. Бочкаревның 3 сурәте дә табылды. Әстерхандагы, аның тирә-юнендә яшәүче татарлар да мәгълүм фотограф тарафыннан сурәткә алынып, тарихка кереп калган. Авыл кешеләре XX гасыр башларында киелә торган милли киемнәрдән, ә бу исә гаять кыйммәтле матди культура байлыгы санала. Әлеге сурәтләргә, шулай ук сакланып калган милли киемнәрнең элементларына таянып, шул чордагы Әстерхан татарларының тышкы кыяфәтен кабат торгызырга мөмкин. Икенче татар авылы Кызан – Татарская Башмаковка китапханәсендә дә И. Бочкаревның XX гасыр башындагы киемнәрдән өч яшь ир-егет һәм малай төшкән бер фотосы табылды.

Фотографияләр төрле елларда эшләнгән. Аларның төгәл датасын сурәтнең арткы ягындагы язудан, ательеның адресыннан белергә була. Иң әүвәлгесе дип Кызан авылындагы дүрт яшь кешенең фотосын санарга мөмкин. Бочкарев ательесы 1904–1909 елларда Макаров йортында урнашканлыктан, әлеге фотоларның да шул чорга каравы ихтимал. Фотографиягә төшүчеләрнең исемнәре язылмаган, шуңа сурәттәгеләр җирле авыл кешеләредер дип, фәкать фаразларга гына мөмкин. Җәмәле авылында төшерелгән ике фоторәсем инде Католическая урамында урнашкан ательеда (1911 елдан) эшләнгән. Бу – ике яшь кызның портреты (арткы ягында язу: «Сунда Куяк Шәһәрбануның энисе дус кызы белән шәһәр кызлары») һәм дүрт кешедән торган күмәк фото – өч баласы белән хатын-кыз – бер кыз һәм ике малай белән, аларның берсе яшүсмер. Фотога 1914 елда төшүләре хакында язу да бар. Фотода – Хәким Умеров, 1901 елгы 13 яшьлек малай – балаларның иң өлкәне һәм Мәүлүдова Рокия, 1888 елгы, ике бала анасы (арткы ягында язу: 1914. «Басып торучы 13 яшчә Умеров Хәким 1901 г. рож. 18 яшьлек Мавлюдова Рокия 1888 туган ана 2 бала анасы»). Янә бер фотоның арткы ягы ябыштырылган, шуңа аның кайда эшләнгәнен күрсәтүче адресын ачыклап булмады.

Шуны ассызыклап үтәргә кирәк, фотографиядә сурәтләнүчеләр, европадан кергән элементлар булган, милли үзенчәлек аз чагылган бер төрлерәк костюмнарда. Иң кыйммәтлесе – дүрт сурәттә өлкәннәр дә, төрле җенестән булган балалар да бар. XX гасыр башында Әстерханда һәм аның тирә ягында яшәүче төрле яшьтәге татарларның ничек киенүе хакында мәгълүмат алырга мөмкин. Әгәр XIX гасырга кадәр костюмнар баш киеменең төрле вариантлары нигезендә төрлеләнергә, үзгәрергә мөмкин булса, XIX гасыр азагы – XX гасыр башына инде ул җыелма детальләрнең тегелеше буенча да, төсләрнең туры килүе ягыннан да гадиләштерелә. Бу урбанизация белән дә, гомумшәһәр мода-

сы белән дә бәйләнгән, чөнки ул чорда татарларның зур күпчелеген күченеп килгән урта идел буе татарлары тәшкил иткән. Костюм гомуммилли киемгә әверелә.

XIX гасыр азагы – XX гасыр башында татар ир-егетләренең гомуммилли өс-баш киемнәре бер комплекс дәрәҗәсендә кабул ителә. Ул шактый тар җиңле итеп тегелгән күлмәк, кыска кәзәки, гомумевропа үрнәгендәге ыштан, кара бәрхеттән «казанча» баш киеме, штиблет һәм фабрикада тегелгән ботинка. Бу костюмның үзенчәлекләре дүрт яшь кеше төшкән фотографиядә аеруча ачык күренә.

Хатын-кызлар костюмы, ирләрнеке белән чагыштырганда кызыклырак та, баерак та. Күлмәк классик формада үкчәгә кадәр озын итеп тегелгән, җиңнәр беләзек тирәсендә киңәеп китәргә мөмкин, якалар – муенны каплый, төз! Әгәр якалар ачык кала икән, муенга тыгыз тукымадан махсус тегелгән күкрәкчә – изү бәйләгәннәр. Ул муенга бәйләнгән һәм аны тулысынча каплаган. Ул озынча түгәрәк яки турыпочмаклы формада да булырга мөмкин. Фотолардан күренгәнчә, күлмәкнең традицион алъяпкыч урыны һәр төрле бизәкләр белән чигелгән. Традицион хатын-кыз күлмәге аска таба киңәя, бөрмәле итәк, җиңелчә генә каймага җыелган җиңнәр аска таба киңәя төшә. Күлмәктәге бөрмәләр (бәби итәк), башлыча киң, ә олы яшьтәге хатыннар һәм кызлар өчен тар. XX гасыр башындагы хатын-кыз күлмәкләренең җиңнәре традицион стильгә яраклаштырып тегелгән һәм чигелгән. Хатын-кызның тышкы киеме ике төргә бүленә: билгә таба аркасы тарайган – аркалык һәм турыдан тегелгән – каптал. Аркалык – идәнгә кадәр тиеп торучы, озын җиңле, тыгыз тукымадан тегелгән камзулның бер төре. Каптал – башка урыннарда яшәүче татарларда да үрнәге булган туры аркалы чикмәннең бер төре. Капталның төймәле яки элмәкле кырые һәм итәге бай декоратив орнаментлары белән аерылып торырга мөмкин. Шуңа охшашлыкны өч балалы хатын фотосыннан күреп була. Ә балалар үзләре исә бердәй шәһәр киемнәреннән, фәкать кызның башында гына калфак.

Хатын-кызларның баш киемнәре берничә вариантта таралган һәм аларның гаилә хәленең дәрәҗәсенә бәйле булган. Яулык-япма тастар исеме белән киң таралган. Кияүдәге хатыннар чәчләрен җиңелчә япма астына яшергәннәр, өстеннән ефәк яулык япканнар. Ике фотосурәттәге хатын-кызда без җиңел, челтәрләп эшләнгән чуклы шәл күрәбез, аның фабриканыкы булу ихтималы зур.

Калфаклар да киң тарала башлый. Бигрәк тә тар кырпулы бәрхет башлыклар татар хатын-кызларында зур популярлык казана. Нәкъ менә шундыйларны без фотографиядәге нәни кызларда күрәбез. Костюмның әлеге элементы гомуммилли татар киеме комплексында озак сакланды.

Ирләрнең баш киеме – түбәтәй. Фотолардагы ир-атлар, шул исәптән Тукай белән төшкәнендә дә, башларына чигелмәгән

түбәтәйләр, ягъни кәләпүшләр кигәннәр. Кәләпүш интеллигенциянең һәм хезмәткәрләрнең яраткан баш киеме булган. XX гасыр башындагы фотографияләрдә без башларына кара кәләпүш кигән татар ир-атларын еш күрәбез. Мөселман гореф-гадәтләре буенча ир-атлар, чәчләрен кырдырып, түбәтәй кигәннәр. Тукай Әстерханга килгәч, үзенең даими рәвештә йөрткән зур чәчләрен кырып ташлый һәм кәләпүш кия. Нәкъ менә шундый формада ул күп кешеләр белән бергә фотога төшә. Мөгаен ул аны җирле татар җәмәгатьчелегеннән аерылып тормас өчен шулай эшләгәндер.

Әстерханлылар муенсага караганда (Казан татарларыннан аермалы буларак) күбрәк табигый энҗе кулланганнар. Өч бала белән фотога төшкән хатын-кыз да шулай бизәнгән, төзәнгән. Кечкенә кызның да муенсасы бар. Әнисенең һәм кызының кулында беләзекләр, кызыныкы гадиерәк һәм ул мәрҗәннән эшләнгән. Әниләренең якасы бантик формасындагы брошка белән төймәләнгән. Татар костюмының аерылгысыз элементы – алкалар. «Ике шәһәр кызы» төшкән фотосурәттә дә бай бизәнү әйберләрен күрергә мөмкин – озын энҗе җепләр, асылмалар, энҗеле алкалар, якалы күлмәкләр өчен брошкалар һәм кыстыргычлар, ике кулда да формасы буенча катлаулы браслетлар. Булган бөтен «байлыкны»да фотограф бөртекләп, җентекләп истәлеккә калдырган. Өченче фотографиядә бизәнү әйберләре шактый тыйнак, ә яшь бала белән төшкән хатынның беләзекләре юк һәм энҗе урынына чылбырга тагылган асылташ.

Кыскасы, өч балалы хатынның киеме, башка сурәтләрдәге ике хатын-кыз белән чагыштырганда, традицион милли төсмерләргә баерак. Аларның күлмәкләре шәһәр модасы буенча тегелгән, әмма, күлмәкләрдәге бөрмәләрдә (бәби итәкләрдә), калфак һәм яулыкларда миллилек төсмере шактый. Татар кызлары өчен хас булган чәч толымнары ювилер әйберләр белән түгел, ә тасмалар ярдәмендә үрелгән.

Җыеп кына әйткәндә, Три протока (Җәмәле) авылында төшерелгән ике фотосурәттәге хатын-кызларга карагач, традицион милли күлмәкләрнең европаның шәһәр модасы йогынтысында үзгәрә башлавын аңлыйсың.

Шулай итеп, И.М. Бочкаревның фотосурәтләре Г. Тукайның тәрҗемәи хәле, XX йөз башы Әстерхан татарларының тормышы, яшәү рәвеше турында кыйммәтле чыганак булып тора.

### Әдәбият

*Загидуллина Д.* Габдулла Тукай в Астрахани // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2006. № 1 (43). URL: http://www.archive.gov.tatarstan.ru/magazine/go/anonymous/main/?path=mg:/numbers/2006_1/06/06_2/

*Марков А., Львов С.* Астрахань на старинных открытках. Астрахань: ГУП «Волга», 1999. URL: http://damir-sh.livejournal.com/193677.html

*Нагайкина С.И.* Фотография в Астрахани. 1861–1920. Очерки по истории губернской фотографии. Астрахань: Тип. Новая линия, 2011. 280 с.: илл. URL: http://foto-history.livejournal.com/2546990.html

*Нафигов Р.* О поездке Тукая в Астрахань // Тукаевские чтения: материалы выступлений. Апрель, 1999 г. Казань, 2000. 161 с.

*Фридерих М.* Тукай как объект идеологической борьбы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 343 с.

Тукай турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 256 б., портр.

***Әхмәтова Динә Ирек кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 76

***Ф.Г. Ваһапова***

# «ЯШЕН» ҺӘМ «ЯЛТ-ЙОЛТ» САТИРИК ЖУРНАЛЛАРЫНЫҢ РӘССАМ-БИЗӘҮЧЕЛӘРЕ

В статье анализируются иллюстрации в сатирических журналах «Яшен» и «Ялт-Йолт», выполненные художниками начала XX века. Отмечается, что в создании иллюстраций принимали участие профессиональные художники, а также художники, не имевшие специального художественного образования. Иллюстрации на страницах журналов позволили проследить генезис и динамику развития татарской книжной графики начала XX века. Автором сделан вывод, что в творчестве художников начала XX века прослеживаются черты, характерные для восточной миниатюры, русской лубочной картинки, а также стилистики искусства модерн.

**Ключевые слова:** журналы «Яшен» и «Ялт-Йолт», иллюстрация, графика, литография, модерн, политипаж, типографские элементы, художник.

1908, 1910 елларда Г. Тукай, Г. Камал белән бергә, Казанда татар телендә нәшер ителүче «Яшен» һәм «Ялт-йолт» сатирик журналларына нигез салалар һәм аның битләрендә, җәмгыятьтәге социаль һәм мораль нигезләргә каршы барып, күп нәрсәләр тәнкыйди мөнәсәбәттә яктыртыла башлый. Г. Тукай һәм Г. Камал оештыручы, нашир һәм мәкаләләрнең авторлары гына түгел, алар журналны бизәү өчен кулланылучы карикатураларның темасы һәм сюжетын билгеләүче авторлар да булалар. Журналның конструкциясе дәфтәр итеп теркәлгән 15 биттән тора, беренчесе – титул бите, аннан карикатуралар белән тулыландырылган (яки сюжетлы рәсем, я фотосурәт) текстлы битләр, ахыргы биттә реклама белдерүләре блогы. Титул битне әзерләүгә аеруча зур игътибар бирелә. Бу битне төзүче элементларны дөрес итеп бүлү аның гомуми характерлы үзенчәлеге санала. Бит горизонталь буенча ике өлешкә бүленә. Өске өлешнең өчтән бере журналның исеме һәм сюжет рәсеме булган политипаждан тора. Политипажның астында санның төп язмасына иллюстрация буларак ясалган карикатура урнаштырыла. Журналлардагы карикатуралар мөстәкыйль түгел, алар мәкалә текстларына иллюстрация буларак бирелә.

«Ялт-йолт»ны өйрәнүчеләр фикеренчә, журнал белән сигез рәссам хезмәттәшлек иткән: Г. Камал, С. Яхшыбаев, инициалларын гына куйган рәссамнар – «И.А» («Ялт-йолт»), «Б.Э» («Ялт-йолт»), «W» («Ялт-йолт») һәм шартлы рәвешетә үзен «коңгыз»га охшаган монограмма астында күрсәткән («Ялт-йолт») рәссам. «Яшен» журналында нәшер ителгән барлык рәсемнәрнең дә авторы Г. Камал үзе була. Санап үтелгән авторлар арасында үз эшенең профессиональ осталары да, үзешчәннәр дә бар.

«Ялт-йолт» журналының 13–30 нчы саннарындагы барлык карикатура һәм политипажлар «И.А» (рәссамның исеме ачыкланмаган) инициалы белән кул куйган рәссам тарафыннан эшләнгән.

Имза куйганда урыс алфавиты хәрефләре кулланылуына карап, бу рәссам милләте буенча урыс булгандыр дип фаразлыйлар. Рәсемнәрнең сюжетларын сулдан уңга уку шуны күрсәтә – рәссамга композиция төзүдә европа традицияләре якынрак булган. Рәссамның карикатуралары сәяси темаларда үзләренең кискенлеге һәм кыюлыгы белән аерылып тора. Сюжет персонажлары хайваннар булганда, автор кайчакта гротеск алымнарын да кулланган. Күпертү алымнарын, кайчакта, хәтта, кайбер элементларга (мәсәлән, кеше-тегермән кебек антропоморф тереклек иясе) сублимация ясау да рәссамга карикатурадагы иң мөһим бурычка ирешергә – җәмгыятьнең һәм аерым кешенең җитешсезлекләрен ассызыкларга ярдәм итә. Рәссам кайбер карикатураларында дәүләт һәм төбәкләрдәге мәгълүм сәяси лидерларның эшчәнлегеннән көлә. Күп кенә рәсемнәрне хаклы рәвештә сюжетлылар исәбенә кертергә була. Рәссам үзенә генә хас алымнар кулланып иҗат итә. Аның рәсемнәре үзенчәлекле нәфислек һәм сыгылмалылык белән аерылып тора. Ул һәрвакыт сизелерлек контурга берегә һәм рәсемдә мастерның саллы кулын тоемлыйсың. Башкару осталыгы кеше гәүдәсенең төзелешен һәм мимик чагылышын җиткерүендә, күренеш законнарын белүендә күренә. Карикатура өчен хас булган график төзелешне һәм аның нигезен тәшкил итүче төп кагыйдәләрне белүе, рәссамның үз эшенең остасы икәнен раслый. Татар журналында эшләгәч, ул милли, мөселман рәсем сәнгате өчен хас булган традицияләрдән читкә китми. «W» инициалы белән язган бердәнбер карикатура авторы да («Ялт-йолт», № 24) бу жанрның төп принципларыннан хәбардар икәнлеген күрсәтә. Ул образны гәүдәләндергәндә гротеск алымын куллана. «Б.Э» исеме белән кул куйган рәссам журналның (№ 54–84) титул битләрен әзерләгән. Политипаж рәсемендә автор сюжетлы символик уку алымын куллана. Мәсәлән, кояш нурларының җемелдәве фонында хайваннарның караңгы силуэтлары тормышның тискәре якларын символлаштырырга тиеш. Журналның гарәп шрифты белән язылган исеме астында хәрефләргә карап торучы елан рәсеме ясалган. Аның амбивалент символын зирәклек дип тә, үлемсезлек дип тә кабул итәргә мөмкин. «Б.Э» «Ялт-йолт» журналының алда күрсәтелгән саннарында чыккан карикатураларның авторы да. Үзенең рәсемнәре астына исемен куймаган рәссамның да эшләре кызыклы. Аның беренче эше журналның 64 нче санында басыла. Ул «Ялт-йолт» журналының 85–97 нче саннарын бизи, 87 нче саннан башлап карикатураларның гына түгел, титул бите политипажларының да авторы була. Әлеге авторның эшләрендә үзенә генә хас кабатланмас стиле бар. Рәссам композиция төзүдә күбрәк европа традицияләренә

таяна. Кайбер эшләрендә экспрессионизм сәнгате үзенчәлекләрен күрергә мөмкин. Аларда рәссамның шәхси эзләнүләре, җәмгыятьтә киләчәк һәлакәтнең котылгысызлыгын аңлаудан туган тойгыны сурәтләүдәге кабатланмас стиле чагылыш таба.

«Яшен» һәм «Ялт-йолт» журналарын бизәү өчен рәссамнар шрифт, пробел (ара), декоратив һәм иллюстратив кебек элементларның барысын да кулланалар. «Ялт-йолт» журналының кайбер саннарында фотосурәтләр дә урын алган. Журналның 55 нче (1913) һәм 88 нче (1915) саннары шагыйрь Г. Тукай, ә 89 нчы саны (1915) И. Гаспринский истәлегенә багышлап нәшер ителгән.

**Әдәбият**

*Гимадиев У.И.* Сатира, ее жанры и художественные средства: (Борьба сатирических журналов за народность и реализм в татарской литературе начала XX века). Уфа: БГУ, 1980. 92 с.

*Гимадиев У.И.* Г. Камал и «Яшен». 75–76. // Галиаскар Камал. Сборник статей, посвященных 100-летию со дня рождения писателя. Казань, 1981. С. 69–78.

*Гимадиев У.И.* Сила сатирического слова (Роль и значение татарских сатирических журналов дооктябрьского периода в развитии национальной литературы). Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. 267 с.

*Рәми И.Г., Даутов Р.Н.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияты буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. Б. 325.

Татарский энциклопедический словарь (ТЭС). Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 1999. С. 284, 690.;

*Червонная С.М.* Искусство Татарии. М.: Искусство, 1987. С. 280–284.

***Вәһапова Фирдәвес Гомәр кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Н.И. Лобачевский исемендәге*
*Нижегород дәүләт университетының Халыкара мөнәсәбәтләр*
*һәм дөнья тарихы институтының сәясәт һәм коммуникацияләр*
*теориясе кафедрасы доценты*
*vagap.art@mail.ru*

УДК 821.512.145-293

***А.Г. Алмазова***

## «ШҮРӘЛЕ» БАЛЕТЫ

В статье ставится проблема анализа либретто первого татарского балета «Шурале», написанного Ахмедом Файзи и Леонидом Якобсоном по поэме-сказке Габдуллы Тукая. Главная цель – показать роль и значение каждого из авторов в создании сочинения.

**Ключевые слова**: Ф. Яруллин, балет «Шурале».

Композитор Ф. Яруллинның Тукай әсәре буенча куелган «Шүрәле» балетының (сәхнәгә куючы Л.В. Якобсон, дирижер И.И. Әүхәдиев, рәссамы Б.И. Волков) премьерасы 1943 елда була.

В.С. Никитин тарафыннан эшләнгән костюм эскизлары (бүген алар В. Качалов исемендәге Казан Зур драма театры һәм ТР Дәүләт сынлы сәнгать музейларында саклана) традицион татар костюмнарын балет өчен интерпретация ясарга тырышуның тәүге үрнәге, анда хореографиягә дә, шулай ук фольклор элементларына да зур урын бирелгән.

Рәссам, музыканың характерын күздә тотып, беренче актта төп персонажларны гротеск формасында хәл итә. Икенче актта милли пластика үзенчәлекләренә, костюмнарны кию рәвешләренә акцент ясала. Монда күпкатламлы, авыр, салдырыла торган бизәкле полихром костюмнар өстенлек итә. Балетның финал өлеше классик бию чаралары аша башкарыла, шуңа да рәссам бармакларга фигуралар куя һәм костюмнарны ярым үтәкүренмәле, ак һәм җиңел итеп ясап, фигураларны максималь дәрәҗәдә азат итә.

Балетмейстер Г. Таһиров Татарстан районнарына экспедициягә барып кайтканнан соң, анда күргәннәреннән чыгып, костюмнарның формасын этнографизм ягына үзгәртә. Кеше формасында гәүдәләндерелгән образларның киемнәре милли төсмерләрдән азат була, әмма Б. Әхтәмов, Шүрәленең сәхнә образын тудырганда, Г. Тукай шигыреннән читкә тайпылмый.

Жанрлы картиналар һәм комик уен күренешләре вакытында киелә торган костюм образлары юморлы планда эшләнгән. Шаржлаштыруга корылган стильләштерүдә табигый үрнәкнең үзен күзәтү алымы файдаланыла.

Кыз-кош Сөембикә образы аша тудырылган әкият дөньясы элементлары, реалистик тормышка капма-каршы итеп, Былтыр образында гәүдәләндерелгән. Сөембикәнең костюмына формасы белән ярымачылган төнбоекны хәтерләтүче рәсем (татар костюмының төп элементы), аңа өстәмә буларак кошның каурыйлары да ясалган. Костюмдагы ак төсләр – яктылык һәм кояш символы, фактура һәм урман төсенә контраст рәвештә.

Шүрәлеләр, аждаһалар һәм убырлы карчыкның уйлап табылган фантастик образлары чынбарлыктагы образларга нигезләнгән. Бер яктан, балетның нигезен тәшкил итүче тормышчанлык принцибы, һәм, икенче яктан, әсәрнең әкият-фантастик жанры һәм символик характеры стильләштерүгә фараз кыла, костюм һәм персонажларны чынбарлыктагыдан турыдан-туры сызып ташлау ихтималын юкка чыгара. Бу эше белән В. Никитин әкиятне тормышка һәм табигатькә якынайткан: костюм эскизлары театр өчен генә булса да, алар крестьян чырайлы һәм киемле, типик татар авылын характерлаучы – үзләренең тере образлары белән дә элемтәләрне югалтмыйлар. Барлык костюмнар да төсләре белән декорациягә яраклаштырылган, гомуми сәнгать-динамик структурасына кушылган.

Сценографиядә зур роль төсләр партитурасына бирелгән: төсле ачык нурлар аеруча мөһим символик фигура һәм башка кирәк- яракларны яктыртырга тиеш була. Р.М. Сперанскийның, татар авылы һәм кара урманның гомумиләштерелгән образ иллюзиясен булдыру өчен ясалган күләмле-тасвирый декорацияләре балет-пьесаның төп принципларына туры килә. Иллюзиягә корылган принцип хореографик формадагы шартлылык белән каршылыкка керми. Табигатьнең гомумиләштерелгән образы бутафория һәм костюмнар ярдәмендә конкретлаша һәм көчәя.

Сугыштан соң, 1945 елда, Л.В. Якобсонның үтенече буенча, композиторлар В. Власов һәм В. Фере С.М. Киров исемендәге Ленинград опера һәм балет театры өчен балетның яңа партитурасын эшлиләр. 1950 елда «Али-Батыр» премьерасы зур уңышка ирешә, соңыннан бу постановка СССРның Зур театрына күчерелә.

Л. Якобсон либреттоны яңадан эшләп, төп акцентны әкиятилеккә, фантастиклыкка бирергә тели. Бу максатка ирешү өчен аңа үз вакытында модада булган люминесцент буяулар да ярдәм итә.

Балетмейстер-дипломант Я.Е. Брунак тарафыннан 1953 елда татар театры сәхнәсендә куелган постановкада «иректә биюләргә» омтылу, башкаручыларның төз гәүдәләрен ассызыкларга тиешле костюмга да йогынты ясый.

Костюмнар буенча рәссам Л.Л. Сперанской-Штейнга, татар киемнәрен яхшы белү, В. Никитин башлап җибәргән милли балетка интерпретация ясау өчен, аның төрле вариантларын эзләргә мөмкинлек бирә. Сценографиядә кулланылган табигый киңлек мотивы татар авылының гомумиләштерелгән образы, костюмнарда этнографик элементларны саклауның мөһимлеген күрсәтә. Сперанская этнографик фольклорга иҗади якын килә: һәр чәчәкнең ролен көчәйтү өчен төсләр гаммасын катлауландыру һәм бер үк вакытта гадиләштерү тенденциясен чагылдыруы, беренче һәм икенче актларда, Сөембикәнең матур киендерелгән образын пластик хәл ителеше өчен аның эскизларында төрле эзләнүләр үткәрүе күренеп тора. Ак костюм кигән кызларның кошларга әверелүләре театр утлары

ярдәмендә гамәлгә аша. Силуэт характерында кискен төстә утлар аша күрсәтелгән, ләкин костюмнарда расшифровкаланмаган Шүрәле «яраннары» образын гәүдәләндерү өчен эшләнгән киемнәр дә кызыклы. Персонажлар җиргә тимичә тизлек белән өскә үрмәләгән халәттә, балетмейстерның авторлык идеясенә туры килерлек итеп ясалганнар.

1950 елларда балет костюмнарын тегү өчен кыйммәтле табигый тукымалар (крепдешин, креп-жоржет, ефәк) кулланылган, костюмнар мамык белән бизәкләнгән, ука һәм сәйлән җепләр белән чигелгән.

1957 елда театр яңа бинага күчәргә әзерләнү сәбәпле, Л.А. Бордзиловской һәм Ш.Б. Байдәүләтов балетны Ленинградтагы С.М. Киров исемендәге Дәүләт опера һәм балет театрында сәхнәләштерәләр. Шунда ук Л.Л. Сперанский В. Никитин эскизлары буенча костюмнар тегә. ТР Милли музеенда Былтыр һәм Сөембикәнең гаҗәеп үрнәктәге балет костюмнары саклана.

1986 елдагы куелышта «Шүрәле» балеты (хореограф К.А. Рассадин) әкияти-гомумиләштерелгән, символик формага һәм буффонадка (үтә көлке театр уены) тагын да якынайган. Шуңа да рәссам А.Б. Кноблокның җете ачык төсләрне сайлавы стилистик яктан үзен аклый.

Яңа постановкада төрле стильлелек һәм чуарлык юкка чыккан. Рәссам гомумиләштерелгән символик характердагы декорация ярдәмендә күренешләргә гомумилек төсмерен бирә. Костюмнар балетның пластик стиленә туры килә. Спектакльдә, стильләштерү законы буенча, символларга кадәр барып җитүгә корылган образларны яңадан ачу өчен мөмкинлекләр табылган. Моңа күбрәк актерларның пластикасы исәбенә һәм, рәссамның көнкүреш конкретлылыгыннан китәргә теләп тегелгән костюмнар ярдәмендә ирешелә. Иллюзия-дөреслеккә якынайтылган декорация һәм символик-кинаяле костюм образлары бер-берсенә каршы килми, стилистик яктан бердәм һәм гомуми сәнгать концепциясе карарына буйсындырылган. Партитурада утка зур әһәмият бирелгән.

Бүгенге көндә «Шүрәле» балеты шул ук редакциядә, шул ук бизәлештә куела, әмма костюмнар һәрдаим яңартыла. Ә бу исә гармония һәм бердәм шартлылыкны тарката. Туй күренеше (II акт) бәрхет һәм крептан тегелгән төрле стильдәге, төстәге ачык костюмнар белән чуарланган.

Берничә костюм эскизлары сакланган. Рәссам фонны нейтраль төс белән каплый, уртага шартлы костюмнар кигән, таяну ноктасы булмаган фигураларны урнаштыра. Силуэтта татар костюмының гомуми билгеләре сакланган. М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының музей фондында шушы постановкадан алынган, рәссамның имзасы куелган ике костюм бүген дә тамашачыларны үзенә җәлеп итә.

***Алмазова Аида Габдрахман кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты.*

**Март аенда** интернетта «Әлбәттә» мәгариф проекты эшли башлады. «Әлбәттә» – татар фәнен киң аудиториягә ирештерү максаты белән башлап җибәрелгән фәнни-популяр проект, дип аңлатыла әлеге сайтта. Аның кысаларында хәзерге көн күренекле татар галимнәренең татар халкы тарихы, тел белеме, әдәбияты, сәнгате һәм фольклорына кагылышлы кыска видеолекцияләре тәкъдим ителәчәк. Хәзергә сайтта тарих фәннәре докторы Дамир Исхаковның «Татар халкы каян килеп чыккан?» темасына лекция тыңларга мөмкин. Филология фәннәре докторы Дания Заһидуллина «Тукай модернистмы?» дигән сорауга җавап бирә. Шулай ук сайтта филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗановның «Зәңгәр шәл»нең сере нидә?» лекциясе урын алган. Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе профессоры Сәгыйть Хәбибуллин лекциясе «Курай татарныкымы?» дип атала һәм анда татар халык музыка уен коралларының килеп чыгышы, татарлар тормышындагы урыны хакында сүз бара. Филология фәннәре кандидаты Зоя Кириллованың «Татар теле: озын сүзнең кыскасы» дип исемләнгән лекциясе – татар теленең дөнья телләре арасындагы урыны һәм төп үзенчәлекләре турында. Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе Фәнзилә Җәүһәрова исә Сабан туе бәйрәменең килеп чыгышы, аның борынгы мәгънәсе һәм эчтәлеге, хәзерге вакытта югалган йолалары хакында сөйли. «Әлбәттә»нең максаты — татар телендәге фәннәргә кызыксыну уяту һәм тирән хөрмәт тәрбияләү.

**12 мартта** ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Лобачевский исемендәге премиягә дәгъва кылган фәнни хезмәтләр конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды. Быелгы конкурста дөньяның 4 иле һәм 30 шәһәрендәге 50 югары уку йортында укучы 652 студент катнашты. Шуларның 69 ы конкурс партнерлары әзерләгән истәлекле призлар белән бүләкләнде. Республикада унтугызынчы тапкыр 27 юнәлеш буенча үткәрелгән конкурс студентлар фәнни эшчәнлегенең барлык өлкәләрен дә колачлый. Конкурс исә, ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Югары уку йортлары ректорлары советы ярдәме белән, ТР Студентлар лигасы тарафыннан оештырылган.

**18 март көнне** ТР ФАның Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Санкт-Петербургның Татар дворяннар җыены «Династия Романовых и мусульмане империи» дип аталган китапны киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итте. Фәнни-популяр басма авторлары – Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Төньяк-Көнбатыш фәнни үзәге җитәкчесе, хәрби фәннәр кандидаты Шамил Әхмәтшин һәм Мәскәү дәүләт геодезия һәм картография университеты доценты, тарих фәннәре кандидаты Александр Закатов. Китапта

Романовлар йорты тарихы бәян ителә, император гаиләсенең мөселманнар белән үзара мөнәсәбәтләре ачыла. XIX гасыр азагы – XX гасыр башында мөселманнарның Ватанны яклауда катнашуына аерым игътибар бирелә. Шамил Әхмәтшин һәм Александр Закатов авторлыгында нәшер ителгән әлеге фәнни хезмәт тарихи мирасны саклауда ярдәм итәр, Россия файдасына төрле конфессия вәкилләре хезмәт итү тарихының элек билгеле булмаган битләрен ачар дигән өмет баглый.

**21 мартта** Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә узган ТР Министрлар Кабинеты карамагындагы Икътисади совет утырышында Татарстанда сәнәгать җитештерүе, технология һәм белемнәрне коммерцияләштерү өчен фәнни эшләнмәләрне адаптацияләүгә мөмкинлек биргән инфраструктураны үстерү мәсьәләләре тикшерелде. Рөстәм Миңнеханов искәрткәнчә, республикада био-, нано-, мәглүмати технологияләр, югары технологияле медицина, робот техникасы, генетика юнәлешләрен һәм яңа материаллар җитештерүгә җитди игътибар бирелә. Әлеге юнәлешләрне актив һәм максатка ярашлы үстерү өчен республикада дүрт инжиниринг, ике прототиплау үзәге эшли. «Инжиниринг үзәкләренең җиһазларыннан файдалануның нәтиҗәлеге югары түгел», – дип ассызыклады Президент. Аның сүзләренчә, предприятиеләрнең фән белән хезмәттәшлегенең нәтиҗәсе яңа эшләнмәләр, перспективалы җитештерү һәм югары технологияле эш урыннары булырга тиеш. Инжиниринг үзәкләре белән уңышлы хезмәттәшлек мисалы итеп, ул КФУ, КИТТУ-КАИны китерде. «Вуз эшләнмәләрен коммерцияләштерү белән активрак шөгыльләнү зарур», – дип саный Илбашы.

**22 мартта** Симферополь шәһәрендә «Исмәгыйль Гаспралы дөньясы» дип исәпләнгән фәнни-гамәли конференция үткәрелде, «Исмаил Гаспринский» китабы Кырым җәмәгатьчелегенә тәкъдим ителде. Китап Россия империясе чорында бөтен мөселман халыклары арасында танылган мәгърифәтче, сәясәтче һәм нашир Исмәгыйль Гаспралының тууына 165 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән. Китапны тәкъдим итү чарасы интернет аша Казан белән туры элемтәгә тоташып оештырылды. Ул Казанның элеккеге Матбугат йорты, ә хәзерге «Ногай» кунакханәсе бинасында урнашкан «Габдулла Тукай» конференцияләр залында узды. Анда Татарстан китап нәшрияты җитәкчелеге, Гаспралының тормышын бәян итүче китапны эшләгән галимнәр, татар язучылары, китапханәчеләр, Казанда яшәүче кырым татарлары катнашты. Ә видеоэкранның икенче ягында М. Гаспралы китапханәсе хезмәткәрләре, Кырым Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары Рәмзи Ильясов һ.б. сәламләде. Әлеге чарада Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Ра-

зил Вәлиев, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институтының яңа тарих бүлеге мөдире И. Заһидуллин, «История татар в лицах» сериясе авторы галим Булат Хәмидуллин һ.б. чыгыш ясады.

**24 март көнне** ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Каюм Насыйри (1825–1902) төзегән Изге Коръәннең мөселман дөньясындагы беренче белешмә-конкордансы – Мифтах әл-Коръән» («Мифтах аль-Кур'ан») дип аталган уникаль китап тәкъдим ителде. Мәшһүр галим, татар мәгърифәтчесенең бу кулъязмасы заманыбызның чын фәнни ачышы санала. Аерым алганда, китап – галимнең 4 еллык киеренке хезмәте нәтиҗәсе. Ул аны 1886 елда тәмамлый. Каюм Насыйри үзе бу китабын «иҗтиһадының иң югары ноктасы», фәнни эшчәнлегенең иң зур тырышлыгы җимеше санаган. Басма 2 томда тәкъдим ителә: беренчесе – «Каләм Шәриф» – Каюм Насыйри тарафыннан нигез буларак алынган Коръәннең 1861 елгы Казан басмасы факсимилесе, икенчесе «Мифтах әл-Коръән» кулъязмасы факсимелесеннән гыйбарәт.

**Март аенда** ел саен сөекле шагыйребез Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатларның исемнәре мәгълүм була. Быел Татарстан Президенты каршындагы Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе комиссиясе түбәндәге иҗат әһелләрен бүләккә лаек дип тапты. **Равил Айдаров** – «Казанский деревянный дом XIX – начала XX веков в акварели и графике: издание второе дополненное» – тарихи-архитектур монография, Борынгы Казан архитектурасын тасвирлаган, бинalar, урамнар күренешләре, архитектур графика (рәсем, сызым, акварель); **Ренат Әюпов** – Габдулла Тукай тормышын һәм иҗатын чагылдырган спектакльләре: «Печән базары» – Р. Әюпов инсценировкасы, 2006 ел; «Зәйтүнәкәй» – Р. Батулла пьесасы, 2011 ел; «Әйт әле, күбәләк» – Т. Миңнуллин пьесасы, 2014 ел; **Фәүзия Бәйрәмова** – «Кырык сырт: романнар» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2005 ел), «Күчем хан: тарихи роман» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел); **Флера Гыйззәтуллина** «Яну дәверләрендә: поэма-трилогия» (Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013 ел), Башкаемда – дөнья исәпләре: шигырьләр, поэмалар, балладалар» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2007 ел); **Шәмсия Җиһангирова** – «Илаһият: шигырьләр» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел), «Бәхетең үз кулыңда: җырлар» (Казан, «Рухият», 2012 ел); **Нәҗип Нәккаш** – Г. Тукай шигырьләре файдаланып эшләнгән шәмаил, ләүхә цикллары, «Ярдәм» һ.б. мәчет дизайны өчен; **Газинур Морат** – «Кош хокукы: шигырьләр һәм поэмалар» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014 ел); **Вакыйф Нуруллин** – «Сайланма әсәрләр. Ике томда. I том: повестьлар» (Казан, «ТанДим» нәшрияты, 2014 ел); **Гөлзада Сафиуллина** – Татарстан халкының рухи мирасын пропагандалаганы, «Сөембикә варислары» (1999–2015 еллар)

фестивале оештырганы һәм «Үлемсез ил җыры» (2007 ел) патриотик җыр башкарганы, «Илаһи моң» (2014–2015 еллар) рухи мирас проекты, шулай ук «Әй, киң төрки даласы» (2013 ел) концерт программалары; **Җәүдәт Сөләйманов** – «Сүтелә йомгак...: шигырьләр, поэмалар» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел); **Айдар Хәлим** – «Өч аяклы ат», «Кыйбла», «Казыктагы тальян», «Татар вакыты» романы һәм «Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» хикәяләре (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2005 ел), «Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман» (Казан, Татарстан китап нәшрияты 2002 ел); **Альберт Хәсәнов** – «Җәнбәт җәвере: повестьлар, хикәяләр, публицистик язмалар» китабы (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2007 ел), «Данәгөл: роман» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел), «Сайланма әсәрләр. Ике томда» (Казан, «Тан-Дим» китап нәшрияты, 2014 ел), «Бүре баласы Чатан: повесть һәм хикәяләр» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014 ел); **Зиннур Хөснетдинов** – «Кичү: хикәяләр, повестьлар, роман-дилогия» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел); **Авторлар төркеме:** Илья Артамонов (рәссам-проектлаучы), Леухин Александр (рәссам-проектлаучы), Вәлиуллин Фщрит (рәссам-монументалист), Шиһабетдинов Рәшид (рәссам-монументалист), Щетинин Игорь (рәссам-монументалист), Ситдыйков Айрат (А. Халиков исемендәге археология институты директоры), Хәйретдинов Рамил (Казан федераль университетының халыкара багланышлар, тарих, көнчыгышны өйрәнү институты директоры), Бугров Дмитрий (археолог). «Дорога длиною в тысячелетия» дип аталган экспозицион инсталляция.

**27 март** – Халыкара театр көне. Шул уңайдан Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, традицион рәвештә, «Тантана» («Триумф») республика театр премиясен тапшыру чарасы уздырылды. ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан театр сәнгате өлкәсендә иҗат һәм иҗтимагый тормыштагы казанышларны бәһаләү өчен гамәлгә куелган әлеге премия быел алтынчы тапкыр тапшырылды. Быел аңа 40 номинант дәгъва кылды. «Тантана»да катнашырга дәүләтнеке булган 15 һәм дәүләтнеке булмаган 6 театрдан барлыгы 128 гариза килгән. Жюри составында ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, шагыйрь, ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, театр тәнкыйтьчесе Нияз Игъламов һ.б. бар. Н. Игъламов сүзләренчә, җиңүчеләрне билгеләү жюри әгъзаларына аеруча авыр булган, чөнки премиягә тәкъдим ителгән иҗади эшләр күптөрле. Бер генә номинациядә дә лидер ачыкланмаган, әмма жюри берәр җиңүчене билгеләргә карар кылган. Тантанада беренче бүләкләрне дә ул тапшырды. Махсус призларны аның кулыннан «Арт» Камера театры һәм Чаллының «Ключ» театр-студиясе вәкилләре кабул итеп алды. «Дебют» номинация-

сендәге бүләк «Болактагы яшьләр театры» артисты Резеда Һадиуллинага Э. Шмитның «Оскар и розовая дама» әсәре буенча сәхнәләштерелгән «14 писем к ...» моноспектаклендәге роле өчен бирелде. «Иң яхшы курчак театры артисты» номинациясендә «Әкият» курчак театрының А. Цагарели спектаклендә Князь Ваня Паниашвилины уйнаган Дилүс Хуҗиәхмәтов җиңде. «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә Т. Миңнуллин исемендәге Түбән Кама Татар дәүләт драма театры артисты Гүзәл Шәмәрданова җиңүче дип табылды. Бүләкне ул Ч. Айтматовның «Анам кыры» спектаклендәге Тулганай роле өчен алды. «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә беренчелекне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Радик Бариев яулады. Премия аңа Ж.-Б. Мольерның «Дон Жуан» спектаклендәге төп герой – Дон Жуан роле өчен бирелде. «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә В.И. Качалов исемендәге Рус Зур драма академия театры артисты Марат Голубев җиңде. Бүләкне ул Дон Жуан»дагы Сганарель роле өчен алды. «Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле» дип, Әлмәт татар дәүләт драма театрының Б. Брехт әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Бистә фәрештәсе» спектаклендә Ми Цзю ролен башкарган Мәдинә Гайнуллина исеме аталды. Тантанада актерлар ансамблен дә бүләкләделәр. «Иң яхшы актерлар ансамбле» номинациясендә Д. Линдси-Эберның «Кроличья нора» пьесасын сәхнәләштергән «Мастеровые» рус драма театры җиңүче дип табылды. «Ел вакыйгасы» җиңүчесе номинациясе – республиканың театр дөньясында иң төп приз. Ул бүләккә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры «Безгә тынычлык бир» («Dona Nobis Pacem») спектакле өчен лаек булды. «Иң яхшы эпизодик роль» – Казан дәүләт яшь тамашачылар театрында Дж. Родариның «Джесельмино в Стране Лжецов» спектаклендәге Булочник роле табылды. Аны актер Василий Фалалеев башкара. «Музыкаль театрның иң ахшы актеры» исеменә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрыннан Гөлнара Гатина лаек булды.

**27 март көнне** С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында «Тукайның әкияти дөньясы» дигән театральләштерелгән концерт булды. Концерт сөекле шагыйребезнең 130 еллыгына багышланган иде. Гаилә өчен абонементта Тукайның өч легендар әкияте – «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән сарык» тәкъдим ителде. Чара ике телдә алып барылды. Анда әкиятләр укылды, шагыйрь тормышын яктырткан хатирәләр яңартылды. Концертны нәфис сүз осталары Луара Шакирҗанова һәм Америкадан килгән артист, милләттәшебез Рөстәм Галич алып барды. Үзенчәлекле бәйрәмдә, шулай ук, танылган коллективлар, яшь, талантлы музыкантлар да катнашты. Татар милләтенең бөек шагыйре Г. Тукай мирасы

еллар узган саен халык күңеленә тирәнрәк юл яра бара. Аның 130 еллыгына багышланган юбилей уңаеннан оештырылган чаралар – моның ачык мисалы. Олугъ юбилейны Татарстанда гына түгел, ә дөньяның төрле почмакларында да бәйрәм итәләр. Бу вакыйгадан С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы да читтә кала алмады – шагыйрь иҗатына анда әкиятләр аша мөрәҗәгать иттеләр. Программада Ф. Яруллинның «Шүрәле», А. Бакировның «Су анасы» балетлары, Р. Яхин, Н. Даутов, Җ. Фәйзи әсәрләре һәм халык җырлары эшкәртмәләре бар. Проекта кыллы квартет, халык уен кораллары оркестры, камера хоры, «Казан» бию ансамбленең балалар коллективы катнаша.

**29 мартта** Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «История и этнография народов Крыма: библиография и архивы (1921–1945)» («Антиква» нәшрияты) дип аталган ретроспектив библиографик күрсәткечне тәкъдим итү чарасы булды. Аның авторы – тарих фәннәре докторы, профессор, В.И. Вернадский исемендәге Кырым федераль университетының тарихи төбәкне һәм крайны өйрәнү кафедрасы мөдире, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Кырым фәнни үзәге хезмәткәре Андрей Непомнящий. Фәнни белешмәлек – аның Санкт-Петербург, Мәскәү, Киев, Прага, Одесса, Симферополь, Керчь, Севастополь, Ялта шәһәрләрендәге китапханәләрдә, архивларда унике еллык тикшеренүләре нәтиҗәсе. Басманың уникальлеге – Кырым халыклары тарихы һәм этнографиясе буенча, 1921–1945 еллардагы бөтен фәнни һәм популяр мәкаләләрнең киселеше бер китапта тупланyында. Басмада, вакытлы матбугатта чыккан мәкаләләрдән тыш, Кырымны өйрәнү буенча СССРда һәм аннан читтә басылган барлык материаллар да исәпкә алынган. Моннан кала, Россия, Украина, Чехия кебек илләрнең 30 дан артык архивында кульязма килеш сакланып, әле басылып чыкмаган материаллар, автор тарафыннан табылып, басмага кертелгән. Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры урынбасары, тарих фәннәре докторы Радик Салихов: «Кырым ханлыгы һәм Кырым татарлары тарихын өйрәнү проблемасы буенча Кырымдагы коллегалар белән хезмәттәшлек итү Татарстан Республикасының “Татар халкының милли тәңгәллеген саклау (2014–2016 еллар)” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында безнең институт өчен аеруча кыйммәт», – диде. Билгеле булганча, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Кырым фәнни үзәге 2014 елның июнендә ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән булдырылды. Фәнни үзәктә 15 хезмәткәр эшли, шул исәптән, 3 фән докторы һәм 6 фән кандидаты. Үзәк эшчәнлегенең өстенлекле юнәлеше буларак, Кырым татарлары һәм Кырым халыклары тарихын һәм мәдәниятен тикшерү, Кырым ярымутравының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү һәм саклау проблемаларын өйрәнү каралган.

**31 мартта** Г. Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры Казан укучылары арасында «Яз. Тукай. Ватан» мәктәп театр коллективлары фестивале уздырды. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән берлектә оештырылган фестиваль татар халкының бөек шагыйре, татар әдәбияты классигы, әдәби тәнкыйтьче, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, яңа заман татар әдәбиятына һәм әдәби теленә нигез салучы Габдулла Тукай һәм артист, драматург, режиссёр Габдулла Кариевның тууына 130 ел тулу уңаеннан үткәрелде. Фестиваль мәктәп укучылары һәм яшьләр арасында ана теленә мәхәббәт уяту, милләтпәрвәрлекне арттыру, укучыларның мәдәни белемен камилләштерү, талантлы яшьләрне барлау һәм аларга булышу, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы иҗади, креатив карашлы шәхесләр үстерү максатын күздә тотып оештырылды.

**Март аенда** «Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы» – сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган шундый исемдәге республикакүләм әдәби-музыкаль бәйгенең зональ туры Чаллы Үзәк китапханәсендә дә узды. Бу бәйгедә Тукай иҗатын сөюче элемтә хезмәткәрләре катнашып, үз сәләтләрен күрсәтә алды. Мәгълүм булганча, шагыйрьнең юбилее уңаеннан оештырылган иҗади ярышның башта районнарда сайлап алу турлары үткән иде, аннан төрле шәһәрләрдә зональ турлар старт алды. Чаллыда «Таттелеком» җәмгыяте һәм Үзәк китапханәнең Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге тырышлыгы белән оештырылган әлеге әдәби-музыкаль бәйгедә Чаллы, Актаныш, Әгерҗе, Менделеевск, Түбән Кама, Алабуга элемтәчеләреннән тыш, Чаллы китапханәчеләре, мәктәп укучылары, тәрбиячеләр, педагоглар, студентлар, спортчылар да көч сынашты. Әлеге вакыйганы тамаша кылырга китапханәнең китап укучылары, студентлар, мәктәп укучылары, әдәбиятка гашыйк шәһәр халкы җыелды. Бәйгедә биш төрле номинация каралган: «Нәфис сүз», «Вокал», «Хореография», «Инструменталь жанр» һәм «Театр жанры». Төп шарт – башкарылачак әсәр Тукайныкы яки аңа багышлап язылган булырга тиеш. Иң күп тапкыр башкарылган әсәр – «Туган авылым» булды. «Туган тел» әсәре исә дүрт төрле телдә сөйләнде һәм җырга да салынды. «Кәҗә белән Сарык» әсәрен театральләштереп куючылар булды. Чарада язучы, җәмәгать эшлеклесе, 2016 елда Габулла Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясенә кандидат Фәүзия Бәйрәмова да катнашты. Ул халыкны шагыйрьнең тормыш юлы һәм аның әсәрләре белән таныштырды. «Тукай мирасы» исемле китап күргәзмәсе, «Тукай дөньясы» дигән декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре экспозициясе, Тукай иҗаты буенча стена газеталары күргәзмәсе, шәһәр музее экспонатлары ярдәмендә эшләнгән «Шагыйрь яшәгән чор чагылышы» экспозициясе – барысы да халыкны көн дәвамында

Тукай иҗатына якынайтты. Әдәбият һәм сәнгать белгечләреннән төзелгән мәртәбәле жюри карары нигезендә, әлеге турның җиңүчеләре дип, «Таттелеком»ның Чаллы элемтә узелында өлкән белгеч булып эшләүче Люция Ягафарова һәм армрестлинг буенча дөнья чемпионы Миләүшә Гыймранова табылды. Алар апрель аенда Арча районы Яңа Кырлай авылындагы Тукай музеена юл тотачак. Анда бәйгенең финал өлеше һәм шагыйрьнең юбилее уңаеннан зур бәйрәм чаралары көтелә.

**Апрель аенда** Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуга багышлап, «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» дигән Казан күләмендә фестиваль-конкурс үткәрелде. Фестиваль-конкурсның район этаплары Казан шәһәренең «Сәйдәш» Мәдәният үзәгендә, В.И. Ленин исемендәге Мәдәният йортында, Мирный торак массивы Мәдәният йортында, «Юность» Мәдәният йортында узды. Катнашучылар 6 номинация буенча осталыкта көч сынаштылар: «Нәфис сүз», «Театр сәнгате», «Хореография», «Вокал», «Инструменталь жанр», «Гамәли сәнгать». Район этаплары нәтиҗәләре буенча лауреатларны билгеләделәр. Аларга шәһәр күләмендәге фестиваль-конкурсның гала-концертында гран-при һәм истәлекле бүләкләр тапшырылачак. Иң оста башкаручылар татар йолдызлары катнашындагы гала-концертта сәләтен күрсәтә ала. «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» дигән шәһәр күләмендәге фестиваль-конкурсның гала-концерты 25 апрель көнне Иске Татар бистәсендә (җәяүлеләргә бирелгән К. Насыйри урамында) була.

**1 апрель көнне** Россиянең дүрт вузы «Уңышлы университетларның глобаль рейтингы» йөзлегенә керүе мәгълүм булды. Fortunate 500 World University Rankings уңышлы университетларның глобаль рейтингы – халыкара югары белемне тикшерүчеләр командасының бәйсез проекты. Аңа «Югары икътисад мәктәбе» илкүләм тикшеренү университетының Мәгариф институты вәкилләре дә кергән. Рейтингның беренче йөзлегенә кергән Россия вузлары арасында М. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты (дөньяда 15 нче урын), Түбән Новгород дәүләт университеты (18 нче урын), «МИСиС» Илкүләм тикшеренү технологик университеты (50 нче урын) һәм «Югары икътисад мәктәбе» илкүләм тикшеренү университеты (76 нчы урын) бар. Рейтингның биш йөзлегенә Россиянең 14 югары уку йорты кергән, шул исәптән «5–100» дәүләт программасында катнашучы 10 вуз. Казан федераль университеты 441 нче урынны били.

**Апрель башларында** Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендәге республика мөселманнары Диния нәзарәте делегациясе Мисырга эшлекле сәфәр кылды. Мөфти, аның урынбасары, РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин,

Голәмәләр шурасының гыйльми сәркатибе, проректор Рөстәм Нургалиев Әл-Әзһәр университеты җитәкчесе, шәех Әхмәд Тайиб, Әл-Әзһәр университеты профессоры, доктор, шәех Ибраһим Сәлах Әл-Һөдһөд белән очраштылар. Әлеге очрашуда дин әһелләре ислам мәгарифенә кагылышлы мәсьәләләр хакында фикерләштеләр. Алар Россиядән Әл-Әзһәр университетына укучыларны бары тик Ислам мәгарифе советы юлламасы буенча гына кабул итү турында сөйләштеләр. Россия күләмендә эшли торган шушы советка сәяси фәннәр докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин җитәкчелек итә. Бездәге дини югары уку йортлары Әл-Әзһәр университетының сәнавия дәрәҗәсенә тигезләнәчәк, ягъни, бездә югары дини гыйлем алган кеше Әл-Әзһәрнең теләгән факультетына беренче курска укырга керә алачак. Моңа кадәр чит илдән килүчеләргә бирედә башта башлангыч гыйлем алу мәҗбүри иде, дип хәбәр итә бу хакта ТР мөселманнары Диния нәзарәте. Шулай ук ислам академиясен булдыруда Мисыр дин белгечләре белән хезмәттәшлек итү турында килешенгән. Чит илләрдә таралган татар дин галимнәренең борынгы кулъязмаларын эзләп бастыру эшендә Мисырның фәнни үзәге ярдәм итәчәк.

**1 апрельдә** Варшавада ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты башлангычы белән «Язма Мирас. Письменное наследие. Textual heritage» проекты кысаларында «Польша архивларында татар документлары» дигән түгәрәк өстәл уздырылды. Әлеге чара Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Польша Фәннәр академиясе, Варшава университеты, немецларның Кавказ, татар һәм төркестан тикшеренүләр институты (ICATAT) белән берлектә оештырылды. Проект Ватикан, Венеция, Генуя, Истанбул, Стокгольм, Берлинда һәм Европаның башка шәһәрләре архивлары, музейларында татар халкы, Татарстан турында тарихи материалларны ачыклап өйрәнүне максат итә.

**4 апрельдә** ТР Фәннәр академиясендә А.Х. Халиков исемендәге Археология институты һәм КДУ «Тарихи ономастика һәм этник тарих» дип исемләнгән дүртенче дисциплинара семинар уздырды. Географик исемнәрнең килеп чыгышы һәм топониминың мөмкинлекләре, археологиядәге һәм фәннең башка өлкәләрендәге мәгълүматларга аларның өстәмә материал чыганагы булуы, шулай ук теге яки бу субстрат топонимнарның килеп чыгышын төп методлар ярдәмендә өйрәнү һ.б. турында филология фәннәре докторы Олег Смирнов (Екатеринбург) чыгыш ясады. Александр Пустяковның (Һельсинки) чыгышы Пермь топонимнары мәсьәләсенә багышланган иде. Ул топонимик анализ материалы удмурт топонимиясенең «удмурт» компонетлы этнотопонимнарның таралыш ареалы белән тәңгәл килүе сәбәпле, аны аерым бүлеп чыгарырга да мөмкинлек булуын җиткерде. Семинар Владимир Напольскихның (семинарның модераторы)

«Фин-угор этнонимиясе Идел буе һәм Урал алды төбәгенең тарихи чыганагы» темасы буенча әзерләнгән чыгышы белән тәмамланды. Соңыннан семинарда катнашучылар җанлы бәхәсләрдә катнашты.

**Апрель азакларында** Казан дәүләт медицина университеты белем дәрәҗәсен ачыклау максаты белән «Бердәм диктант» акциясен үткәрде. Акциядә катнашырга теләүчеләр бу көнне университетның төрле аудиторияләрендә татар телендә диктант яздылар. Акциягә Татарстан шәһәр һәм районнарындагы медицина көллиятләре һәм училищелары да кушылды. Булачак медицина хезмәткәрләре диктантны Габдрахман Әпсәләмовның шушы игелекле һөнәр ияләренә багышланган «Ак чәчәкләр» романыннан алынган өзек буенча яздылар. «Бердәм диктант» «Татарстан Республикасы халыкара телләре турында»гы канун һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасының 2014–2020 елларга дәүләт программасы кысаларында үткәрелде.

**22 апрельдә** КФУның Алабуга институты базасында Туган тел көненә багышланган «Төрки дөнья: тел, әдәбият, тарих һәм дин проблемалары» VIII халыкара тюркология конференциясе уздырыла. Конференциянең төп максаты – төрки халыкларның телен, әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү практикасы һәм фәнни проблемалары, төрки халыкларның тарихи язмышында ислам диненең роле һәм тоткан урыны турында фикер алышу. Фәнни чарада галимнәр, вуз мөгаллимнәре, теологлар, методист-укытучылар, аспирантлар катнаша. Конференциядә төрки халыкларның тарихы һәм археологиясе, фольклоры һәм әдәбияты, топонимикасы һәм ономастикасы, заманча төрки тел белеменең актуаль мәсьәләләре, төрки халыкларда ислам һәм дини күзаллаулар, лингвокультурология, контактология һәм тәрҗемә мәсьәләләре, төрки телләрне һәм әдәбиятларны укытуда инновацияләр дигән тематик юнәлешләр буенча секция утырышлары уздырылды. Конференция кысаларында төрки халыкларның тарихы һәм мәдәнияте буенча фәнни эшләр, шулай ук татарларның кулъязма китаплары һәм традицион бизәнү әйберләре күргәзмәләре, түгәрәк өстәлләр һәм башка фикер алышу мәйданчыклары оештырылды.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc. форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

— авторның фамилиясе, инициаллары

— мәкалә исеме

— аннотация (рус телендә)

— төп сүзләр (рус телендә)

— сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31, 3 нче кат, 133 нче бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**
На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2016. № 2

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды:   .  .2016.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,5. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59, 292-71-80
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20